# ШУРА

№ 24

2019




2000999941436

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

ЭЧТӘЛЕК

ВӘГАЗЬЛӘР

Шәйтанның явызлыгыннан саклану, аның аздыру юлларын белү . . . . . 12
Бәраәт кичәсе . . . . . 19
Зәкят – Исламның өченче баганасы . . . . . 24
Рамазан аена рәхим итегез! . . . . . 30
Рамазан ае фазыйләтләре . . . . . 37
Рамазанда да гөнаһларны калдыра алмасак... . . . . . 43
Ураза тотуның фазыйләтләре . . . . . 48
Кадер кичәсе . . . . . 53
Ураза гаете хөтбәсенең гарәпчә укылышы . . . . . 58
Ураза гаете хөтбәсенең кириллицага транслитерациясе . . . . . 60
Ураза гаете хөтбәсенең татарчага тәрҗемәсе . . . . . 62
Ураза гаете вәгазе . . . . . 64
Рамазан аеннан соң да гыйбадәтләрне киметмәгез . . . . . 71
Мөселманның сөннәт буенча киенү рәвеше . . . . . 77
Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен белик! . . . . . 82
Табигать – адәм балаларына әманәт . . . . . 88
Сабырлык . . . . . 93

ҮРНӘК ЗАТЛАР

Бишенче тугры хәлифә – Гомәр бине Габделгазиз . . . . . 102
Мөэминнәрнең анасы – Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә . . . . . 110

ФӘН

Шәригать хөкемнәре . . . . . 116
Коръән ничек сакланган . . . . . 128

ТАРИХ

Габденнасыйр Курсави . . . . . 137

«Зәңгәр» мәчет һәм «Халидия» мәдрәсәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . 148

МИРАС

Тәрбияле ата . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151

УРАЗА

Рамазан аеның фазыйләтләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161

НӘСЫЙХӘТ

Сәхабәләрнең әхлагы һәр мөселманга үрнәк . . . . . . . . . . . . . . 171

Йосыф галәйһиссәлам – бөтен кешелек өчен югары әхлакның гүзәл үрнәге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174

ТӘРБИЯ

Бала һәм милли аң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183

ӘДӘБИ СӘХИФӘ

Соңгы сынау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191

**«ШУРА» дини альманах, №24**

*апрель – июнь 2019*
*шәгъбан – шәүвәл 1440*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Эдуард Димасов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нчы йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«Инфо систем» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420044, Казан ш., Ямашев проспекты, 36 Б*
*Тел./факс: +7 (843) 519-91-10*
*Сайт: http://kpkps.ru/*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 21.03.2019
Чыгу көне: 01.04.2019

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хөтбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, басып, кычкырып түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللّٰهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللّٰهِ۞ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللّٰهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللّٰهِ! ۞ اِتَّقُوا اللّٰهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللّٰهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللّٰهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

________________________________۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللّٰهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

۞____________________________________

Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, кычкырып түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللّٰهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللّٰهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللّٰهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган выкытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللّٰهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعْوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хөтбә буларак киләсе сүзләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللّٰهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ

إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاتِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне кычкырып укый һәм хөтбә тамам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَائِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهُ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, басып, кычкырып түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләẓии һәдәәнә лиһәәẓәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләẓии каалә фии китәәбиһил- кәриими әстәгыйẓү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаẓәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъдү: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә этыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләẓиинәт-тәкау, вәл-ләẓиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйẓү билләһи: ______________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ______________________________

______________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, кычкырып түбәндәге сүзләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә кааләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иẕәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйẕү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган выкытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хөтбә буларак киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләẕиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ẕәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә

вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мүʼминиинә вәл мүʼминәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мукыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне кычкырып укый һәм хөтбә тамам була:**

«Иннәллаһә йәʼмүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

# Вәгазьләр

*12 апрель вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Шәйтанның явызлыгыннан саклану, аның аздыру юлларын белү

Барча галәмнәрне юктан бар кылучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмде-сәна, мактауларыбыз, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең түреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде һәм дә аның әһле бәйтенә, сәхабәләренә сәламнәребез, изге догаларыбыз ирешсә иде. Раббыбыз Аллаһының әмерен үтәп, Аның рәхмәтләренә ирешергә ният итеп, җомга намазына килгән мөэмин-мөселман кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Һәрберебезгә дә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең сәламе, ике дөнья рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Үзенең Коръәни Кәрим китабында болай дип әйтә:

إِنَّ الشَّيْطَانَ لَكُمْ عَدُوٌّ فَاتَّخِذُوهُ عَدُوًّا ۚ إِنَّمَا يَدْعُو حِزْبَهُ لِيَكُونُوا مِنْ أَصْحَابِ السَّعِيرِ ﴿٦﴾

**«Дөреслектә, шәйтан сезгә дошмандыр, сез дә аны дошман тотыгыз! (Аллаһы тыйган фәхеш, харам эшләрдән вә бидгать гамәлләрдән саклану һәм фарыз, вәҗиб, сөннәт гамәлләрен үтәү һәм шәйтан дуслары, динсезләрдән киселү – шәйтанны дошман тоту буладыр). Әлбәттә, шәйтан үзенә ияргән кешеләрне җәһәннәмгә кертер өчен, аларны Аллаһы тыйган эшләрне эшләргә өндидер һәм Аллаһы кушкан эшләрдән тыядыр».**

«Мәләикә / Фәрештәләр» 35:6

Хәбәр итүләре буенча, сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Шәйтан адәм улында кан юлыннан йөри», – дип әйткән.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе: «Шәйтан кешеләрнең күкрәкләренә кергән кебек, җеннәрнең дә күкрәкләренә керер һәм вәсвәсә кылыр. Әгәр Аллаһы Тәгалә зекер ителсә, аларның күкрәкләреннән чыгар һәм качар», – дип әйткән. Ягъни, шәйтан адәм баласы һәм җеннәрнең янында гына йөреп калмый, ә аздырыр өчен аларның эчләренә, йөрәкләренә керә, хәтта кан тамырлары буенча да йөри. Әгәр дә кешеләр дә, җеннәр дә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләне зурлап, даими зекер итсәләр, көненә биш вакыт намазларын вакытында үтәсәләр, уразаларын тотсалар, фарыз, вәҗиб, нәфел садакаларын бирсәләр, ел саен корбан чалдырсалар (чалсалар), кешенең эченә кергәне дә чыга, янында булганы да Аллаһы Тәгаләне зекер итүченең тавышы ишетелмәслек җиргә качар. Әгәр дә халкыбыз даими намазларын үтәп, Аллаһыны зекер итсә, ул вакытта бозыклык та кимер иде.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин туры юлга өндәүче, ирештерүче булып җибәрелдем. Миндә һидаятьтән кала бернәрсә дә юктыр. Иблис аздыручы булып яратылды. Анда заләләттән башка бернәрсә дә юк», – дип әйткән. Ягъни, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм туры юлга өндәүче һәм туры юлдан адашмыйча барырга өйрәтүче итеп җибәрелгән. Шул ук вакытта, шәйтан котыртуына иярмәү ысулларын һәм шәйтанның вәсвәсәсеннән котылу юлларын өйрәтергә җибәрелгән. Шәйтанның котыртуыннан котылу юлларын өйрәтеп кенә калмаган, аны үзенең яшәү рәвешендә дә күрсәткән. Ә инде адәм баласына сынау буларак, аңа вәсвәсә кылып, гөнаһлы гамәлләрне матурлап күрсәтер өчен иблис мәлгунь яратылган. Ул кылган һәм чакырган гамәлләре адәм баласын туры юлдан яздыру, аздыру өчен эшләнелә. Шуңа күрә, кешегә үзеннән аның котыртуын кире кагып, дошманы булган шәйтанга каршы тору – фарыз була.

Әлбәттә, акыллы кеше генә дошманнан дусны, дустан дошманны аера белә. Мөэмин-мөселман дустына итагать итеп, дошманы булган шәйтанның кылган гамәлләрен кире кагып, аңа иярмәскә тиеш була.

Надан кешенең билгеләре дүрт төрле: 1) кирәксезгә, урынсызга ачулану; 2) кирәксезгә бозык эшләрдә нәфесенә иярү; 3) кирәк булмаган, хаксыз урынга малын сарыф итү; 4) дошманыннан дустын аера белмәү.

Ошбу санап үткән гамәлләрне гыйлемсез кеше генә кыла. Наданлыгы аркасында шәйтанның харам нәрсәләрне матур итеп күрсәтүенә бирелеп, Аллаһы Тәгаләгә буйсынасы урынга, шәйтанга гыйбадәт кыла башлый.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйтә:

أَفَتَتَّخِذُونَهُ وَذُرِّيَّتَهُ أَوْلِيَاءَ مِن دُونِي وَهُمْ لَكُمْ عَدُوٌّ ۚ بِئْسَ لِلظَّالِمِينَ بَدَلًا ﴿٥٠﴾

**«... Әллә сез, адәм балалары, Минем урыныма ул иблисне вә аның нәселен дус тотарсызмы? Алар бит сезгә дошманнардыр. Аллаһыга итагатьне иблискә итагать итү белән алмаштыру залимнәр өчен ни яман булды».**

«Каһаф / Тау тишеге» 18:50

Адәм баласы Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, Раббысы Аллаһыга якынаерга, ә иблис мәлгуньнең нәселеннән булган шәйтаннар кыла торган бозыклыктан ерак булырга тиеш. Кеше Аллаһы Тәгалә разый булырлык гамәлләр кыла икән – җәннәтле була, ә акылын эшләтмичә, шәйтан коткысына бирелә икән – җәһәннәмгә керәчәк, чөнки дус-ишләр бергә булачак.

Акыллы кешенең билгесе дүрт төрле гамәл белән аерылып тора:

1. Наданнарга йомшак күңелле булыр.

2. Батыйльдан (ялганнан) нәфесен тыяр – кирәкмәгән, бозык эштән ерак булыр. Файдасыз эштән сакланыр.

3. Малын кирәкле, тиешле урынга гына сарыф итәр.

4. Дусны дошманыннан аера белер.

Хәбәр итүләре буенча, иблис Яхъя галәйһиссәламгә очрагач, Яхъя аннан адәм балалары турында аның фикерен сораган. Ул: «Адәм балалары өч төркемгә бүленәләр: беренчесе – синең кебек (ягъни Яхъя галәйһиссәлам кебек), аларга карата бернәрсә дә кыла алмыйм. Икенче төрле кешеләр безнең кулыбызда балалар кулында булган туп кебек: без алар белән теләгәнчә уйныйбыз. Ә өченче төрле төркем – безнең өчен иң авыры. Аларга вәсвәсә кылып, теләгебезгә ирешәбез, ә ул Аллаһы Тәгаләдән куркып, тәүбәгә килә дә, гөнаһлы гамәлләрен ташлап, безнең куйган хезмәтебезне юкка чыгара. Без ошбу өченче төркемнән өметсез дә булмыйбыз, аларга карата теләгебезгә дә ирешә алмыйбыз», – дип Яхъя галәйһиссәламгә җавап биргән.

Галимнәр әйтүләре буенча, шәйтанга ун төрле кешене туры юлдан яздырырга җиңелрәк икән:

1. Комсызлар һәм яман уйда булучыны.

2. Дөньяда озак яшәргә теләүчене.

3. Рәхәтне һәм нигъмәтне тиешледән артык теләүчене.

4. Үзенең кылган гамәлләренә исе китеп, сокланучыны.

5. Кардәшләрен кимсетеп, аларны хөрмәт итмәүчене.

6. Көнче, хөсед кешене.

7. Рия һәм кешеләрнең мактавын яратучыны.

8. Саран кешене.

9. Тәкәббер кешене;

10. Барчасының да ярдәмен теләүче кешене.

Аллаһы Тәгалә «Әгъраф» сүрәсенең 17нче аятендә иблиснең сүзләрен китереп, болай дип әйтә:

ثُمَّ لَآتِيَنَّهُم مِّن بَيْنِ أَيْدِيهِمْ وَمِنْ خَلْفِهِمْ وَعَنْ أَيْمَانِهِمْ وَعَن شَمَائِلِهِمْ ﴿١٧﴾

**«Соңыннан аларны аздырыр өчен алларыннан һәм артларыннан, уң якларыннан һәм сул якларыннан килермен...»**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:17

Кайбер тәфсир галимнәре әйтүенчә, иблиснең «кешеләрнең алларыннан килермен» дип әйтүе – Кыямәт көнен аңлата, чөнки ул алда, ягъни киләчәктә булачак. Әгәр дә иблис кешеләрнең күңеленә Кыямәт көненең булуына карата шик салса, ул вакытта алар кылган гамәлләре өчен үлгәннән соң җавап бирәчәкләрен оныталар. Шул сәбәпле, алар гөнаһлар кыла һәм башкаларның хакларын бозудан курыкмый башлыйлар.

Иблиснең «кешеләрнең артларыннан килермен» дип әйтүе – без яши торган дөньяны аңлата диләр. Иблис вәсвәсәсе белән кешеләргә дөньяны, аның ләззәтләрен матурлап күрсәтә, үлемне оныттыра. Шуңа кеше Ахирәткә әзерләнмичә, Аллаһы Тәгалә кушканнарын үтәмичә, тыйганнан тыелмыйча, киләчәккә зур планнар корып яши. Әмма Аллаһы Тәгалә билгеләгән үлем сәгате аңа көтмәгәндә килә һәм ул намаз укымыйча, ураза тотмыйча, изге гамәлләр кылмыйча, фани дөньядан китеп тә барырга мөмкин.

Иблиснең «кешеләрнең уң ягыннан килермен» дип әйтүе – изге гамәлләр кылудан читләштерергә тырышырмын, дигәнне аңлата. Ул кешеләрнең күңелләренә изгелек эшләү бернигә дә тормый, дигән уй кертә. Әгәр дә кешенең дини гыйлеме булмаса, ул изгелек кылуны файдасыз бер гамәл итеп күрә башлый.

Әгәр дә кеше байлыгыннан зәкят, гошер, фитыр садакасын бирергә, йә байлыгын башка бер хәерле эштә сарыф итәргә теләсә, шәйтан аның

күңеленә: «Байлыгыңны юк-барга әрәм итмә, фәкыйрьләнәсең бит», – дигән коткы сала. Шуның белән иблис хәерле эшне начар бер гамәл итеп күрсәтә.

Иблиснең «кешеләрнең сул ягыннан килермен» дип әйтүе – кешеләргә гөнаһлы гамәлләрне матурлап күрсәтермен дигәнне аңлата. Шуңа кешеләр бозык, явыз гамәлләрне хәерле дип уйлап, аларны кыла башлыйлар. Иблис кешене гөнаһлар кылдыру аркылы Аллаһы Тәгаләне инкяр итүче имансыз итәргә яки Аллаһыдан башка затларга гыйбадәт кылучы мөшрик итәргә тели. Иблис бүгенге көндә байтак кына кешеләр белән үзенең максатына иреште дә.

Иблис: «Әгәр нәфесе аны гаҗәпләндерсә, гамәлен күпкә санаса һәм кылган гөнаһасын онытса, мин аны җиңәмен», – дип әйтте (ягъни, әгәр кеше үзенең теләгенә бирелеп башкарган эшләренә: «Мин бит башкалар эшли алмаган эшне башкарып чыктым», – диеп гаҗәпләнсә, иблис аны җиңәчәк). Янә иблис: «Гыйбадәтләрне, изге гамәлләрне күп кылдым инде, кешеләргә кылган изгелекләрем дә бик күп булды инде, шулар мине җәннәткә алып керәчәкләр, – дип санаган кешене; Аллаһы Тәгаләне танып та: «Намаз укымасам да, ел да корбан чалмасам да, башка фарыз, вәҗиб гыйбадәтләрне үтәмәсәм дә, җәннәткә керәчәкмен», – дип йөргән һәм шуңа өстәп кылган гөнаһларын оныткан кешене җиңәчәкмен, андый кешеләр минем белән җәһәннәмгә барырга әзерләнүчеләр», – дип үзе үк әйтә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм иблистән: «Әй, мәлгунь, минем өммәтемнән дошманнарың күпме?» – дип сорагач, иблис мәлгунь: «Унбиш: син; тугры имам; түбәнчелекле бай; гадел сатучы; Аллаһыдан куркучы галим; үгетләүче мөэмин; йомшак күңелле мөэмин; тәүбә кылып, тәүбәсендә торучы; харамнан сакланучы; һәрвакыт тәһарәтле мөэмин; күп садака бирүче мөэмин; кешеләр белән күркәм холыклы булган мөэмин; кешеләргә файда китерүче мөэмин; даими уку-

чы Коръән-хафиз; кешеләр йоклаган вакытта, төнлә уяу торучы кеше», – дип җавап кайтара. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Минем өммәтемнән дусларың кем?» – дип сораган. Иблис мәлгунь: «Алар унау: җәбер кылучы солтан; тәкәббер бай; алдалап сатучы; сәрхуш; сүз йөртүче; зина кылучы; ятимнең малын ашаучы; намазны җиңелгә санаучы; зәкят бирмәүче; дөньяда озак яшәүне теләүче. Менә бу кешеләр минем иптәшләрем һәм кардәшләрем», – дип җавап биргән.

Раббым Аллаһы, мөэмин-мөселманнарга иблис мәлгуньнең явызлыгыннан сакланырга сабырлык, тәкъвалык, камил иман насыйп әйләсәң иде. Әәмин!

*Равил хәзрәт Нуруллин,*
*Яр Чаллы шәһәренең «Туфан» мәчете имам-хатыйбы,*
*Аксакаллар шурасы рәисе*

*19 апрель вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Бәраәт кичәсе

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн, әммә бәгъде: бу фани дөньяны һәм Ахирәт дөньясын яратучы, дөньяга барча тере һәм тере булмаган мәхлүкъларны барлыкка китереп, тәрбия кылучы, адәм балаларын барча мәхлүкаттан өстен итеп, акыл һәм башка бик күп нигъмәтләр белән нигъмәтләндереп, ризыкландыручы вә хәрәкәтләндерүче, фани дөньяның һәм Ахирәтнең хуҗасы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә иксез-чиксез шөкранәләребез һәм дә сәна-мактауларыбыз вә рәхмәтләребез булса иде.

Бу дөньяга рәхмәт буларак җибәрелгән, өммәте өчен бөтен авырлыкларга түзеп, сабыр итеп, үзенә йөкләнгән пәйгамбәрлек вазифасын башкарыр өчен бөтен көчен куйган, Кыямәт көненең бөек расүле – сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләреннән чыккан салават вә догаларыбыз ирешсен.

Ихлас күңел белән, Аллаһының әмеренә буйсынып, дога һәм гыйбадәт кылу өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Изге җомга көнебез барчаларыбызга да хәерле һәм мөбарәк булсын!

Шәгъбан ае дәвам итә. Бу ай Ислам динендә изге айларның берсе санала һәм ул бер-бер артлы килгән өч изге ай рәтендә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның турында: «Шәгъбан – минем аем, раҗәб – Аллаһы Тәгалә ае, Рамазан – минем өммәтемнең ае», – дип әйткән. Динебез тарихындагы мөһим вакыйгалар белән дә үзенчәлекле

ул: Аллаһы Тәгалә Рамазан аенда ураза тоту тиешлеген шушы айда хәбәр итә; кыйбланың үзгәртелүе, Бәраәт кичәсе дә шәгъбан аена туры килә.

«Бәраәт» сүзе гарәп теленнән «бурычтан вә җәзадан котылу» дип тәрҗемә ителә, исламда бу төшенчә «гөнаһлардан котылу» дигән мәгънәгә ия.

Бәраәт кичәсе шәгъбан аеның 14 нче көненнән 15 нче көнгә каршы кичендә була. Бу елны исә ул нәкъ менә бүген ахшамнан соң керә. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

حم ﴿١﴾ وَالْكِتَابِ الْمُبِينِ ﴿٢﴾ إِنَّا أَنزَلْنَاهُ فِي لَيْلَةٍ مُّبَارَكَةٍ ۚ إِنَّا كُنَّا مُنذِرِينَ ﴿٣﴾ فِيهَا يُفْرَقُ كُلُّ أَمْرٍ حَكِيمٍ ﴿٤﴾

**«Хә мим. Хәләлне вә харамны ачыклый торган китап – Коръән белән ант итәмен. Чыннан да, Без ул Коръәнне мөбарәк булган бер кичне төшердек. Чыннан да, без ул Коръән белән кисәтүче булдык, һәр хикмәтле эш мөбарәк кичтә хәл ителер».**

«Духан / Төтен», 44:1-4

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Бәраәт турында болай дигән дигән: «Шәгъбан аеның уртасындагы бу кичәдә Аллаһы Тәгалә Бәни Кәлеб кабиләсе сарыкларының йоннары санынча кешеләрне җәһәннәмнән азат итәр».

Әйе, әлеге кичә гөнаһлардан котылу, иминлек кичәсе, төрле уңышлар, изгелекләр иңә торган кадерле вакыт. Бу вакытта Аллаһы Тәгалә кешеләрнең бер еллык бәхет-сәгадәтен, язмышын билгели. Шулай ук бу кичәдә кешеләрнең бер еллык гамәлләренә нәтиҗә ясала. Алдагы ел өчен бөтен мәхлүкатның ризыклары, киләсе ел эчендә туачак һәм вафат булачак кешеләр дә бу кичне билгеләнер. Бу кичтә кеше гөнаһлары өчен гафу үтенсә, ин шә Аллаһ, кешенең гамәл дәфтәреннән шул узган елда кылынган гөнаһлары сызылыр.

«Мөселманнар бу кичәдә нинди гамәлләр кылалар соң?» дигәндә, әлбәттә, Аллаһыга дога кылалар, фәкыйрьләргә, мескеннәргә, мохтаҗ кешеләргә садакалар бирәләр, һәрвакыт гыйбадәттә, изгелектә булырга тырышалар. Ибне Мәҗедән (Аллаһы аннан риза булсын) тапшырылган бер хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең болай дип әйткәне риваять ителә: «Шәгъбан аеның унбишенче кичәсе керсә, аны гыйбадәт белән уздырыгыз. Көндез ураза тотыгыз, чөнки ул кичне Аллаһы Тәгалә кояшның чыгуына кадәр дөньяга рәхмәт карашы белән карар һәм боерыр: «Юкмы гафу сораучы, аны гафу итәм. Юкмы ризык сораучы, аны ризыкландырырмын, юкмы кайгылы вә авыру кеше, шифасын һәм дәвасын бирермен. Моннан тыш нинди теләкләре бар, сорасыннар – бирермен һәм бу хәл кояш чыкканчы дәвам итәр».

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Бәраәт кичәсе көнендә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәм мәгъфирәте җир йөзенә таралып торыр, дигән идек. Шуңа да безгә бу изге кичәдә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен мөмкин кадәр күбрәк изге гамәлләр, нәфел гыйбадәтләр кылырга тырышырга кирәк. Сөекле Расүлебез моңа басым ясап, үзенең хәдисендә: «Бәраәт – сезнең өчен зур форсаттыр, зур байлыктыр, чөнки ул билгеле булган бер кичәдер. Шәгъбан аеның 14-еннән 15-енә булган кичәседер. Кадер кичәсе, Бәраәт кичәсеннән зуррак булса да, кайчан булганы төгәл билгеле түгел. Шуңа да бу кичәне күбрәк гыйбадәт кылып уздырыгыз», – дип юкка гына әйтмәгәндер.

Шушы кичтә «тормыш» дигән агач селкенеп, шуннан кешенең исеме язылган яфрак өзелеп төшәр, дигән риваять бар. Димәк, кешенең гомере шушы кичәдә билгеләнә: тагын бер ел яшиячәкбезме? Әгәр безгә әҗәл килсә, Аллаһы Тәгалә каршысына барырга безнең нинди изгелекләребез бар? Нинди гөнаһларыбыз бар, нинди гөнаһлардан безгә тәүбә кылырга кирәк? Мөхтәрәм җәмәгать, шушы кичтә әнә шул сорауларны үзебезгә би-

реп, уйлансак иде. Шуңа күрә дә безгә күбрәк «Әстәгъфируллаһ»ны әйтү кирәк. Кайбер риваятьләрдә бу кичтә «Йәсин» сүрәсен уку киңәш ителә.

Бәраәт кичәсендә намаз уку, изгелекләр кылу, әрвахларга догалар кылу хәерле. Моннан тыш Бәраәт кичендә ураза тоту гадәте Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең күркәм сөннәте булып тора. Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам: «Бәраәт кичәсе – догалар һәм теләкләр кабул була торган кич. Бу кичәне үзебез һәм әһелебез, балаларыбыз, туганнарыбыз өчен догалар кылып, Аллаһыдан сорау кирәк», – дип әйткән.

Башка бер хәдистә китерелә: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына Җәбраил фәрештә килеп: «Йә, Мөхәммәд, бу кичәдә өч йөз рәхмәт ишеге ачылыр. Аллаһы Тәгалә һәр мөселман бәндәнең гөнаһасын ярлыкар, мәгәр ун төрле кешенең гөнаһасын ярлыкамас: сихерчене, күрәзәчелек кылучыны, мөселманны рәнҗетүчене, исерткеч эчемлекләрне эчәргә даимчылык кылучыны һәм зиначыны, риба кылучыны, ата-анасын рәнҗетүчене, нахакка кеше үтерүчене, үзенең кардәше белән талашкан кешене. Әгәр ихлас күңелдән тәүбә кылсалар, бу эшне ташласалар, аларның да гөнаһларын ярлыкар», – дип әйткән.

Мөселман кардәшләрем! Шәгъбан аенда бу кадәр сөенечләр булгач, һәркайсыбызга бу кичәдә уяу торып, намаз уку, Коръән уку, Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә салаватлар әйтү, догалар кылу хәерле эшләр булыр.

Бу көнне без үзебезгә Аллаһының бер һидаяте, бүләк көне дип карарга тиешбез. Киләсе Бәраәт кичәсенә хәтле яши алабызмы – белмибез. Аллаһының бу мөбарәк кичәсен күрергә насыйп булган икән, безгә әлеге мөмкинчелектән файдаланырга кирәк. Соңыннан, Аллаһы Тәгалә каршысына баргач, йөзебез кызарырлык булмасын. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

فَاعْتَرَفُوا بِذَنبِهِمْ فَسُحْقًا لِّأَصْحَابِ السَّعِيرِ ﴿١١﴾

**«Эш узгач, гөнаһларын таныдылар, без гаепле диделәр, кыздырылган ут әһелләренә Аллаһының рәхмәте гаять ерактыр».**

«Мүлек / Патшалык», 67:11

Аятьтән күренгәнчә, җәһәннәм ишеге төбенә килеп җиткәч, җәһәннәм әһелләренең хәлен беркем дә үзгәртә алмас. Менә безгә бу дөньяда шушы хәлебезне үзгәртергә мөмкинлек бирелгән.

Бәраәт кичендә һәм, гомумән, Аллаһының киң рәхмәтенә ирешү өчен асыл бәндә булуың кирәк. «Нәрсә ул?» дип сораганда, һәркем, ягъни без – кешеләр, үзебезне вакытлыча гына дөньяга килгәнебезне аңларга тиешле. Аллаһыны мәңгелек дип белсәк, ягъни һәркем үзен вакытлыча икәнен таныса, Аллаһыны да таный һәм дә дөнья байлыкларына алданмыйча, нәфес артыннан бармыйча, хәерле бер адәм булу кирәк. Хакыйкатьтә, дөньяга алдану – мәңгелек дөнья нигъмәтләреннән коры калуга сәбәп була. Асыл бәндә шул: Аллаһы Тәгаләнең әмерләренә буйсынучы, Аллаһы «эшләгез!» дип боерса, аны иҗтиһад кылып (тырышып) башкаручы һәм Раббысының бәла-казаларына разый булып, сабыр итүче. Аллаһы Тәгалә: «Бер колым минем биргән бәлаләремә вә казаларыма сабыр әйләмәсә һәм бирелгән нигъмәтләремә шөкер итмәсә, бу минем бәндәм түгелдер. Җиремнән һәм күгемнән чыгып, үзгә (башка) тәңрене теләсен», – дип әйткән. Асыл бәндә шулдыр – Аллаһыдан куркып, өметләнеп, тәкъвалык белән үтенечтә булуында, Аллаһыга ялваруында.

Аллаһы Тәгалә кылган догаларыбызны, теләгән теләкләребезне кабул әйләсен. Шушы мөбарәк кичәне хәере белән каршы алып, күркәм гыйбадәтләр кылып, гөнаһларыбызны, тәүбәләребезне кабул кылып, күңелләребезне пакьләргә, нурландырырга, изге максатларыбызга ирешергә һәм дә хәерле, тыныч тормышларда яшәргә насыйп вә мияссәр кылса иде. Әәмин!

*Марсель хәзрәт Сабиров,*

*«Болгар» мәчетенең икенче имам-хатыйбы*

*26 апрель вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Зәкят – Исламның өченче баганасы

Галәмнәрне, безне юктан бар итеп яратучы, безгә бу дөньяны бүләк итүче Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз булса иде. Аның сөекле бәндәсе, ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез булса иде. Мөхтәрәм дин кардәшләребез, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Ислам дине 5 рөкенгә нигезләнгән:

1. Аллаһыдан башка һичбер илаһ булмавына вә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аның расүле икәненә шәһадәт китерү.

2. Намаз уку.

3. Зәкят бирү.

4. Рамазан аенда ураза тоту.

5. Хаҗ кылу.

Күргәнебезчә, намаздан соң Аллаһы Тәгалә тарафыннан мөселманнарга фарыз кылынган гамәлләрнең берсе – зәкят. Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында зәкят турында бик күп тапкыр искә төшерә:

وَأَقِيمُوا الصَّلَاةَ وَآتُوا الزَّكَاةَ ﴿٤٣﴾

**« ...Намазларыгызны үтәгез, зәкятләрегезне түләгез».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:43

Аллаһы Тәгалә Коръәндә зәкят түбәндәгеләргә бирелер ди: беренчесе – зәкят бирерлек нисабка ия булмаган фәкыйрьләргә[1]. Нисабка

[1] Фәкыйрьләр – яшәү минимумы булып, нисабы булмаган кешеләр.

килгәндә, без аны ничек аңларга тиеш? Кешенең бай булуының шартлары бар. Динебездә мин бай дигән сүз ул, әгәр дә алтын белән исәпләсәк, 85 грамм алтының булу. Бүгенге көндә якынча 210[1] мең сум акчасы булса, ул нисабка ия кеше, бай кеше булып санала, әгәр бу суммасы булмаса, әлеге кеше фәкыйрь дип санала.

Икенчесе – зәкят бернәрсәләре дә булмаган мескеннәргә бирелер. Димәк, беренчесе фәкыйрьләр булды, икенчесе – мескеннәр. Мескеннәр – ул бернәрсәләре дә булмаган, йортларында бернинди уңайлыклар, шартлары булмаганнар.

Өченчесе – зәкят җыючы махсус кешеләргә бирергә, диелгән.

Дүртенчесе – мөәләфәи кулүб. Бу – Ислам диненә әле генә килгән, әмма йөрәкләре Исламда әле ныгымаганнар[2]. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам вакытында ганимәтләрдән кайбер сәхабәләргә әзрәк бирелгән, әмма яңа гына дингә килгән сәхабәләргә күбрәк бирелгән. Алар нәкъ мөәләфәи кулүб.

Алдагысы – коллыктан котылырга теләүче кешеләр. Безнең җирлектә бүгенге көндә андыйлар инде юк.

Алтынчысы – бурычын түли алмаучы кешеләргә. Аларга шулай ук зәкят бирелергә тиеш.

Җиденчесе – Аллаһы Тәгалә юлында йөрүчеләр.

Сигезенчесе – юлда, сәфәрдә акчасыз калучыларга. Алар мөселман булса – зәкят бирелә. Мөселман булмаса, ярдәм итәргә мөмкинме? Әйе, ярый. Бу садака булып саналачак, ин шә Аллаһ. Садаканы без көн саен бирә алабыз, ә зәкят елына бер бирелә.

Зәкятне кем бирергә тиеш? Ул кеше:

---

1 **Бу 2018 ел өчен билгеләнгән нисаб. 2019 елга нисабның, фидия һәм фитыр садакаларының күләме Пленум утырышында билгеләнгәннән соң, мөхтәсибәтләргә һәм барча имамнарга хәбәр ителәчәк. Әлеге һәм киләсе вәгазьләрдә шул мәгълүматны хәбәр итүегез сорала.**

2 Бу кешеләр кабилә башлыклары булганнар, ләкин Ислам таралганнан һәм көчләнгәннән соң, бу ихтыяҗлык төшеп кала һәм хәзер ул кулланылмый.

1. Мөэмин-мөселман булырга.

2. Үз акылында булырга (ягъни мәҗнүн түгел).

3. Балигълык яшенә җиткән булырга.

4. Ирекле булырга.

5. Матди яктан хәлле булырга тиеш, ягъни бурычларыннан кала мал-мөлкәте билгеле нисаб күләменә ия булырга тиеш. Нисаб турында алдарак әйтеп узган идек – 85 грамм алтын, безнең акчалар белән – якынча 210 мең сум.

Нисаб турында тулырак әйтсәк, шушы 85 грамм алтын күләмендәге мал – ул акча яисә берәр төрле товар рәвешендәге булган мал була ала. Мәсәлән, кемнеңдер 500 меңлек товары булып, бер ел үтеп, бу мал артса, ул бу малдан 2,5 %, ягъни кырыктан бер өлешен зәкят итеп түләргә тиеш.

Тагын бер очрак – ул терлек тоту. Мәсәлән, берәр кеше сарык тотса, ул зәкятне сарыклар белән түләргә тиеш. Әгәр сарыклар 40-тан ким булса, зәкят түләнми. Әгәр сарыклар саны ел дәвамында 40-120 җитсә – 1 сарык, 120-200 җитсә – 2 сарык түләнелә. Бу шулай ук кәҗәләргә дә кагыла.

Кеше сыер тота икән, ул очракта, әгәр 30-дан ким булса, зәкят түләнелми, әгәр 30-дан 39-га кадәр булса, ул чакта 2 еллык бозау белән түләнелә, әгәр 40 булса, 3 еллык бозау белән түләнелә.

Җир зәкяте дип нәрсәне атыйлар? Бу – алынган уңыштан зәкят. Сугару ысулыннан чыгып, булган уңышның 1/10 яки 1/20 өлеше зәкят итеп түләнелә. Әгәр чәчүлек яңгыр суы белән һәм җир асты сулары белән сугарылса – 1/10 өлеше, әгәр ясалма юл белән сугарылса, уңышның 1/20 өлеше түләнелә. Икенче төрле без аны гошер садакасы дип йөртәбез. «Гошер» сүзе гарәп телендәге гашәра – ун – саныннан чыккан. Мисалга, 10 капчык бәрәңгенең 1 капчыгын без гошер садакасы итеп бирергә тиешлебез.

Зәкят биргәндә ният белән бирергә кирәк, шуңа да һәрбер садака бирүне зәкят дип әйтеп булмый. Кайбер кеше: «Мин бит инде көн саен мәчеткә садака биреп торам», – дип ялгыша. Зәкят нәкъ «зәкят бирәм»

дигән ният белән, алда санап киткән категориягә кергән кешеләргә генә бирелә. Бу кешеләрне Аллаһы Тәгалә «Тәүбә» сүрәсенең 60 нчы аятендә әйтеп үтә, шуңа күрә зәкят бары тик кулдан-кулга бирелергә тиеш. Мәчет тартмасына зәкят дип салынган акча шунда югалачак та.

Тагын бер сорау: зәкят бирүне кемнәрдән башларга кирәк? Алар:

1. Мохтаҗ булган бертуган кыз һәм ир кардәшләр, аннан соң аларның балалары.

2. Әти ягыннан мохтаҗ булган абый-апа, аннан соң әни ягыннан мохтаҗ булган абый-апалар.

3. Мохтаҗ булган якын туганнар.

4. Мохтаҗ булган күршеләр.

Әгәр безнең күршеләр фәкыйрь икән, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә бездән: «Син бай идең, ашарыңа-эчәреңә булды, әмма күршеңдә ризык булмады, син аңа булыштыңмы?» – дип сораячак.

5. Үз районыңда, мәхәлләңдә яшәүче мохтаҗлар.

6. Үз шәһәреңдә (район, авыл) яшәүче мохтаҗларга зәкят түләнергә тиешле. Ягъни шушы тәртиптән түләнә башланырга тиеш.

Ә зәкят кемгә бирелми соң? Соңгы арада ошбу сорау күпләрне борчый башлады. Кадерле мөселман кардәшләрем, зәкят түбәндәге кешеләргә түләнми:

1. Әти һәм әнигә.

2. Әби белән бабайга (дәү әни, дәү әти).

Ни өчен аларга зәкят түләнелми? Әти-әни – алар безнең иң якын кешеләребез, без аларны гомеребез буе карарга тиешбез. Бер тапкыр зәкят биреп, «калганын үзегез карагыз инде», – дип әйтү динебездә дөрес түгел. Аларны тәрбияләп, карап тору гел безнең өстебездә булырга тиеш.

3. Үзеңнең улыңа, кызыңа, аларның балаларына.

4. Матди яктан хәлле булган кешеләргә.

5. Мөселман булмаган кешеләргә. Мөселман булмаганнарга зәкят бирелми, ә садака итеп бирелә.

6. Үзеңнең хәләл җефетеңә, ягъни ире бай булып, хатынына зәкят бирә алмый, шулай ук хатыны бай булып, иренә бирә алмый.

7. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам хәзрәтләре һәм аның гаиләсенә.

8. 7 яшьтән кече балаларга.

9. Психик авыру кешеләргә зәкят бирелми.

Мөмкинчелекләре булып та, зәкят түләмәгән кешенең хәле нинди? Бу сораугa Аллаһы Тәгалә «Тәүбә» сүрәсендә җавап бирә:

وَالَّذِينَ يَكْنِزُونَ الذَّهَبَ وَالْفِضَّةَ وَلَا يُنفِقُونَهَا فِي سَبِيلِ اللَّهِ فَبَشِّرْهُم بِعَذَابٍ أَلِيمٍ ﴿٣٤﴾ يَوْمَ يُحْمَىٰ عَلَيْهَا فِي نَارِ جَهَنَّمَ فَتُكْوَىٰ بِهَا جِبَاهُهُمْ وَجُنُوبُهُمْ وَظُهُورُهُمْ ۖ هَٰذَا مَا كَنَزْتُمْ لِأَنفُسِكُمْ فَذُوقُوا مَا كُنتُمْ تَكْنِزُونَ ﴿٣٥﴾

> **«Янә бар шундый кешеләр: алтын вә көмешне җыеп асрарлар, Аллаһы юлына һич тә бирмәсләр, аларга рәнҗетүче газап булачагы турында хәбәр бир. Кыямәт көнендә җыйган ул алтын-көмешләре җәһәннәм утында кыздырылып маңгайларына, вә кабыргаларына, вә аркаларына басылыр һәм әйтелер: болар дөньяда вакытта үзегез өчен асраган алтын вә көмешләрегез. Инде саранлык белән җыеп саклаган малыгызның газабын татыгыз».**

«Тәүбә», 9:34-35

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән: «Зәкят бер һиҗри ел үтмичә, зәкят малыннан алынмый». Без исә зәкятне еш кына Рамазан аенда бирергә тырышабыз. Ни өчен? Чөнки Рамазан аенда Аллаһы Сөбеханәһү

вә Тәгалә эшләгән һәрбер гамәл өчен калган айлардагы фарыз әҗерен бирер, ди. Тиздән Рамазан ае җитә, шул сәбәпле, хөрмәтле кардәшләрем, нисабка ия булсак, зәкятләрне кемнәргә бирергә булачагын уйлап куйыйк, ин шә Аллаһ, саваплары арттырылып кайтачак. Рамазан ае үтү белән, шәүвәл аеның беренче көнендә, ураза гаете намазы укылганчы, зәкятнең бер төре булган садака – фитыр садакасы бирелә. Ибне Гомәрдән килгән хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән:

«Ураза гаете көнне, бәйрәм намазына чыгар алдыннан, мөселман булган һәркемгә – колга һәм ирекле кешегә, ирләргә һәм хатын-кызларга, олысына һәм кечесенә – бер сагъ хөрмә яки арпа күләмендә садака өләшү фарыз ителә» . Сагъ – ул 5142,5 граммга тигез үлчәү берәмлеге.

Кадерле дин кардәшләрем, зәкят – Исламның өченче баганасы булып тора. Әгәр зәкят түләнелмәсә, Аллаһы Тәгалә яңгырларны туктатыр; Кыямәт көнендә ул байлык елан булып килер. Шулай ук, зәкятне биргәндә бары тик сыйфатлы маллардан гына бирергә онытмыйк. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә ихлас мөселманнардан, Үзенең яраткан колларыннан булырга насыйп әйләсен иде.

*Ирек хәзрәт Җиһаншин,*
*«Хәләл» комитеты җитәкчесе,*
*«Утыз Имәни» мәчете имам-хатыйбы*

*3 май вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Рамазан аена рәхим итегез!

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Берничә көннән бик бәрәкәтле бер айга – Рамазанга – аяк басачакбыз, ин шә Аллаһ. Рамазан – мөселман тәкъвименең 9 нчы ае. Рамазан сүзе гарәп телендәге «рамада» сүзеннән һәм ул «кайнар», «эссе булу» дигәнне аңлата. Бу ай Гарәп ярымутравындагы бик эссе һава торышына туры килә торган була. Соңгы елларда безнең Татарстан җирлекләрендә дә ураза эссе һәм озын җәй айларына туры килеп барды. Аллаһыга шөкер, 19 сәгатьләп уразалар тоттык, әмма бер генә кешенең дә килеп: «Хәзрәт, быел авыррак булды», – дип әйткәне булмады. Бу – Аллаһының рәхмәте. Һәм шуны да искәртеп үтәргә кирәк: елдан-ел ураза тотучылар саны арта гына барды. Бер ел ураза тотып караган кеше, икенче елларда үзенең дусларына, туганнарына да ураза тотарга киңәш итә башлыйлар. Бу да бит Рамазан аеның бер фазыйләте. Аның кешегә ясаган тәэсире.

Безнең якларда исә бу айны «ураза ае» дип тә йөртәләр. Әлбәттә, моның да үз нигезе бар, чөнки Рамазан ае дигәч, нәкъ менә ураза күз алдына килә. Әмма ураза тоту бу айда гына булмаганлыктан, Рамазанны аның белән генә чикләргә ярамый. Дөреслектә, бу бик фазыйләтле, бүләкләргә бай ай. Аллаһы Тәгалә бу айны калган айлардан аерып куйды. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бу ай турында бик күп хәдисләр әйтеп калдырды. Һәм шул фазыйләтләрнең кайберләрен бүгенге вәгазебездә карап китәрбез, ин шә Аллаһ.

Аллаһы Тәгалә өчен иң якын гамәлләр нинди гамәлләр? Әлбәттә, фарыз, Ул Үзе тиеш дип билгеләгән гамәлләр. Шуңа күрә аларны үтәгән өчен әҗер-савабы да, үтәмәгән өчен гөнаһы да күбрәк. Аннан соң сөннәт, аннан мөстәхәб һәм башка гамәлләр.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

> **«Ий мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки аңа кимчелек китерүдән сакланырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Әбү Габдрахман Габдулла бине Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһе сөйләгән: «Мин Аллаһы Илчесенең: «Ислам биш терәккә нигезләнә: «Аллаһыдан башка илаһ юк, Мөхәммәд – Аның Илчесе» дип шәһадәт бирү, намаз уку, зәкят түләү, хаҗ кылу, Рамазанда ураза тоту», – дип әйткәнен ишеттем». Пәйгамбәребез әлеге хәдистә берничә фарыз гамәлне санап китә һәм шулар арасында Рамазан аенда ураза тоту да бар. Димәк, беренче фазыйләтле гамәл – Рамазан аенда без Аллаһыга якын булган гамәлне кылабыз икән. Бераз гына аңа тукталып та үтик.

Ураза гарәп телендә «саум» – «тыелу» дигәнне аңлата. Күрәсезме, һәрбер гамәл нәрсә дә булса эшләргә чакыра: намазны хәрәкәтләр кылып укырга, садака бирер өчен кая да булса барырга кирәк, дәрес бирер өчен сөйләргә, аңлатырга кирәк. Ә саум дигән сүз, киресенчә, нәрсәне дә булса эшләмәскә, тыелып торырга куша. Рамазан аенда без ашау-эчүдән генә түгел, ә бөтен гөнаһлардан тыелып торырга тиешбез, югыйсә без уразабызга зур зыян китерергә мөмкинбез.

Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам: «Мөэмин ураза тотып та, ачлыктан башка бернәрсәгә дә ирешмәскә мөмкин», – дип әйткән. Рамазан аенда безнең күзебез дә, колагыбыз да, телебез дә, йөрәгебез дә ураза тота. Ураза тотучының йөрәге тәкәбберлектән, көнчелектән, икейөзлелектән, ачудан пакь булыр. Болар турында, ин шә Аллаһ, алдагы җомгаларда тулырак сөйләшеп китәрбез әле.

Шулай ук, ураза тоту – Аллаһыга гыйбадәт итү. Һәрбер гыйбадәт чисталык (госел) белән эшләнелә, шуңа күрә ураза тотканда да пакь, горселле булу хәерле. Ураза тотар алдыннан түбәндәге сүзләрне (гарәпчә) укып, тел белән ният кылу мөстәхәб санала:

نَوَيْتُ أَنْ أَصُومَ شَهْرِ رَمَضَانَ مِنَ الْفَجْرِ إِلَى الْمَغْرِبِ خَالِصًا لِلّٰهِ تَعَالَى

Нәүәйтүән әсуумә саумә шәһри рамадаанә минәл-фәҗри иләлмәгъриби хаалисан лилләәһи тәгааләә.

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә өчен, ихласлык белән таң вакытыннан башлап, кояш батканчыга кадәр Рамазан уразасын тотарга ният кылдым».

Кояш баткач ниндидер ризык, тоз яки су белән ифтар кылу, ягъни авыз ачу – сөннәт. Хөрмә кебек татлы җимешләр белән ифтар кылу – мөстәхәб.

Ифтардан соң (авыз ачканнан соң) түбәндәге дога укыла:

اَللّٰهُمَّ لَكَ صُمْتُ وَبِكَ أٰمَنْتُ وَعَلَيْكَ تَوَكَّلْتُ وَعَلَى رِزْقِكَ أَفْطَرْتُ

فَاغْفِرْ لِي يَا غَفَّارُ مَا قَدَّمْتُ وَمَا أَخَّرْتُ

Әллааһүммә ләкә сумтү вә бикә әмәнтү вә галәйкә тәүәккәлтү вә галәә ризкыйкә әфтартү фәгъфирлии йәә гаффәәру мә каддәмтү вә мәә әххартү.

Мәгънәсе: «Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым, Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Синең ризалыгың белән авыз ачам. Әй гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка».

Рамазан аеның тагын бер фазыйләте булып шәйтаннарның ай буе богауда булулары тора. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Рамазан аенда җәннәт капкалары ачык булыр, җәһәннәм капкалары бикле булыр, шәйтаннар чылбырда булыр», – дип әйткән. Бу исә вәсвәсә кыла торган шәйтаннарның булмавы, шуңа да бик күп итеп изге гамәлләр кылып калу мөмкинчелеге була дигәнне аңлата. Ә кем дә кем үзен изге гамәлләр кылырга ияләштерә, ул Рамазаннан соң да шулай ук дәвам итәчәк. Гомумән, кешенең уразалы булган көне, уразасыз көненнән аерылып торырга тиеш. Ә шәйтаннарның богауда булуы моңа ярдәм итә. Шушы ук хәдистә җәннәт ишекләренең ачылуы һәм җәһәннәм ишекләренең ябылуы хакында әйтелә. Бу да Рамазан ае хөрмәтенә мөэмин-мөселманнарга Аллаһыдан бер бүләк.

Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип искәртә: «Кем дә кем (Рамазанда) Аллаһыга бер нәфел гамәл эшләп якынайса, калган айларда фарыз гамәлне кылган кебек, ә фарыз гамәл кылган кеше – 700 фарыз гамәл кылган кебек булыр». Шуңа да Рамазан аенда бик күп нәфел намазлар укып, садакалар биреп калырга өлгерергә кирәк, чөнки мондый мөмкинчелек елга бер генә килә.

Шулай ук Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Аллаһы Тәгалә бу айда ураза тотуны фарыз, ә төннәрен намаз белән үткәрүне сөннәт итеп кылды», – дип әйткән. Галимнәребез «төннәрен намаз

белән үткәрү» дигәнне тәравих намазы дип әйтәләр. Чыннан да, Рамазан аенда уразадан кала икенче зур гамәл – ул тәравих намазы. Тәравих намазы Рамазан аенда укыла. Ул 20 рәкәгатьтән тора. Тәравих намазы ирләр һәм хатыннар өчен, ураза тотучылар өчен дә, берәр төрле авыру яки сәфәрдә булу сәбәпле, ураза тотмаучылар өчен дә сөннәт мүәккәдә булып санала. Тәравих намазын мәчеттә уку – сөннәт, аны үтәгән өчен зур савап вәгъдә ителгән. Әмма әлеге намазны өйдә берүзең укысаң да ярый.

Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Рамазан аенда, бу айның изге ай икәнлегенә ышанган хәлдә һәм әҗер-савабын бары тик Аллаһыдан гына өмет итеп тәравих намазын кылучыга аның барлык элеккеге гөнаһлары кичерелә», – дип әйткән. Шулай ук ул: «Аллаһы Рамазан аенда ураза тотуны сезнең өчен бурыч иткән. Ә мин исә аның төнендә кыямда торуны, ягъни тәравих намазын сөннәт иттем. Кем иманлы йөрәк белән, савап алу теләге белән Рамазан аенда ураза тотса һәм тәравих намазын укыса, гөнаһлардан котылыр, яңа туган сабый бала сыман булыр»[1], – дип әйткән.

Тәравих намазын бары тик ястү намазыннан соң гына укырга була. Рамазан аенда витр намазы тәравих намазыннан соң укыла. 20 рәкәгатьле тәравих намазында сәламне һәр ике рәкәгатьтән соң яки һәр дүрт рәкәгатьтән соң бирергә була. Тәравих сүзе «ял итеп алу» дигән сүздән килеп чыккан. 20 рәкәгатьле тәравих намазын 5кә бүлеп ял итүебез дә шуны аңлата. Шушы ял итү вакытында түбәндәге зикерне әйтү динебездә күркәм гамәлләрдән булып санала. Гадәттә, аны мәкам белән, матур итеп көйләп укыйлар.

سُبْحَانَ ذِي الْمُلْكِ وَالْمَلَكُوتِ سُبْحَانَ ذِي العِزَّةِ وَالعَظَمَةِ وَالْقُدْرَةِ
وَالْكِبْرِيَاءِ وَالجَبَرُوتِ سُبْحَانَ الْمَلِكِ الْحَيِّ الَّذِي لَا يَمُوتُ سُبُّوحٌ قُدُّوسٌ

[1] Имамнар Әхмәд бине Хәнбәл һәм Ән-Нәсаи хәдисләр җыентыгыннан.

رَبُّنَا وَ رَبُّ الْمَلاَئِكَةِ وَ الرُّوحِ لاَ إِلَهَ إِلاَّ الله نَسْتَغْفِرُالله نَسْأَلُكَ الْجَنَّةَ وَ نَعُوذُبِكَ مِنَ النَّارِ

«Сүбхәәнә ẓил-мүлки вәл-мәләкүүт. Сүбхәәнә ẓил-гыйззәти вәл-газамәти вәл-кудрати вәл-кибрияя-и вәл-җәбәруут. Сүбхәәнәл-мәликил-хәййил-ләẓии ләә йәмүүт. Сүббүүхүн куддүүсун раббүнә вә раббүл-мәләәикәти вәрруух. Ләә иләәһә илләллааһу нәстәгъфируллааһ. Нәс'әлүкәл җәннәтә вә нәгууẓү бикә минән нәәр».

Мәгънәсе: Яшерен вә ачык булган һәрнәрсәнең Иясе чиста Пакь. Көч-Куәт, Бөеклек, Күркәмлелек Иясе Пакь. Ул Мәңге исән һәм беркайчан да үлмәс. Камиллек Иясе, Кимчелексез, Ул – безнең Раббыбыз, фәрештәләрнең һәм җаннарның Раббысы. Аллаһыдан башка илаһ юк һәм без Аннан гөнаһларыбызның ярлыкавын сорыйбыз. Йә, Раббым, без Синнән җәннәт сорыйбыз һәм ут газабыннан сыенабыз.

Бу намазны өйдә, әллә инде җәмәгать белән мәчетләрдә укыргамы, дип сораучылар да бар. Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Ул Рамазан аеның бер кичендә чыккач, мәчетләрдә кыйраәтне ишетеп һәм андагы ялтыраган кандилләрне[1] күреп: «Гомәр безнең мәчетләребезне Коръән белән нурландырган кебек, Аллаһы Тәгалә Гомәрнең каберен яктыртса иде», – дип әйткән. Гали радыяллаһу ганһенең сүзләре Рамазан аендагы тәравих намазы турында була. Шуңа күрә мөмкинлеге булган кеше тәравихны мәчеттә җәмәгать белән укыса, хәерлерәк. Шуңа өстәп, тәравихка җыелган халыкны күреп, калган кешеләр дә мәчеткә тартыла башлый. Кешеләрнең көне буе ураза тотып, кичләрен әле намазга да килүләрен күрүчеләргә, мәчеткә беренче адымнарын ясарга бу бик зур этәргеч булып тора ала.

Рамазан аеның тагын бер фазыйләте – авыз ачтыру. Ураза тотучыны авыз ачтырган кешегә ураза тотучыга ирешкән кадәр савап языла

1 Кандил – люстра.

ала. Ә ураза тотучыга савап билгеле түгел, аны Аллаһы Тәгалә Үзе билгели. Башка бер риваятьләрдә: «Ураза тотучыны авыз ачтырган кешегә бер кол азат иткән кадәр савап языла», – дип әйтелә. Һәм, әлбәттә, без бу форсатлардан файдалана белергә тиешбез.

Мөхтәрәм җәмәгать, без, чыннан да, бик фазыйләтле һәм бүләкләргә бик бай булган айга аяк басарга әзерләнәбез. Бу айга күп калмады, шуңа күрә үзебезне рухи яктан да, физик яктан да әзерләргә өлгергәнбездер, дип өметләнәм. Быел беренче тәравих намазы 5 нче май көнне укыла. Уразаны 6 нчы май көнне тота башлыйбыз. 4 нче июнь – Ураза гаете.

### Фидия

Рамазан аенда ураза тота алмаган кешеләр уразаларын башка айларда тота ала, уразаны бөтенләй тота алмаганнар исә фидия садакасы түләргә тиеш була. Фидия – ураза тотмаган көннәр өчен бирелә торган садака. Фидия акчалата түләнергә мөмкин.

Рамазан аеннан кала башка айларда тоткан уразалар бу ураза кебек саваплы булмас. Шуңа күрә бу айда көчебездән килгән кадәр изгелекләр кылып, намазлар укып калыйк. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә дә бу айны матур итеп каршы алып, күңелләребез, җаннарыбыз һәм тәннәребез үзгәргән халәттә озатып калырга насыйп әйләсә иде. Әмин!

*«Хозур» редакциясе*

*10 май вәгазе,*

*Рамазан аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Рамазан ае фазыйләтләре

Барлык мактау, хәмде-сәналәр дөньяларны барлыкка китерүче, барчабызны да һәрдаим нигъмәтләндереп торучы, һәр гамәлебезне белүче вә аның өчен гадел рәвештә хөкем итәчәк, Үз рәхмәтенә ирешүчеләрне мәңгелек җәннәткә һәм адашканнарны җәһәннәмгә кертәчәк Бөек зат – Аллаһыга булсын!

Соңгы пәйгамбәр итеп җибәрелгән, дөньяга Раббыбызның сүзләрен вә шәригатен тараткан, җәннәт ишеген беренче булып ачачак вә үзенең өммәтен – мөселманнарны беренчеләрдән булып анда алып керәчәк сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә салаватлар булсын.

Ихлас күңел белән, Аллаһының әмеренә буйсынып, дога һәм гыйбадәт кылу өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Изге җомга көнебез барчаларыбызга да мөбарәк һәм хәерле булсын!

Туган көн, яңа ел, әниләр көне кебек бәйрәмнәрне алдан ук көтеп алабыз. Без исә шундый ук зарыгу белән Рамазан аен да көтәргә тиешбез. Аллаһы Тәгалә безгә бу айны исән-имин килеш каршы алырга насыйп әйләде. Бүгенге вәгазебездә кыскача гына булса да Рамазан аеның фазыйләтләре һәм Рамазан аенда кылына торган хаталар турында сөйләшеп китәрбез.

Вакыт беркайчан да туктап тормый, ничек кенә Рамазан ае озаграк торсын дип теләсәк тә, ул барыбер узачак. Шуңа да, мөмкинлек булганда, Рамазан аен кадерлик. Әгәр дә безгә берәр кунак килергә җыенса, без өйләребезне җыештырабыз, кунакларны матур итеп каршы алабыз, алар безнең өйдә булганда үзебезне дә бүтәнчәрәк, гадәти итеп тотмыйбыз,

ә киткәндә, моңсуланып озатып калабыз. Рамазан ае бик кадерле кунак, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Әгәр Рамазан аеның нинди фазыйләтле икәнен белсәләр, алар аның мәңге булуын теләрләр иде», – дип әйткән.

Уразаның дәвамлыгы бер ай. Кемдер өчен бу артык күп булып тоела аладыр. Әмма, беренчедән, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

لَا يُكَلِّفُ اللَّهُ نَفْسًا إِلَّا وُسْعَهَا ﴿٢٨٦﴾

**«Аллаһы Тәгалә һичкемне көче җитмәгән эш белән йөкләмәс, мәгәр көче җиткән эш белән йөкләр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:286

Икенчедән, Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең: «Рамазан – сабырлык ае. Сабырлыкның савабы исә җәннәттер», – дигән хәдисен дә исебезгә төшерик. Рамазан тулысы белән бәрәкәтле ай: аның иртәсе дә, киче дә, көндезе дә, төне дә бәрәкәтле. Гадәттә, ураза тотмаучы кешегә уразаны тотарга киңәш итсәң, ул төрледән-төрле акланулар эзли башлый: «Хәзрәт, мин бит ашамыйча тора алам, әмма мин су эчмичә тора алмыйм», яки: «Минем эштә сүгенмичә генә эшләп булмый, шуңа миңа ураза тотудан да файда юк инде», – дигән кешеләр бар. Әмма Аллаһы Тәгалә сау-сәламәт кешегә уразаны фарыз итеп кылган икән, димәк, бу кешегә бернинди авырлык китерми. Ә телләрен сүгенүдән, гайбәттән туктата алмаган кешеләр Рамазанда шул гамәлләреннән генә булса да тукталып торсалар, бу да алар өчен бертөрле ураза булыр иде. Ураза – тыелып тору дигәнне аңлата да бит. Әйе, әлбәттә, шәригать ягыннан караганда, ураза – Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен дип, таң беленгәннән алып, кояш баеганчыга кадәр ашау-эчүдән, якынлык кылудан тыелып тору. Әмма уразага илтә торган һәрбер адым – кадерле адым. Бүген кеше үзен тәрбия кылам дип, берәр төрле гөнаһтан тыелып торыр, икенче көнне ул инде уразасын да тота башлар, ин шә Аллаһ. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «...Бу

айның башы – рәхимлелек, уртасы – гөнаһларны гафу итү, азагы – ут газабыннан азат ителүдер. Шуңа күрә бу айда 4 төрле гамәлне күбрәк эшләгез: икесе Аллаһы сездән разый була торган, ә икесе үзегезгә үк бик кирәкле гамәлләр. Беренче ике гамәл – шәһадәт китерү һәм тәүбәләр кылу. Икенче ике гамәл – Аллаһыдан җәннәт сорап, Аңа ут газабыннан сыенудыр», – дип әйткән. Кадерле җәмәгать, бу айны үзебезнең рәхимлегебез һәм юмартлыгыбыз белән тутырсак иде.

Юмарт вә Рәхимле Аллаһы Тәгалә Үз колларын да бер-берләренә карата рәхимле вә юмарт булырга өнди. Рамазан ае ул – ярышу ае. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм иң юмарт кешеләрнең берсе иде, ә Рамазанда ул тагын да юмартрак булган. Хәдисләрдә әйтелгәнчә: «Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам яхшы гамәлләр кылуда искән җилгә караганда да юмартрак иде».

Рамазан аен шартлы рәвештә 3 кә бүлеп карасак та, бу айда, чыннан да, мәрхәмәтлегебезнең чиге, тәүбәләребезнең саны булмаска тиеш. Һәм, әлбәттә, бигрәк тә соңгы ун көнлектә безнең игътибарлылыгыбыз артырга тиеш. Беренчедән, бу вакыт – уттан азат итү ункөнлеге, икенчедән, Кадер кичәсе дә шушы ункөнлектә яшеренгән. Өченчедән, «кунакның китү вакыты җитә», ягъни бу – Рамазанның соңгы көннәре. Мондый форсат кабаттан нибары бер елдан соң гына җитәчәк.

## Рамазан аенда кылына торган хаталар

Хата дип әйтү бик үк туры килмәсә дә, бу пунктларны шулай дип исемләдек.

Беренче хата булып Рамазан аенда ураза тотмау тора. Ни өчен? Чөнки ул фарыз гайн дәрәҗәсендәге гамәл. Ислам динендә фарыз гамәлләр бар икәнен беләбез, шуңа күрә аларны калдыру – Аллаһы каршында гөнаһлы булу дигәнне аңлата. Кем дә кем Аллаһы Тәгаләгә ышана, фарызларны таный икән – аңа акрынлап аларны үти башларга кирәк. Шулай булганда,

Кыямәт көнендә фарыз кылынган гамәлләр өчен соралганда, җавап бирү җиңел булыр. Аннан соң, безнең күпме сәламәтлекләре зәгыйфь булган дусларыбыз бар. Алар теләсәләр дә, ураза тота алмыйлар. Без Аллаһыга шөкер кылып, гыйбадәтләребезне башкарырга тиешбез.

Икенчесе – Рамазан аенда барлык игътибарны бары тик ризыкка гына юнәлтү. Күп еллар ураза тоткан кешеләр алдарга мөмкинлек тә, ирек тә бирмәсләр: авыз ачканда кеше кайчан туена? Дөрес, су эчеп куйгач та. Инде ахшам намазыннан соң бер тәлинкә аш ашаганнан соң, ашказаны башка ризыкны сорамый да. Әмма Рамазан аен: «Бүген ифтарга нәрсәләр әзерлим икән?» – дип кенә үткәрсәк, без аны шул ашау өчен генә көткән кебек булабыз. Моңа да игътибар итсәк иде. Ә инде тәмле ризыклар көненә килгәндә, ул бар – Ураза гаете бәйрәме. Менә аны чын бәйрәм итеп, дуслар-туганнар бергә җыелып билгеләп үтүне гадәткә кертсәк була, чөнки ул мөселманнарның рәсми бәйрәме булып санала.

Алдагысы – күп еллар ураза тотып та, намаз турында уйламау. Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә: «Кыямәт көнендә иң беренче соралачак нәрсә – ул намаз», – дип әйтелә. Иң яхшы ысул – акрынлап җомга намазларына йөри башлау. Шуңа күрә моңа да игътибарлы булсак иде.

Тагын бер хата: Коръән укымау.

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ﴿١٨٥﴾

**«Рамазан ае – бик шәрифле ай, ул айда Аллаһыдан кешеләргә туры юлны күрсәтә һәм һидаятьне ачык бәян кыла торган Коръән иңдерелде».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Коръәни Кәрим – Аллаһы Тәгаләнең сүзе. Без исә Аллаһы Тәгалә безгә нәрсәне кушкан, нәрсәне тыйган икәнен белергә, Коръәни Кәримне

нинди максат белән иңдергәнен аңларга тырышырга тиешбез. Шуңа күрә, Рамазан аенда булса да, бу китапка тагын да күбрәк игътибар итәргә тиешбездер.

Алдагысы – вакытны бушка сарыф итү. Югарыда Рамазан ае бик фазыйләтле ай дип әйтеп үттек. Шуңа күрә бу айдан файдаланып калмау гөнаһ булмаса да, хата саналыр. Бу дөньяда изгелек кылуга караганда, гөнаһ җыю җиңелрәк килеп чыга. Менә шуңа күрә Аллаһы Тәгалә бүләк иткән һәр форсаттан файдалана белергә тиешбез: Рамазан һәм башка шундый кичәләрдә изгелекләрне күбрәк эшләп калырга ашкынырга кирәк. Сәхәр ашагач, ифтарга кадәр йоклап яту, яки кирәксез гамәлләргә вакытны сарыф итү – әлбәттә, хатадыр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә искә төшереп:

أَيَّامًا مَّعْدُودَاتٍ ﴿١٨٤﴾

**«Ураза санаулы көннәр»,** – дип әйтә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:184

Чыннан да, Рамазан ае нибары 29-30 көн генә. Боларның кадерен белсәк иде: Рамазан аенда кылган бер изге гамәл калган айларда кылган гамәлгә тиң түгел. Аның әҗер-савабы бик күп тапкыр артык языла.

Вәгазебезнең ахырында Рамазан аена карата бер киңәш бирәсе килә: Кадер кичәсен эзләгез. Соңгы 10 көндә, көн саен 10 гына сум булса да садака бирегез, ике генә рәкагать булса да намаз укыгыз һәм 3 тапкыр «Ихлас» сүрәсен укыгыз. Әгәр сездә йөз сум гына булып, аны бер көндә садака итеп бирсәгез, Кадер кичәнә эләкмәсегез бар. Ә 10 сумлап көн саен биреп барсагыз, бу кичне тоту мөмкинлеге арта. Шулай ук «Ихлас» сүрәсен 3 тапкыр уку – бөтен Коръәнне укуга тиң. Бер генә көнне эзләп, аннан да колак какканчы, бу рәвешле гамәл кылу Кадер кичәнә эләгергә мөмкинчелек бирәчәк.

Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә тоткан уразаларыбыз, укыган намазларыбыз өчен шатланышып, Әр-Раян ишекләреннән, Аллаһы Тәгалә Үзе вәгъдә иткән җәннәтләргә керергә насыйп булса иде. Әәмин!

*«Хозур» редакциясе*

*17 май вәгазе,*

*Рамазан аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Рамазанда да гөнаһларны калдыра алмасак...

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн, әммә бәгъде: барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә булса иде. Һәм дә салават-шәрифләребез Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтуһ.

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, без даими рәвештә Аллаһы Тәгаләгә хәмед-сәналәребезне әйтәбез. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, Аның сөекле илчесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребезне җиткерәбез. Аеруча шушы айда – Рамазан-шәрифтә гыйбадәтләребезне тагын да арттырабыз. Намазларыбызны мөмкин кадәр камилрәк укырга тырышабыз. Вакытында уку турында сүз дә юк – монысы намазның шарты. Фарыз намазларын мәчеттә җәмәгать белән уку җаен табарга тырышабыз. Уразаларыбызны төп-төгәл итеп тоту өчен көч куябыз. Сәхәргә торабыз. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтенә ияреп, аның: «Сәхәрдә – бәрәкәт», – дигән сүзләренә итагать итеп, шул вакытта Аллаһы Тәгалә биргән тәгамнәр белән ризыкланабыз. Ифтарларга йөрибез. Вәгазьләнәбез. Машинада барганда җырлар түгел, ә Коръән тыңлыйбыз. Егерме рәкәгать тәравихларда да торабыз. Нәфел гыйбадәтләрен өстәргә тырышабыз.

Әмма, Рамазан үттеме – барысы да онытыла. Шушы бәрәкәтле көннәр ничек килеп җиткән булса, шулай ук үтеп тә китәчәк. Бер ияләшкән гадәт белән биш вакыт намазга мәчеткә йөрербез. Шәүвәлдә ураза да тотарбыз. Ләкин гаеттән ерагайган саен Рамазан дәресләрен онытабыз... Мәчеткә җомгага гына киләбез. Нәфелләрне калдырабыз. Изгелектән ерагаябыз.

Нигә? Чөнки бәрәкәтле Рамазан аенда да, күпме генә гыйбадәт кылсак та, гөнаһтан арына алмыйбыз. «Ничек инде, хәзрәт?! Ураза тотам бит. Намаз укыйм бит. Гөнаһ кылырга вакытым юк бит», – диярсез. Чынлыкта, без гөнаһлы тормышка шулкадәр ияләшкән ки, аны сизмибез дә. Рамазан ае уразасы, биш вакыт намаз – болар фарыз гыйбадәт, без аларны үтәргә тиеш. Кылмыйбыз икән – гөнаһлы булабыз. Бу безнең изге бурычыбыз, аның белән масаясы түгел. Масайсаң, бу – рия, ягъни гамәл-гыйбадәтеңне Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен түгел, башкалар күрсен, мактасын, синнән көнләшсен өчен кыласың.

Рамазан ае – айларның солтаны. Шушы айда Аллаһы Тәгалә Коръәнне иңдерә башлады. Шулай ук бу айда Кадер кичәсе бар. Раббыбыз ул кичә турында Коръәни Кәрим китабында болай дип әйтә:

لَيْلَةُ الْقَدْرِ خَيْرٌ مِّنْ أَلْفِ شَهْرٍ ﴿٣﴾

**«Кадер киче савабы мең айдан да хәерлерәк, мең ай кылган гыйбадәттән артыгырактыр».**

«Кадер / Кадер Киче», 97:3

Бу айда шәйтаннар богауда булалар, без үз нәфесебез белән генә калабыз. Нәрсә эшлибез, нәрсә кылабыз, нинди сүз сөйлибез – барысын да үзебез кылабыз. Берәүне дә гаепли алмыйбыз.

Шуңа да бу айда гөнаһлардан тыелу, күңелебездә кыек эшләргә карата тиешле мөнәсәбәт тәрбияләү мөһим. Чынлыкта, адәм баласының нәфесе гөнаһка ияләшә. Башта кечкенә генә ялгышлык та аның күңелен

борчый. Аннары калебтәге шул тап зурайганнан зурая бара. Һәм кеше олы гөнаһларга да кереп китүен сизми кала. Раббыбыз Үзе сакласын.

Рамазан аенда гыйбадәтләребезне арттырып, фарыз гамәлләребезне кылу дәрәҗәсен күтәреп, без нәфесебезне тагын да тәрбиялибез. Еш кына: «Хәзрәт, бер танышым бар, Рамазанда ураза тота, үзе намаз да укымый, яулык та япмый», – дип сорыйлар. «Үзең ураза тотасыңмы?» – дип сорасаң: «Юк», – дип җавап бирә. Намаз да укымый. Әйе, намаз укымау – гөнаһ. Ураза тотмау да гөнаһ. Ләкин Аллаһы Тәгалә кемнең дә булса күңеленә ураза тоту теләгеn салды икән – шул орлыкны үтермик. Үзебездән башлыйк. Бәлки шул Рамазанда ураза тотканнан соң кеше намазга да басар. Ифтарларга йөреп, вәгазьләнер. Ялгыш юлда булуын аңлар, хаталар төзәтү өчен тырыша башлар.

Әлхәмдүлилләһ, Рамазан ае җитү белән мәчетләребез тула. Бүген әле намаз укымаган кардәшләребез дә, кимендә, гөнаһлардан сакланырга тырыша. Кайбер авыллардагы, төбәкләрдәге кибетләрдә, әйтик, харам сату тыела. Кеше тәмәке тарта икән – тартмаска тырыша, аракы эчә икән – шушы айда тыелып тора. Ин шә Аллаһ, аларның шул рәвешле нәфесләрен җиңәргә тырышуы җавапсыз булмас. Башта харамнан читләшер, аннан гыйбадәтләрен кыла башлар. Аллаһы Тәгаләнең сөекле бәндәләреннән булыр, ин шә Аллаһ. «Син әле намаз да укымыйсың, ничек ураза тотасың», – дип әйтәбез икән – шәйтанга ярдәм итәбез, димәк, аның эшен эшлибез. адәм баласын гыйбадәттән читләштерәбез. «Синең Рамазан аенда гына гөнаһтан тыелып торуыңнан ни файда?» – дип күңелләрен төшермик. Һәм икейөзлелектә гаепләмик. Киресенчә, булышыйк: ифтарга чакырыйк. Берәрсе гөнаһлардан тыелырга ихтыяр көче тапмый икән – күркәм нәсыйхәт кылыйк.

Ә моның өчен үзебезгә гөнаһлардан арыну кирәк. Хаклыкка кайтыр өчен Рамазаннан да хәерлерәк чор юк. Әгәр дә Рамазан-шәрифтә гөнаһлы гамәлләрдән, яман фикерләрдән тыела алмыйбыз икән – баш-

ка вакытта бу бик авыр биреләчәк. Рамазан – ул мәдрәсә. Рамазан – ул тәрбия. Һәм шул дәресләрдән мөмкин кадәр күбрәк файда алу өчен калебебезне гөнаһлардан чистарту кирәк. Кем Рамазанда ураза тотып та, ач кылу дәрәҗәсен генә алса, ни үкенеч аңа. Ни үкенеч шул кешегә, кем төннәр буе тәравихлар укып та, төне буе уяу торган кебек кенә саналса. Һәм ни үкенеч шул кешегә, кем Рамазан аен гамәл-гыйбадәттә үткәреп тә, гөнаһлары ярлыкланмаса.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! «Гөнаһлардан арыныйк дигән сүз миңа кагылмый, әнә, уразасыз, намазсыз кеше кайгырсын», – дип уйламыйк. Уразалы килеш тә гайбәттән арына алмыйбыз. Раббыбыз ураза тотучыларны җәннәткә Әр-Раян дип аталган капкадан кертер, ин шә Аллаһ. Һәм бу капкадан ураза тотучылардан гайре башка беркем кермәс. Шул дәрәҗәне күршебезне, туганыбызны «чәйнәүгә» алыштырабызмы? Рамазан аенда, аеруча Кадер кичәсендә кылынган изгелегебез өчен савап мең тапкырга кадәр җитәргә мөмкин. Раббыбызның рәхмәте киң, шул рәхмәтне бозык сүзгә алыштырабызмы? Ураза килеш тә талашудан тыелмыйбыз. Рамазанда да күз зинасыннан оялмыйбыз. Тапкан малыбыз хәләлме? Әллә ифтарларда яман юл белән килгән ризыклар белән авыз ачабызмы? Рамазан – ул уйлану ае. Өстеңнән хисап тотканчы, үз-үзеңә хисап тоту ае.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләре Рамазаннан соң ярты ел дәвамында әле Аллаһы Тәгаләдән уразаларын кабул итүне сорыйлар иде. Ялварып дога кылдылар. Без исә ярым-йорты уразабыз кабул булуына шиксез ышанабыз. Ураза кабул булуның бер билгесе булып безнең Рамазаннан соң да гамәл-гыйбадәтләребезне киметмәвебез; Рамазанда гөнаһлардан сакланып, шул яшәү рәвешен дәвам итүебез тора.

Зәгыйфьлегебезне җиңик. Көчле мөселман булыйк. Үз нәфесебезгә хуҗа булыйк. Рамазан аенда күңелебезне пакьлик. Ураза гаетенә анадан туган сабый сыман гөнаһсыз килик. Раббыбыз һәрберебезгә шундый

мөмкинлек биргән – шушы шәрәфле айның бәрәкәтен күңелләребезгә сеңдерик. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*24 май вәгазе,*

*Рамазан аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Ураза тотуның фазыйләтләре

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, сезгә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, сәламе вә бәрәкәте булса иде!

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Рамазан ае килү белән җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла, ә шәйтаннар богауланып куела», – дип әйткән. Бу хәдисне Әбү Давыдтан кала башка 5 олуг мөхәддис тә китерәләр. Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазанның беренче төне җитү белән шәйтаннар һәм тыңлаусыз җеннәр богауланып куелалар. Җәһәннәмнең ишекләре ябыла һәм аларның берсе дә ачылмый. Җәннәт ишекләре ачыла һәм аларның берсе дә ябылмый. Соңыннан бер кычкыручы: «Йә, яхшылык теләүче, монда кил. Йә, начарлык теләүче, тукта», – дип кычкырыр. Һәм һәрбер кичәдә Аллаһы Тәгаләнең уттан котылган бәндәләре булыр», – дип әйтте.

Бу хәдискә шәрех бирүче галимнәр «Җәннәт ишекләре ачыла» дигән гыйбарәне Аллаһы Тәгаләнең җиргә бик күп нигъмәтләре иңә, дип аңлаттылар. Шулай ук бу айда шәйтаннар богауга куела. Рамазан

ае – гамәлләр өчен бик күп саваплар языла торган һәм шулай ук начарлыклар өчен дә гөнаһ дәрәҗәсе арта торган ай. Шәйтаннарның булмавы кешегә изгелекләрне күбрәк кылырга, явызлыклардан читләшергә булыша. Бу хәдистән аңлашылганча, шәйтаннар белән җеннәр бер сүз түгел. Шәйтан – «шәтана», ягъни «ерагайган» дигән сүздән барлыкка килгән һәм Аллаһының рәхмәтеннән ерагайган дигәнне аңлата.

Алга таба Пәйгамбәребез: «Соңыннан бер аваз бирүче: «Йә, яхшылык теләүче, монда кил. Йә, начарлык теләүче, тукта», – дип кычкырыр», – дип әйтә. Рамазанда яхшылык кылуга чакыру да, яхшылыкны эшләү дә бик күп савапларга ия. Шулай ук гөнаһ дәрәҗәсе артканга күрә, тукталып торырга кушыла.

Иң соңыннан: «Һәм һәрбер кичәдә Аллаһы Тәгаләнең уттан котылган бәндәләре булыр», – дип тәмамлады. Кайбер галимнәребез моны һәр кичтә дип, ә кайберләре авыз ачкан вакытта була, дип әйттеләр. Әмма, ничек кенә булмасын, Аллаһы Тәгалә Рамазан аена тагын бер бүләк биргән, ул да булса – җәһәннәмгә керергә лаеклы кешеләрне дә Аллаһы Тәгалә бу ай хакы-хөрмәтенә уттан азат итә икән.

Рамазан аенда иң олуг гыйбадәтләрнең берсе – ураза тоту.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки аңа кимчелек китерүдән сакланырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Ураза – Ислам диненең биш баганасының берсе, ягъни фарыз кылынган гамәл. Бохари хәдисләр җыентыгында мондый хәдис китерелә:

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Ураза – калкан булып тора, ураза тоткан кеше һәрбер әдәпсез эштән читләшсен һәм үзен дорфа кешеләр кебек тотмасын. Әгәр дә берәр кеше аның белән талашырга теләсә яки тирги башласа, ике тапкыр: «Мин уразадамын», – дип әйтсен. Җаным Аның кулында булган (Аллаһы) белән ант итәм, ураза тотучының авызыннан килгән ис Аллаһы Тәгалә каршында ислемайга караганда да якынрак. Һәм Аллаһы Тәгалә: «Ул ашау-эчүдән һәм теләкләреннән Минем өчен тыелып тора. Бу уразасын да ул Минем өчен тота һәм аның өчен әҗерен дә Мин Үзем бирермен, ә (кылган) бер изге гамәл өчен (әҗер-савабы) ун тапкыр артык булачак», – дип әйтте». Ураза тотуның нигезе – тыелып тору. Без бу айда ашау-эчүдән, начар гамәлләрдән, начар сүзләрдән (гайбәт, ялган, бохтан, яла ягу һ.б.) читләшеп торабыз, чөнки бу уразаның кабул булу шарты да булып тора. Әмма бу калган айларда әлеге гамәлләрне кылырга ярый, дигән сүз түгел, киресенчә, бу айда үзеңне тәрбияләп, калган айларда да шундый ук яшәү рәвеше алып барырга кирәк.

Уразаның тагын бер фазыйләте – авыздан килгән иснең Аллаһыга күркәм булуы. Ураза тотучыларның күбесе ул исне авызда барлыкка килә дип уйлыйлар. Әмма табиблар аны ашказаны чистару белән бәйләп аңлаталар. Кеше ураза тота-тота, ашказанындагы тупланган матдәләрдән арына башлый. Шуңа күрә ураза тотучы гыйбадәт кылып кына калмый, шуңа өстәп үзенең сәламәтлеген дә яхшырта икән.

Тагын бер фазыйләт: ураза тоткан өчен әҗер-савапны Аллаһы Тәгалә Үзе билгели. Әгәр намаз укыган өчен фәлән-фәлән кадәрле, садака өчен фәлән кадәрле дип сөйләнсәк тә, ураза өчен савапның билгеле булмавының берничә уңай ягы бар. Беренчедән, кеше ураза өчен бик күп савапларга өмет итә ала, чөнки 10, 20 генә дип әйтелмәгән. Икенчедән, кеше: «Мин 30 көн буе ураза тоттым, минем инде шуның кадәрле изгелекләрем бар», – дип, үз-үзен юата алмый һәм шулай итеп, тәкәбберлектән саклана.

## «Әр-Раян» ишекләре

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Җәннәттә Әр-Раян дигән бер ишек бар. Кыямәт көнендә бу ишектән бары тик ураза тотучылар гына керәчәк. Аннан ураза тотучылардан башка берәү дә керә алмаячак. «Ураза тотучылар кайда?» – дип әйтелер һәм алар алга чыгачак. Алардан кала бу ишектән беркем дә кермәячәк. Ураза тотучылар (бу ишектән) кергәч, ул ишекләр ябылачак һәм бүтән беркем дә алардан кермәячәк», – дип әйткән.

Җәннәтнең ишекләре турында ишеткәнебез бар, әлбәттә. Кем дә кем күп итеп намаз укыды, аларны намаз ишегеннән, кем күп итеп садака бирергә гадәтләнде, аны садака ишегеннән җәннәткә чакырырлар. Пәйгамбәребез тагын бер хәдисендә болай дип әйткән: «... Ураза тотучыларны җәннәткә «Әр-Раян» ишекләреннән, садака бирүчеләрне садака ишегеннән чакырырлар». Моны ишеткәч, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе: «... Ә һәрбер ишектән дә чакырылучы кеше булырмы икән?» – дип сораган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аңа: «Әйе, һәм мин син ул кешеләр арасында булырсың, дип өметләнәм», – дип җавап кайтарган.

Бу хәдисләрдән ураза тотучыларга җәннәттә аерым бер ишек барлыгы билгеле. Һәм Кыямәт көнендә барлык халык каршында ураза тотучылар алга чыгып, җәннәткә шул ишектән керерләр, ин шә Аллаһ. Ә ни өчен Пәйгамбәребез Әбү Бәкергә шундый сүзләр әйтә соң? Чөнки Әбү Бәкер көн саен барлык төр изге гамәлләрне эшләп калырга тырышкан. Көн саен намаз да укыган, көн саен садака да биргән, җеназа намазларында да катнашкан, авыруларның хәлләрен белгән һ.б. Рамазан аенда, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһедән үрнәк алып, күп итеп изгелекләр кылып калырга ашыгырга кирәк. Һәм шулай эшләгәндә генә, Рамазан ае тәрбиясе ел буена җитәр, ин шә Аллаһ.

Әлбәттә, уразаның фазыйләтләре моның белән генә чикләнми. Вәгаземнең ахырында кыска гына берничә хәдис китерәсем килә:

«Ураза тотучыны сөендереп, кәефен күтәрәчәк ике нәрсә бар. Берсе – ифтар вакытында уразадан чыкканда сөенү, икенчесе – Кыямәт көнендә уразаның савабы белән сөенү»;

«Ураза – ул кешене җәһәннәм утыннан саклый торган калкан»;

«Чисталык, пакьлек – иманның яртысы, ураза – сабырлыкның яртысы»;

«Сәхәр ашагыз, дөреслектә, сәхәрдә бәрәкәт бар».

Кадерле җәмәгать, иң могтәбәр айларның берсе – Рамазан аенда атлыйбыз. Аллаһы Тәгалә тоткан уразаларыбызны, укыган тәравих намазларыбызны, биргән садакаларыбызны, яшерен һәм ачык кылган изгелекләребезне кабул кылса иде. Әәмин!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

*31 май вәгазе,*

*Рамазан аеның 26 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Кадер кичәсе

Рамазан аен ел буе сагынып көтсәң дә, изге көннәр сизелми дә үтә. Көн арты көн Раббысына тугры бәндә кадерле вакытларны изге гамәл, Коръән укуга багышлый. Тоткан ураза калебләрне йомшарта, торган кыямнар кешене сабыр, әхлаклы итә, укыган аятьләр гафиллектән уята. Тән итагать кыла, тел зикер итә, җан уйлана, гыйбрәт ала.

Кунакның китәр вакытлары җиткәч, кадере арта. Шулай ук Рамазанның ахыргы 10 көне дә безнең өчен аеруча гыйззәтле. Ул көннәрдә иман әһеленең изгелекләре өстәлә, «Рәхмәтенә ирешермен, гөнаһымнан пакьләнермен, уттан котылырмын», – дигән өметләр арта. Гайшә радыяллаһу ганһә: «Аллаһы Илчесе Рамазанның ахыргы ун көнендә башка көннәргә караганда ныграк иҗтиһад, тырышлык күрсәтте» , – дип әйткән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам ул көннәр турында болай дигән: «Рамазаның ахыргы 10 көне – ул җәһәннәм газабыннан котылу көннәре» .

Рамазан ае бәгыренең иң күркәм почмагында Коръән иңдерелгән Кадер кичәсен яшереп тота. Бер орлыктан үсеп чыккан агачта меңләгән җимешләр җитешкән кебек, Кадер кичәсенә дә мең ай йөкләнгән.

Бу кичәдә әҗер-саваплар бергә – мең бәрабәрендә языла. Бу кичәнең тулы кадерен һәм кыйммәтен бары ачлыктан нечкәрә-нечкәрә сизгерләнгән күңелләр генә аңлый һәм тоя ала. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

إِنَّا أَنزَلْنَاهُ فِي لَيْلَةِ الْقَدْرِ ﴿١﴾ وَمَا أَدْرَاكَ مَا لَيْلَةُ الْقَدْرِ ﴿٢﴾

لَيْلَةُ الْقَدْرِ خَيْرٌ مِّنْ أَلْفِ شَهْرٍ ﴿٣﴾ تَنَزَّلُ الْمَلَائِكَةُ وَالرُّوحُ فِيهَا بِإِذْنِ
رَبِّهِم مِّن كُلِّ أَمْرٍ ﴿٤﴾ سَلَامٌ هِيَ حَتَّىٰ مَطْلَعِ الْفَجْرِ ﴿٥﴾

**«Хактыр ки, Без Коръәнне (Ләүхел-Мәхфүздән дөнья күгенә) Кадер кичендә төшердек. Сиңа Кадер киче дигәне нәрсәне белдерә? Кадер киче – мең айдан да хәерлерәктер. Ул кичтә һәртөрле эш өчен Раббыларының рөхсәте белән фәрештәләр һәм Җәбраил галәйһиссәлам иңәр. Ул төннең таңына кадәр иминлек, сәламәтлек булыр».**

«Кадер / Кадер Киче», 97:1-5

Ни өчен соң ул төн «Кадер киче» дип аталды?

Кадер – ул «кодрәт», бу төн Аллаһы каршында иң кодрәтле һәм иң хөрмәтле төндер. Кадер төнен Коръән иңү белән үзенчәлекле иткән Аллаһы ул төннең тагын бер өстенлеген бәян итеп: **«Кадер төне мең айдан хәерлерәк»**, – дип әйтә. Ул төнне догада, гыйбадәттә, зикердә, намазда үткәргән бәндә мең ай гыйбадәт кылудан да зуррак әҗер алачактыр. Мең ай ул 83 ел һәм 4 ай була.

Ул төндә җир йөзенә Аллаһы кешеләргә тәкъдир кылган һәрбер яхшы вә яман эш белән Җәбраил галәйһиссәлам һәм башка фәрештәләр төшәләр. «Ул таң беленгәнче иминлектер», ягъни Кадер төнендә җир өстенә төшкән фәрештәләр бәрәкәт, тынычлык һәм хәерлелек белән төшәләр. Бигрәк тә ул фәрештәләр Коръән укучылар, Аллаһыны зикер итүчеләр һәм гыйлем эстәүчеләр белән бергә булалар. Шәйтан да ул төнне үзенең мәкерлекләрен кыла алмый.

Кадер төне кайчан була? Мөселманнар өчен айлар арасында Рамазан ае, көннәр арасында җомга көне, кичләр арасында Кадер кичәсе иң мөбарәк санала. Кадер кичәсе Рамазан-шәриф аенда булган бер кичәдер.

Шул ук вакытта Рамазанның кайсы кичәсендә булганы төгәл һәм анык рәвештә билгеләнмәгән. Бу мәсьәләдә галимнәр төрле фикердә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Кадер төне – Рамазанның ахыргы ун төнендә. Кем аларны уяу үткәрә, Аллаһы аның кылган һәм кылачак гөнаһларын кичерә. Бу да так санлы төндә: тугызынчы, жиденче, бишенче яки өченчесендә», – дип әйткән.

Әбү Зәрр радыяллаһу ганһе: «Без Рамазан аенда Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергә ураза тотканда, уразаның соңгы җиде көне калган иде. Һәм егерме өченче төндә ул безнең янга төн уртасында намаз укырга чыкты. Егерме дүртенче төндә безнең янга чыкмады, ә егерме бишенчесендә төн уртасында чыкты. Аннары мин аңа: «Әй Аллаһының Илчесе! Бәлки сиңа төнге намазны үткәрергәдер?» – дидем. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр бу төнне берәр кеше имамга ияреп намаз укыса, бу – төне буе укыган намазга тиң була», – дип җавап бирде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм егерме алтынчы төндә безнең янга чыкмады. Төннәрнең егерме җиденчесендә ул үзенең хатыннарын, гаилә әгъзаларын һәм башка кешеләрне җыйды һәм намазны шундый озак итеп укыды ки, хәтта без сәхәр ашауны калдырудан курыктык. Калган төннәрдә ул безнең янга чыкмады», – дип риваять кылган.

Кадер төненең үз галәмәтләре бар. Галимнәр билгеләп үткәнчә, Кадер кичәсен кайбер галәмәтләрдән, шул кичкә хас булган аерым билгеләрдән тәгаенләргә мөмкин: бу кичә нурлы, тыныч һәм матур булыр; бик салкын да, бик эссе дә булмас; ул кичтә болытлар йөрмәс һәм җил исмәс, һавадан йолдызлар атылмас, яңгыр яумас, барча җиһанда тылсымлы тынлык урнашыр. Шул төн арты кояш нурсыз, пакь тулы ай кебек чыгар.

Кадер кичәсе гыйбадәте: бу кичә Аллаһының рәхмәте бик мул булган бер кичәдер. Көндез ихтыяҗы булганнарга мөмкин кадәр ярдәм итәргә, авыз ачканда фәкыйрьләрне ашатып-эчерергә, кичен Коръән укып,

гыйбадәт кылып үткәрергә кирәк. Гыйбадәттә каза намазын кылу, Коръәни Кәримнән сүрәләр, догалар уку, тәүбә итү, садака бирү, мөселманнарны сөендерү һәм башка саваплар казану – болар барысы да бу кичәгә хөрмәт күрсәтүнең ишарәседер. Хөрмәт күрсәтү гөнаһлы эшләрне эшләмәү белән дә хасил булыр.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәү, Аллаһы Тәгаләгә инанып һәм савабына өметләнеп, Кадер кичәсен гыйбадәт кылып уздырса, элек кылган гөнаһлары гафу ителәчәк», – дип әйткән.

Шулай ук кайбер риваятьләрдә Кадер кичәсендә иң азы – ике рәкәгать, уртача – йөз рәкәгать, ә иң күбе – бер мең рәкәгатьле намаз укылуы хәбәр ителә .

Бу намазны нәкъ шушы рәвешле уку мәҗбүри түгел, әмма аны шушылай уку мәслихәт булуын хәбәр итә торган риваятьләр бар. Төп максат булып исә мөселманнарның бу төнне гыйбадәт һәм зикердә үткәрүе тора.

Пәйгамбәрбез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, дүрт хәлифә радыяллаһу ганһүм һәм соңыннан бөтен Ислам дәүләтләре бу кичәгә олуг хөрмәт күрсәткәннәр, гыйбадәттә үткәргәннәр.

Кадер кичәсендә укыла торган дога:

Хәзрәти Гайшә радыяллаһу ганһәдән риваять ителә: «Йә, Расүлуллаһ, Кадер кичәсенең кайсы кичә икәнен белсәк, ул кичтә ни дип әйтергә кирәк?» – дип сораганыма Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу доганы укырга кушты:

اَللَّهُمَّ إِنَّكَ عَفُوٌّ كَرِيمٌ تُحِبُّ الْعَفْوَ فَاعْفُ عَنِّى

«Аллаһуммә иннәкә гафүвүң кәриимүң, түхиббүл гафүә, фәәгъфү ганни».

«Йә, Аллаһым, һичшиксез, Син гафу кылучы, Син юмарт, Син гафу итәргә яратасың, мине гафу ит»

Кадер кичәсендә Аллаһы Тәгалә адәмнәренә чиксез нигъмәтләр насыйп итәр. Бу кичәдә күңел күзләренә илаһи нурдан сөрмә тарткан саф мөэминнәр хакыйкать офыкларының йолдызлары кебектер.

## Фитыр

Рамазан аенда фитыр садакасы һәм зәкят билгеләнә. Фитыр садакасы бирү һәр мөселманга да вәҗиб гамәлләрдән санала. Фитыр садакасы мохтаҗларга бирелә. Фитыр садакасын мөселман булмаганнардан һәм фәкыйрьләрдән тыш, бар кеше дә бирергә тиеш. Фитырны гаилә башлыгы барлык гаилә әгъзалары һәм аның тәрбиясендә булган кешеләр өчен үзенең кеременнән түли. Ир бала балигъ булуга, фитырны үзе өчен үз кеременнән түләргә омтылырга тиеш. Андый мөмкинлеге булмаган очракта, бу бурыч гаиләдәге башка ир-атлар өстенә төшә.

Безне Рамазаныбызда саулык-сәламәтлектә кавыштырган Аллаһы Тәгаләгә мактау, зурлауларыбыз вә шөкерләребез булсын! Тагын да күп еллар дәвамында Рамазаннар морадына ирешергә насыйп әйләсен. Әәмин!

*«Хозур» редакциясе*

# Ураза гаете хөтбәсенең гарәпчә укылышы

خطبة عيد رمضان

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اَللّٰهُ وَاَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ ❁ سُبْحَانَ مَنْ نَوَّرَ قُلُوبَ الْعَارِفِينَ بِنُورِ الْمَعْرِفَةِ وَالْإِيمَانِ وَشَرَحَ صُدُورَ الصَّادِقِينَ بِشَرْحِ الْهِدَايَةِ وَالْعِرْفَانِ وَأَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ ❁ اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اَللّٰهُ وَاَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ ❁ سُبْحَانَ مَنْ فَتَحَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ الرَّحْمَةِ وَالْغُفْرَانِ وَزَيَّنَ قُلُوبَ الْمُحِبِّينَ بِتِلاَوَةِ الْقُرْآنِ وَغَلَّقَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ النِّيرَانِ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ❁ وَعَدَ لِلصَّائِمِينَ دُخُولَ بَابٍ مِنْ أَبْوَابِ الْجِنَانِ كَمَا أَخْبَرَنَا نَبِيُّنَا نَبِيُّ آخِرِ الزَّمَانِ: إِنَّ لِلْجَنَّةِ بَابًا يُقَالُ لَهُ الرَّيَّانُ لاَ يَدْخُلُهُ إِلاَّ الصَّائِمُونَ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ، شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنْزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ❁ اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اَللّٰهُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ ❁ وَأَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللّٰهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ ذُوالْعَفْوِ وَالْغُفْرَانِ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَهَادَةً نَاطِقَةً بِالْحُجَّةِ وَالْبُرْهَانِ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى آلِهِ وَأَصْحَابِهِ صَلاَةً مُوصِلَةً إِلَى دَارِ الْجِنَانِ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى أَبِي بَكْرٍ الصِّدِّيقِ وَ عُمَرَ الْفَارُقِ وَ عُثْمَانَ ذِي النُّورَيْنِ وَ عَلِيٍّ الْمُرْتَضَى الْأَئِمَّةِ رِضْوَانَ اللّٰهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ❁

أَمَّا بَعْدُ: أَيُّهَا النَّاسُ، أُوصِيكُمْ عِبَادَ اللهِ وَنَفْسِي أَوَّلاً بِتَقْوَى اللهِ ۞ أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوا وَّالَّذِينَ هُم مُّحْسِنُونَ ۞ بَارَكَ اللهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرآنِ الْعَظِيمِ وَنَفَعنَا وَإِيَّاكُمْ بِالْآيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَّادُ الْكَرِيمُ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ السَّمِيعُ الدُّعَاءِ

## خطبة ثانية

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذَ بِاللهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ ۞ إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا اَللَّهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ عَلَى جَمِيعِ الْأَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ وَعَلَى أَهْلِ طَاعَتِكَ أَجْمَعِينَ مِنْ أَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرَضِينَ ۞ اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ وَارْحَمْنَا مَعَهُمْ وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

# Ураза гаете хөтбәсенең кириллицага транслитерациясе

## Беренче хөтбә

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән нәввәра кулүүбәл-гаарифиинә би нуурил-мәгърифәти вәл-иимәән, вә шәрахә судүүрас-саадикыйнә би шәрхил-һидәәйәти вәл-гыйрфәән, вә әкрамә гыйбәәдәһүл-мү’миниинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Сүбхәәнә мән фәтәхә галәс-саа’имиинә әбүәәбәр-рахмәти вәл-гуфраан, вә зәййәнә кулүүбәл мүхиббәйни битиләәвәтил Куръәни, вә галләка галәс-саа’имиинә әбүәәбән-нииараани фи шәһри рамәдаан. Вәгадә лис-саа’имиинә дүхуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбиййүнәә нәбиййү әәхириз-зәмәән: иннә лил-җәннәти бәәбән йүкаалү ләһүр-раййәән. Ләә йәдхулүүһү илләс-саа’имүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһрү рамәдаанәлләҙии үнзилә фииһил-куръәәнү һүдәл-линнәәси вә бәййинәәтин минәл һүдәә вәл-фүркаан, Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһуу ҙүл-гафьүи вәл-гуфраан, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһуу. Шәһәәдәтән нәәтыйкатән билхүҗҗәти вәл бүрһәәни. Салләллааһу Тәгаалә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи саләәтән-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән. Хусуусан минһүм галәә Әби Бәкринис-Сыйддикый вә Гумәрал-Фәәрукый вә Гуҫмәәнәз-ҙиннүрайни вә Галийинил-Мүртәдал ә-иммәти, ридъвәәналлааһи галәйһим әҗмәгыийнә.

Әммә бәгьдү: әййүһәннәәс, үсыйкүм гыйбәәдәллааһи вә нәфсии әүвәлән-битәкъүәллааһ. Әгуузу билләәһи минәш шәйтаанир-раҗиим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааһә мәгалләҙиинәт-тәкау

вәлләẕиинә һүм мүхсинүүн. Бәәракәллааһү ләнәә вә ләкүм фил-куръәәнил-газыйим, вә нәфәганәә вә иййәәкүм бил-әәйәәти үәẕẕикрил-хәкиим, иннәһуу һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүл-галиййүл-газыйиму сәмиигуд-дүгаа'.

## Икенче хөтбә

Иннәл-хәмдә лилләәһи нәхмәдүһуу вә нәстәгыйнүһу вә нәстәгъфируһу вә ну'минү биһии вә нәтәүәккәлү галәйһи вә нәгуузү билләәһи мин шүруури әнфүсинәә вә мин сәййиәәти әгъмәәлинәә мән йәһдииһилләәһү фәләә мүдыйллә ләһүү вә мән йүдълилһү фәләә һәәдиә ләһ. Вә әшһәдүән ләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһ, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһ. Иннәллааһә вә мәләә-икәтүһү йүсаллүүнә галәннәбиййи. Йәә әййүһәл-ләẕиинә әәмәнүү саллү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли вә сәллим галәйһи вә галәә җәмигыйль-әнбийәә'и вәл-мүрсәлиин, вә галәә мәләә'икәтикәл-мүкаррабиин. Вә галәә гыйбәәдикәс-саалихыйн, вә галәә әһли таагатикә әҗмәгыйн, мин әһлис-сәмәүәәти үәл-арадыйн. Аллаһүммә-гъфир лилмү'миниинә вәл-мү'минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәәи минһүм вәл-әмъүәәт, вәрхәмнәә мәгаһүм. Үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәәмәр-раахимиин.

# Ураза гаете хөтбәсенең татарчага тәрҗемәсе

## Беренче хөтбә

Мәрхәмәтле, шәфкатьле Аллаһы Тәгалә исеме белән.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыга гына мактау. Аллаһы Тәгаләгә якынаючыларның (гарифләрнең) күңелләрен (калебләрен) мәгърифәт (ярлыкау) һәм иман нуры белән нурландырган, тугрыларның (садыйкларның) күңелләрен һидаять һәм белем белән ачкан, мөэмин колларына Рамазан ае уразасын бүләк иткән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Рамазан аенда ураза тотучыларга рәхмәт һәм мәгъфирәт (гөнаһларны гафу итү) ишекләрен ачкан һәм ут ишекләрен бикләгән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Ул (Аллаһы Тәгалә) ураза тотучыларга җәннәт ишекләренең берсе аша керүне вәгъдә иткәндер. Бу турыда безгә Пәйгамбәребез, ахырзаман пәйгамбәре хәбәр иткән: «Чынбарлыкта, җәннәтнең бер ишеге бардыр, аңа «Раййән» диелә. Ул ишектән Рамазан аенда ураза тотучылардан башка беркем дә кермәс». Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: «Рамазан ае кешеләргә туры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр». Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк, Ул гафу итүче һәм мәгъфирәт иясе (гөнаһларны каплаучы) икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм расүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аңа, аның гаиләсенә, сәхабәләренә Аллаһы Тәгаләдән булган җәннәт йортларына илтә торган салават ирешсен. Әй кешеләр! Аллаһы Тәгаләнең коллары, сезгә һәм үземә дә тәкъвалы булырга васыять итәм. Таш белән атылган

шәйтаннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: «Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә тәкъвалылар һәм игелек кылучылар белән бергә». Аллаһы Тәгалә безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Чынбарлыкта, Ул (Аллаһы Тәгалә) гафу итүче, рәхимле, юмартлык иясе, олуглык иясе, бөек Зат һәм догаларны ишетүче, кабул итүче.

## Икенче хөтбә

Чынбарлыкта, барча мактау Аллаһы Тәгаләгә, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Аллаһы Тәгаләгә үзебезнең начарлыкларыбыздан, гамәлләребезнең бозыклыкларыннан сыгынабыз. Кемгә Аллаһы Тәгалә һидаять бирсә – аны адаштыручы булмас, ә кемне адаштырса – аны туры юлга күндерүче булмас. Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм хак илчесе икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аллаһым, бөтен пәйгамбәрләргә, илчеләргә, Үзеңә якынайтылган фәрештәләреңә, Үзеңнең изгелек кылучы колларыңа һәм Сиңа итагать итүче әһелләрнең һәммәсенә – булсыннар алар күк әһелләреннән һәм булсыннар алар җир әһелләреннән – барчасына салават һәм сәлам ирештер. Аллаһым, мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, алар арасыннан исән вә вафат булганнарын мәгъфирәтең белән гафу ит. Алар белән берлектә безгә рәхимле бул һәм безне Үз рәхмәтең илә алар белән бергә булырга насыйп ит. Йә рәхимлеләрнең иң рәхимлесе.

*4 июнь вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Ураза гаете вәгазе

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылучы, шул галәмнәрне тәрбия кылып һәм Үзенең төрле нигъмәтләре белән бүләкләп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмде-сәналәребез, олуглауларыбыз булса иде. Безне хак юлга күндерүче, барчаларыбызга иң күркәм үрнәк булучы, сөекле, нурлы пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, барлык сәхабәләренә күңелләребезнең түрләреннән чыккан сәламнәребез, салават-шәрифләребез һәм һәртөрле изге догаларыбыз ирешсә иде.

Тәннәребезне арулап, пакь киемнәр киеп, Аллаһы Тәгаләнең чиксез рәхмәтенә һәм ризалыгына ирешер өчен Гыйдел-фитыр намазына җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем! Сезне динебезнең иң күркәм сәламе белән сәламлим: әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Барчаларыбызга Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең сәламнәре, бәрәкәтләре һәм рәхмәтләре булса иде.

Газиз дин кардәшләрем, ватандашларым, мәчетебезне олуглап килгән хөрмәтле кунаклар! Бүген – бәйрәм, мөселманнарның ай буе ураза тотып, зарыгып көтеп алган көне, ике олуг бәйрәмебезнең берсе – Изге Рамазан гаете. Һәркайсыгызны шушы мөкатдәс көн, бөек бәйрәм, Гыйдел-фитыр көне белән ихлас күңелдән тәбрик итәм! Шушы көннең вәгазе, хөтбәсе, бергә җыелып намаз укуыбыз ихласыбыз ныгуына, дуслыгыбыз көчәюенә, бер-беребезгә булган мәхәббәтебезнең артуына, Аллаһыга

якынаюыбызга, Аның сөекле коллары булуыбызга һәм дә ике дөньяның бөек дәрәҗәләренә ирешүебезгә сәбәп булсын!

Ай буе Аллаһы ризалыгын өмет итеп ураза тоттык. Аллаһы Тәгалә тоткан уразаларыбызны кабуллардан кылса иде!

Рамазан аеның дәрәҗәсе турында пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Рамазан ае – айларның хуҗасыдыр»[1].

Рамазан ае керсә, Гомәр радыяллаһу ганһе: «Хуш килдең безне пакьләүче», – дип әйтә торган булган. Рамазан аенда ураза тоту – Ислам дине әркәннәренең берсе. Бу айда күк капуслары ачылып, бөтен галәмгә Аллаһының рәхмәте тарала. Рамазанда кылынган гыйбадәтләргә әҗер-савап башка айларга караганда күбрәк бирелә һәм адәм баласының гөнаһлары гафу ителә. Шуңа күрә без бу айда дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче миллионлаган дин кардәшләребез кебек үк ураза тоттык, тәравих намазларына йөрдек, изге гамәлләрне күбрәк кылырга тырыштык, күңелләребезне пакьләдек, иманнарыбызны ныгыттык.

Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки аңа кимчелек китерүдән саклансыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Аллаһы Тәгалә Үзенең колларына битараф түгел. Ул ай буе ураза тотуны йөкли һәм ураза тотуны безгә җиңеләйтә.

---

[1] Имам Бәйһакый хәдисләр җыентыгыннан.

Ураза тотучыга җиңеллек булсын өчен аны котыртып торучы шәйтаннар богаулана, аның өчен җәннәт ишекләре ачыла һәм җәһәннәм ишекләре ябыла. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Рамазан ае башланса, җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла һәм шәйтаннар чылбырлар белән богаулана»[1].

Уразаның мәгънәсе нәрсәдән гыйбарәт соң? Ураза сүзе «тыелу» дигәнне аңлата. Ураза тотучы кеше таң атканнан алып кояш баеганчыга кадәр ашау-эчүдән, җенси мөнәсәбәтләрдән тыелып торырга тиеш. Әмма ураза камил булсын өчен, без шулай ук ялган, гайбәт, начар сүзләр сөйләү кебек гөнаһлардан да үзебезне сакларга тиеш. Бу турыда сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Кем уразалы була торып та ялган-гайбәттән тукталмаса (тыелмаса) – аның ач йөрүеннән бернинди файда юк», – дигән[2], ягъни үзен мөселман дип таныган кеше уразаны сәламәтләнергә яисә ябыгырга дип түгел, үзен рухи яктан камилләшү өчен тотарга тиеш. Аллаһы Тәгалә Үзенең Китабында:

وَسَارِعُوا إِلَىٰ مَغْفِرَةٍ مِّن رَّبِّكُمْ وَجَنَّةٍ عَرْضُهَا السَّمَاوَاتُ وَالْأَرْضُ أُعِدَّتْ لِلْمُتَّقِينَ ﴿١٣٣﴾

**«Яхшылык эшләргә, тәүбә кылырга ашыгыгыз, җәннәткә ашыгучылардан булырсыз. Ул җәннәтнең киңлеге җир һәм күкләр кадәрдер. Ул җәннәтләр тәкъвалар өчен әзерләнде»,** – дип әйткән.

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:133

Шушы ук сүрәнең 134 аятендә Аллаһы Раббыбыз болай ди:

الَّذِينَ يُنفِقُونَ فِي السَّرَّاءِ وَالضَّرَّاءِ وَالْكَاظِمِينَ الْغَيْظَ وَالْعَافِينَ عَنِ النَّاسِ ۗ وَاللَّهُ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ ﴿١٣٤﴾

---

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

2 Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

**«Аллаһы Тәгалә, чыннан да, шатлыкта да, кайгыда да малларын сарыф итүчеләрне, ачуларын тыючыларны һәм кешеләрне гафу итүчеләрне, изгелек эшлүчеләрне ярата».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:134

Без аеруча шушы сөекле бәйрәм көннәрендә яхшылык эшләргә ашыгырга тиешбез. Үз калебләребезне чистарту, күркәм сүзләр сөйләү, гайбәткә кермәү, кешене гаепләмәү, ялганламаска тырышу лазем.

Күпләребез Рамазан ае дәвамында уразалар тотты, ифтар мәҗлесләрендә катнашты яисә үзенең хәләл малларыннан ифтарлар үткәрде. Рамазан ае безнең һәрберебезнең күңеленә шатлык-сөенеч ае булып кереп урнашты. Уразаларыбызны кабуллардан кылып, Аллаһы Тәгалә икенче шатлыкка да ирешүебезне – ягъни Раббыбыз белән очрашуыбызны һәм дә вәгъдә ителгән Әр-Раян ишекләреннән җәннәтләргә керүебезне дә насыйп кылса иде.

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә омтылган мөселман Рамазан аенда үзе турында гына түгел, башкалар турында да, дине турында да кайгырта, булган малыннан зәкятен чыгара, гади садакалар биреп мохтаҗларның, ятимнәрнең күңелен күрә, Ислам дине үсешенә үзенең өлешен кертә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән:

«Нинди садака өстенрәк?» – дип сораганнар. Ул: «Рамазан аенда бирелә торган садака», – дип җавап кайтарган[1].

Хәер бирүченең гөнаһлары да кими. Мөгаз бине Җәбәлгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтеп калдырган: «Ураза – калкан сакчы булса, садака – су утны сүндергән кебек, гөнаһларны сүндерәдер».

Моның өстенә, садака бирүче Кыямәт көнендә күләгәдә булыр. Бу хакта хәдистә болай дип әйтелгән: «Сул кулы уң кулының садака бирүен

1 Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

белмәү дәрәҗәсендә яшереп садака бирүче кеше Кыямәт көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәт күләгәсенә лаек булыр»[1].

Кыямәт көненә гыйлемле кеше үзенең белеме, дога кылучы – намазы, ураза тотучы – уразасы белән, ә садака бирүче белем, намаз һәм ураза белән килер. Чөнки ул – мөселман кардәшләренең китапларын бастырган, намаз укучыларга мәчет төзеткән, ураза тотучыны авыз ачтырган. Ул боларның барысының да әҗерен алыр. Бу – Аллаһының кодрәте.

Садака бирү – үтәү (башкару) өчен иң җиңеле, ә шәйтан аны иң авыры итеп күрсәтә. Шуның өчен дә садака кешенең Исламга карашын билгели торган бер күрсәткеч булып тора. Ягъни, кеше садака бирсә, мохтаҗларга, ятимнәргә, авыр хәлдә калучыларга булышса, димәк, ул мөселман һәм Ислам диненә ярдәм итүче, әгәр мөмкинлеге була торып та, ярдәмен күрсәтмәсә – ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтеннән читләшүче.

Бер хәдис-шәрифтә болай әйтелә: «Кешедә булырга мөмкин булган иң начар нәрсә – кирәгеннән артык саранлык һәм куркаклык»[2].

Саран кеше башкаларның догасыннан һәм мәхәббәтеннән мәхрүм була. Әгәр андый кешеләр күбәйсә – ул җәмгыятьтә төрле бәла-казалар барлыкка килә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Зәкят түләмәгән халык, һичшиксез, яңгырдан мәхрүм булачак», – дип әйткән[3].

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды авыру балаларны дәвалау өчен матди ярдәм күрсәтү буенча хәйрия эшчәнлеген алып бара. Мәрхәмәтле кешеләр тарафыннан җыелган акчалар балаларның тернәкләнү һәм дәвалану курсларын үтү, катлаулы операцияләр бәясен түләр өчен тотыла. Фонд тәрбиясендәге сабыйларның күпчелеге ДЦПның авыр формаларыннан интегә һәм аз ке-

[1] Имамнар Бохари һәм Мөслим китерәләр.

[2] Имам Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

ремле, күпбалалы, тулы булмаган гаиләләрдә тәрбияләнә. «Тамчыдан күл җыела», – ди халкыбыз. Киләчәктә балаларыбызның язмышына битараф булмасак иде. Динебездә садака бирүнең әһәмияте шушы хәдистә аермачык күрсәтелә: «Сул кулы уң кулының садака бирүен белмәү дәрәҗәсендә яшереп садака бирүче кеше Кыямәт көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәт күләгәсенә лаек булыр»[1].

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Һиҗри исәп буенча быелгы – 1440 нчы елның изге Рамазан ае тәмамланды. Әмма: «Рамазан ае бетте», – дип, адәм баласы Бөек Раббыбызга гыйбадәтен һәм итагатен ташларга тиеш түгел. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَاعْبُدْ رَبَّكَ حَتَّىٰ يَأْتِيَكَ الْيَقِينُ ﴿٩٩﴾

**«Үлем килгәнгә кадәр Раббыңа гыйбадәт кыл!»**

«Хиҗер», 15:99

Рамазан аенда гына гыйбадәт кылып, изге ай тәмамлангач гыйбадәтләрне калдыру, мәчеттән һәм җәмәгатьтән ерагаю – зур хата һәм адәм баласы өчен куркыныч нәрсә. Чөнки мөселман булу бер Рамазан ае белән генә бәйле түгел. Кеше үлемнең кайчан киләсен белми, ул үлемгә һәм үлемнән соң киләчәк мәңгелек тормышка һәрвакыт әзер булырга тиеш.

Җәннәт белән җәһәннәм турында ишетеп кенә булса да белмәгән кеше хәзер сирәктер. Җәннәт тә мәңгелек, җәһәннәм дә мәңгелек һәм алар икесе дә кешеләр белән тулган булачак. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

«Кулында Мөхәммәднең җаны булган Зат белән ант итәм, әгәр мин күргәнне күргән булсагыз, аз көлер һәм күп елар идегез», – дигән. Аннан:

---

[1] Имамнар Бохари һәм Мөслим китерәләр.

«Әй, Аллаһының Илчесе, син нәрсә күрдең соң?» – дип сораганнар. Ул: «Җәннәтне һәм җәһәннәмне», – дип җавап биргән[1].

Беркем дә мәңгелек җәһәннәмгә керергә теләми, бөтен кешенең дә җәннәткә ирешәсе килә. Шулай булгач, өстебезгә йөкләнелгән гамәл-гыйбадәтләребезне үтәп калырга тырышыйк. Динебезне өйрәник, балаларыбызга дини тәрбия бирик, якыннарыбызны да дингә өндик. Бөтен җәмгыятебез белән диндә булганда гына төрле афәтләрдән, хәвеф-хәтәрләрдән имин булырбыз, ин шә Аллаһ.

Мөхтәрәм җәмәгать! Күпләр өчен Ислам диненә керешү ураза тотудан башланды. Кеше ураза тотып, иң әүвәл үзенең ризыкка булган нәфесен җиңә. Ул үзенең Аллаһы колы булуын аңлый, Раббысына итагать итә башлый, аның холкы тәрбияләнә, башкаларга мөнәсәбәте яхшыра. Аңа башкалар да иярә, җәмгыять рухи яктан савыга.

Аллаһы Тәгалә тоткан уразаларыбызны, укыган намазларыбызны, кылган изгелекләребезне, биргән садакаларыбызны кабуллардан кылсын, хата-кимчелекләребезне гафу итсен, күңелләребездә нинди изге теләкләребез, изге уй-ниятләребез булса – шуларга ирешергә, дингә яңа килүчеләргә ихласларын куәтләргә, гыйлем эстәүчеләргә хәерле, файдалы гыйлемнәр алырга насыйп әйләсен, балаларыбызга изге ният белән гамәл кылып, киләчәктә хәерле бәндәләр булуларын насыйп кылсын, үзебезгә сабырлыкны, күркәм холыкны, ихтирамны, күркәм мөгамәләне юлдаш кылсын. Изге бәйрәмебез барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын!

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

[1] Имам Әхмәднең Мөснәденнән.

*7 июнь вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Рамазан аеннан соң да гыйбадәтләрне киметмәгез

Барча галәмнәрне юктан бар кылучы Аллаһы Тәгаләгә дан вә мактаулар булсын. Шушы дөньяга укытучы итеп, галәмнәргә рәхмәт булып килгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләреннән чыккан салават вә шәрифләребез булса иде.

Рамазан ае тәмамланды. Ул – безнең Аллаһы Тәгаләгә ихлас гыйбадәт һәм гамәлләр кылуга өметләнгән, изге ниятләр белән көткән мөбарәк аебыз. Бу вакытта һәркайсыбыз үз алдына төрле максатлар куйды: һәр көн Коръәни Кәримне уку, аны дөрес итеп тулаем укып чыгу, нәфел намазларын арттыру, изге эшләрне күбрәк кылу, үз-үзебезне даими катгый тәртиптә тоту һәм бик күп шундый җитди эшләр алып барудан гыйбарәт булды. Без кайбер максатларыбызга ирештек, ә нәрсәләрдер әле авыр булып эшләнелми калды. Бүген күңелләребездә – төрле хисләр: үз-үзебездән риза булып бетмәү дә, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына өмет тә, һәрхәлдә, йөрәкләребездә барыбер Аллаһы Тәгаләнең бу мөбарәк ае тәмамланудан җиңел хәсрәт һәм сагыну тора.

Аллаһы Тәгалә безгә күп төрле рәхмәтләрен ирештереп тора. Шуларның иң зурлары – ул гыйбадәт. Рамазан аендагы ураза – иң зур гыйбадәт. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ
لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки аңа кимчелек китерүдән сакланырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Белгәнебезчә, Рамазан аенда кеше үз нәфесе белән көрәшә, шәйтаннар богаулана. Һәм шушы айда ихласлылык арта. Мәчет юлын бер тапкыр да таптамаган кешеләр мәчетләргә киләләр. Фарыз намазларын, тәравих намазларны укып, уразалар тота һәм шушы халәт ай буе дәвам итә, чөнки кешенең җаны Аллаһының рәхмәтенә бик сусаган була. Әмма Рамазан ае бетү белән бу ләззәт бетә, янә гади тормыш башлана. Тик мөселман кешесе шушы изге айда алган тәкъвалык дәрәҗәсен югалтмаска тиеш. Аз-азлап, ләкин дәвамлы булсын. Аз булса да, әмма дәвамлы булган эш нәтиҗәсен китерә. Бу хакта хәтта сөекле Пәйгамбәребез хәдисендә дә болай дип әйткән: «Ураза тотуның кабул ителү билгесе – ул мөселманнарның башка вакытта да ел буенча, Рамазан аендагы кебек, гыйбадәттә булуыдыр».

Димәк, Рамазан ае тәмамлангач та, безгә гыйбадәтне туктатмый, бер дәрәҗәдән икенчесенә үстерергә кирәк. Ураза тотулар һәр ай диярлек дәвам итәргә, шушы уразалар аша Аллаһыга якынаюны максат итеп куйсак иң хәерлесе шушы булыр.

Иманыбызның Рамазан аеннан башка да югары дәрәҗәгә ирешүенә ничек ирешергә, нинди гамәлләр кылырга соң? Менә аларның кайберләренә тукталып үтик:

1. Ният. Безнең һәр кылган эшебез, барлык гыйбадәтләребез дә Аллаһының ризалыгы өчен булырга тиеш. Шуңа да һәрбер хәрәкәтебезне, һәр гамәлебезне Аллаһының олуг исеме «Бисмилләһ» белән башлыйк.

2. Намаз. Тиешле булган биш вакыт намазларыбызны вакытында үтәргә тырышыйк. Шулай ук сөннәт һәм нәфел намазлар турында да онытмыйк.

3. Коръән уку. Рамазанда иң зур игътибар бирелә торган гыйбадәт – ул Коръәни Кәрим. Коръән һәр мөселман өчен иң мөһим китап. Аның Рамазан ае белән бәйләнеше бик нык, чөнки ул нәкъ менә шушы айда иңдерелде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм тау куышында булган вакытында, Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам килеп: «Укы», – дип әйтә. Шушы мизгелдән дөньялыктагы иң олы китапларның берсе – Коръән иңә башлый. Шул рәвешле, дөньяга Аллаһы Тәгаләнең соңгы рәхмәте иңә. Шушы китапны бүгенге көнгә кадәр ничә миллионлаган кеше укый, ятлый. Мөгаен, Коръән ул җир йөзендә иң күп укыла һәм ятлана торган китаптыр.

«Һәр көнне Коръәннән 10 бит яисә 1 җөз укыйм», – дип үз алдыгызга башкарып чыга алмаслык максатлар куймагыз. Укылган Коръән битләренең саны артыннан кумагыз, ул көненә 3 аять тә булырга мөмкин, ләкин сез ул аятьләрне ихлас тырышлык белән, күңелләрегезгә сеңдереп укысагыз, тәфсир ярдәмендә үзегезгә мәгънәсен ачыкласагыз, уйланып, тәмам төшенеп, тормышыгызда һәм гамәлләрегездә куллансагыз яхшы булыр. «Уйлап-фикерләп үткәргән төннең бер сәгате намаз өстендә торган төннән хәерлерәк», – дип әйтелгән хәдисләрдә.

Мөслим җыентыгында мондый бер хәдис бәян ителә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кыямәт көнендә Коръән аны укыган кешеләргә шәфәгать итәр». Шулай ук Тирмизи риваятендә китерелә: Кыямәт көнендә Коръән килер һәм: «Йә Раббым, Коръән укучыны бизә», – дип әйтер. Шушы адәмнең башына таҗ кидертерләр. Шуннан соң Коръән әйтер: «Йә Раббым, өстә аңа». Һәм аңа кадерле кием кидертерләр. Бераздан Коръән янә әйтер: «Йә Раббым! Разый бул аннан». Һәм аннан разый булырлар. Коръән укучыга әйтерләр:

«Укы һәм күтәрел». Һәр укылган аять өчен аңа әҗер-савап өстәрләр. Әнә шундый эчәлектәге хәдисләр шактый. Тагын нинди гамәлләр өчен шушындый дәрәҗәләргә ирешеп була? Коръән яңгыраган җирдә һәрвакыт нур булыр. Кайбер кешеләр Коръәнне укый белсәләр дә, аның мәгънәсенә төшенмәскә мөмкиннәр. Әмма аларга да Аллаһы Тәгалә Үз рәхмәте белән әҗерләрен насыйп кылыр. Ә кемдер төртелә-төртелә, авырлык белән укырга мөмкин. Хәдистә әйтелгәнчә, аның өчен дә әҗер булыр. Хәдистә китерелә: «Кем Коръәнне шома итеп, җиренә җиткереп укый, ул иң бөек дәрәҗәдәгеләр белән булыр. Ә кем инде аны төртелә-төртелә укый, укырга өйрәнә, аңа икеләтә әҗер булыр» .

«Коръәнне тавыш белән укучы ачык садака бирүчегә тиң, ә Коръәнне эчтән укучы, садаканы яшерен рәвештә бирүчегә тиң»[1].

Шулай ук бер хәдистә: «Үз өйләрегездә «Әл-Бәкара» сүрәсен укыгыз. Хакыйкатьтә, «Әл-Бәкара» сүрәсе укылган өйгә шәйтан керми», – дип әйтелә .

Коръәнне укыганнарын ишеткән очракта, шулай ук тынлык сакларга кирәк. Аллаһы Тәгалә Үз китабында болай дип әйтә:

وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَأَنصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ﴿٢٠٤﴾

**«Коръән укылганда яки Коръәннән вәгазь сөйләнгәндә ихлас тыңлагыз, сүз сөйләмичә, эш эшләмичә тик торыгыз! Шулай итсәгез, шаять, рәхмәт кылынырсыз».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:204

Бу әҗер-саваплар һәммәсе Коръәнне укыган, ятлаган, өйрәткән өчен бирелә. Аллаһы Тәгалә каршында Коръәнне хөрмәтләп яшәгән, ятлаган кешеләрнең дәрәҗәсе шундый зур.

4. Догада булу. Аллаһыга даими дога кылуда булырга кирәк. Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

---

[1] Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

وَالَّذِينَ يُؤْتُونَ مَا آتَوا وَّقُلُوبُهُمْ وَجِلَةٌ أَنَّهُمْ إِلَىٰ رَبِّهِمْ رَاجِعُونَ ﴿٦٠﴾

**«Сезнең Раббыгыз әйткән: «Сорагыз Миннән һәм Мин сезгә җавап бирермен. Дөреслектә, Миңа гыйбадәт кылудан өстен булганнар җәһәннәмгә кимсетелгән рәвештә кертелерләр».**

«Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:60

5. Белем эстәү. Күпләребез изге Рамазан аенда гыйлемнәрен арттырдылар – Коръәннән яңа аятьләр өйрәнелде, яңа китаплар укылды, яңа хәдисләр белән танышып, вәгазьләр тыңланылды. Хөрмәтле дин кардәшләрем, бу гамәлләребезне дәвамлы кылыйк, ирешкән үрләрдә тукталмыйк.

6. Нәфел уразалар. Шәүвәл аеның 6 көнендә ураза тоту хәерле икәнен күпләребез белә. Әбү Әюб Әл-Әнсари радыяллаһу ганһе риваять итә: «Аллаһының Расүле галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Кем Рамазан аенда һәм шәүвәл аеның 6 көнендә ураза тотса, гомере буе ураза тоткан кебек булыр». Моңа өстәп, булдыра алган хәтле, дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә, зөлхиҗҗә һәм мөхәррам айларының беренче атнасы көннәрендә һәм яңа туган һәр айның беренче өч көнендә, 13, 14, һәм 15 көннәрендә ураза тотарга мөмкин.

7. Юмартлык. Әгәр без Рамазан аенда саранланмасак, садакалар бирсәк, малларыбызны Аллаһы юлында сарыф итсәк, башка вакытларда да шул изге максатны онытмыйк.

8. Кардәшлек. Изге Рамазан аенда без барыбыз да вакытыбызны күбрәк дин кардәшләребез арасында уздырдык, бергәләшеп тәравих, җомга намазларын укыдык, ифтарларга йөрештек. Инде Рамазан үткәч тә, ишекләребез ябылмасын, дус-кардәшлек җепләре өзелмәсен иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Без һәрвакыт күңелләребезгә иманыбызның һәм гыйбадәтнең татлылыгын искәртеп торырга тиешбез. Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорап, алда санап үтелгән гамәлләрне һәрдаим

башкарырга тырышыйк. Киләсе Рамазанга никадәр үзгәрүебезне, башка кеше булуыбызны күрербез: иманыбыз да көчлерәк, йөрәкләребез дә пакь булыр, ин шә Аллаһ.

Кадерле дин кардәшләрем! Вәгаземне Коръән аяте белән тәмамлыйсым килә:

رَبَّنَا لَا تُزِغْ قُلُوبَنَا بَعْدَ إِذْ هَدَيْتَنَا وَهَبْ لَنَا مِن لَّدُنكَ رَحْمَةً ۚ إِنَّكَ أَنتَ الْوَهَّابُ ﴿٨﴾

**«Раббыбыз! Туры юлга кергән безнең йөрәкләребезне ялгышларга авышулардан сакла, безгә Үзеңнең рәхим-рәхмәтләреңне бир, дөреслектә, Син – Бирүче!»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:8

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба мөхтәсибенең яшьләр эшләре буенча ярдәмчесе,*

*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*14 июнь вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Мөселманның сөннәт буенча киенү рәвеше

Ислам – ул үз эченә кеше тормышының һәр өлкәсен алган дин. Безнең өчен ничек итеп туклану дөрес, ничек йокыга әзерләнү һәм йоклау файдалырак, хәерлерәк, гаиләдә, кешеләр белән мөнәсәбәтләрне кору ничек яхшырак – инде барысы да билгеле бит. Ә ни өчен билгеле? Чөнки Раббыбыз, безгә зур рәхмәтен күрсәтеп, Пәйгамбәребез галәйһиссәламне җибәрде. Һәм беләбез, Мөхәммәд пәйгамбәр – ул гади бер кеше иде, ул безнең кебек үк ашый-эчә, йоклый иде, аның гаиләсе дә, балалары да булды. Менә көндәлек тормышыбыздагы вак кына мәсьәләләр дә безгә шуннан билгеле. Мөселманнарга исә бары тик шуны өйрәнеп, гамәлдә үти башларга гына кирәк.

Шулай итеп, бүген без мөселманнарның киенү рәвеше хакында сөйләшербез. Җәй айлары җитте, күпләр ял итәргә, бакчаларда эшләргә, су коенырга мөмкин, кемдер даими рәвештә спорт белән шөгыльләнә. Менә монда киемгә кагылышлы сораулар туа да инде.

Беренчедән, Изге Китабыбызга мөрәҗәгать итик. Раббыбыз:

يَا بَنِي آدَمَ قَدْ أَنزَلْنَا عَلَيْكُمْ لِبَاسًا يُوَارِي سَوْآتِكُمْ وَرِيشًا ۖ وَلِبَاسُ التَّقْوَىٰ ذَٰلِكَ خَيْرٌ ۚ ذَٰلِكَ مِنْ آيَاتِ اللَّهِ لَعَلَّهُمْ يَذَّكَّرُونَ ﴿٢٦﴾

**«Әй адәм балалары! Без сезгә гаурәтләрегезне каплар өчен бер кием һәм (бизәнер өчен) зиннәт иңдердек. (Иман, Аллаһыдан курку, яхшы әхлак һәм гаурәт урыннарын каплау кебек). Тәкъва киеме моннан (бизәкле киемнәрдән) яхшырак. Бу**

**(киемнәрнең иңдерелүе) Аллаһының аятьләреннән, – бәлки, алар (нигъмәтләребез турында) уйлап карарлар (һәм кабахәт эшләрдән сакланырлар)»,** – дип әйтә.

«Әгъраф / Пәрдә», 7:26

Бу аятьтән без үзебез өчен нәрсәләрне аңларга тиешбез? Беренчедән, Аллаһы Тәгалә кешегә киемне гаурәт урыннарын капласын өчен биргән. Икенчедән, киемнәр безгә матурланыр өчен дә кирәк.

Гаурәт урыннарга нәрсә кергәне һәркемгә мәгълүмдер. Ир-атның гаурәте – ул кендектән алып тездән түбән булган өлеш. Кардәшләрем, игътибарлы булыйк әле. Бүген шәһәрләрдә генә түгел, инде хәтта авылларда да кыска шортылар кигән ир-егетләрне күрергә була. Бу мөселман ир-атка бер дә килешми торган кием! Спорт белән шөгыльләнәбезме без, диңгездә-күлдә су коенабызмы, авыр эшләр башкарабызмы, бакчада эшлибезме – һәрвакытта да кендектән алып тез капкачларыбызны каплап торган киемдә булырга тиешбез. Фәкать хәләл җефете белән булганда гына, ягъни өендә, аулак урында, башка туганнары, балалары күрмәгәндә, ир кеше кыска шорты кебек кием кия ала.

Хатын-кызлар чит кешеләр янында битләреннән һәм беләзеккә кадәр кулларыннан кала башка урыннарын капларга тиеш. Бүген яшь мөслимәләр арасында муеннарын капламыйча яки кыскарак җиңле күлмәкләр кию модасы бар. Алар шуны белеп торырга тиеш: бу рәвешле киенү гаурәтне тулысынча каплау дип саналмый, мондый киемдә укылган намаз да кабул булмый. Инде яулык япкансыз икән, бу бит бик зур адым, зур гыйбадәт, мөслимә кардәшләребез, сез муеннарыгызны да, кулларыгызны да тиешенчә каплап йөрегез, үзегезне гөнаһлы итмәгез. Ир-атларга шуны киңәш итәр идем: әгәр хәләл җефетегез яки апа-сеңелләрегез тиешенчә киенми икән, моны игътибарсыз калдырмагыз. Әмма аларга бу тәртипләрне катылык белән түгел, хикмәт белән, җайлап аңлатыгыз.

Ир-атларның да, хатын-кызларның да киеме сыланып торырга, тән төзелешен күрсәтергә тиеш түгел. Кием үтә күренмәле, тәннең төсе күренерлек булырга тиеш түгел. Җәйге вакытта моңа аеручы игътибар итәргә кирәк. Әлбәттә, кемдер ир-атлар кеше арасында кендектән алып тездән түбән чалбар кисә дә җитә инде, дияргә мөмкин. Тик монда тыйнаклык, кабул ителгән әдәпләргә игътибар итәргә кирәк. Беренчедән, безнең җирлеккә тәннең өске өлешен капламый йөрү хас түгел, бу әдәпсезлек санала. Икенчедән, өске күлмәген салып, чалбардан гына йөргән ир-ат башкаларның игътибарын җәлеп итә: аңа чит-ят хатын-кызлар күз сала, мөселман балалары, яшүсмерләр дә аны шундый кыяфәттә күрергә мөмкин. Бу инде бер дә матур күренеш түгел, ә оятсызлык билгесе. Өченчедән, безнең Пәйгамбәребез галәйһиссәлам беркайчан да кеше арасында, урамда шундый кыяфәттә йөрмәгән.

Ир-атның өске күлмәге озын җиңле булса хәерлерәк булыр иде. Әлбәттә, майка, футболкалар кебек кием кию ир-ат өчен гөнаһ булмаячак, әмма сөекле Пәйгамбәребезнең һәрвакытта да озын җиңле кием киюен истә тотсак, без моны сөннәт, хәерле гамәл дип әйтәбез. Инде шуңа да карамастан, җәй көннәрендә футболкалардан йөрисез икән, мәчеткә килгәндә, намазга басканда булса да, озын җиңле күлмәк киегез. Намазны кыска җиңле киемдә уку – мәкруһ, ягъни киңәш ителми, шуны истән чыгармагыз.

Мөслимә киемнәренә килгәндә дә, аның төп максаты – тыйнаклык, хатын-кызны ят күзләрдән саклау. Шуңа күрә хатын-кыз киеме артык игътибар җәлеп итәргә, ягъни бик чуар, бик катлаулы фасонлы булырга тиеш түгел.

Киемнең төсенә килгәндә, мөселманга билгеле бер төстәге генә һәм кара кием генә кияргә кушылмаган. Төрле хәдисләр бар, алардан без Мөхәммәд пәйгамбәрнең төрле төстәге киемнәр кигәнен беләбез. Мисал өчен, имам Әт-Табәраниның хәдисләр җыентыгында мондый ике хәдис

китерелә: «Расүлуллаһ бәйрәм көннәрендә кызыл чапан (өске кием) кия иде» һәм «Мин Пәйгамбәребез өстендә ике сары төстәге кием күрдем». Ә аеруча Мөхәммәд пәйгамбәр ак төсне хуплаган һәм болай дип әйткән: «Ак киемнәр киегез, чөнки алар иң яхшылары, вә мәетләрегезне аларга төрегез». Галимнәребез мөселманнарга үзләре яшәгән җирлектә таралган төстәге һәм фасонлы киемнәр кияргә киңәш итә, әмма ул шәригать кануннарына туры килергә тиеш. Димәк, Исламда кием кара төстә булырга тиеш дигән канун юк. Безнең илдә ул кешеләрдә тискәре хисләр тудырырга мөмкин, бигрәк тә җәй көне карадан йөрүчеләр бар кешенең игътибарын җәлеп итәчәк, шуңа күрә, бездә таралган тыныч һәм ачык төсләргә өстенлек бирергә кирәк.

Ә хәзер бер бик гыйбрәтле риваятьне сөйләп китәсем килә. Бервакыт Әбүл-Әхвәс радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез галәйһиссәлам янына сәләмә киемнәрдән килгән.

– Синең малың бармы? – дип кызыксынган Расүлуллаһ.

– Бар, ий Аллаһының Илчесе!

– Нинди малың бар?

– Минем дөяләрем, атларым, сарыкларым, кәҗәләрем һәм Раббым биргән башка төрле байлыгым бар.

Моны ишеткәч, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Ий, Әбүл-Әхвәс, Аллаһы Тәгалә сиңа байлык биргән икән, синдә Аның нигъмәтләренең эзләре күренсен!» – дип әйткән.

Әйдәгез әле бу хәдис өстендә уйланыйк. Менә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам янына начар гына, ертык киемнәрдән бер кеше килә. Һәм Расүлуллаһ моның тышкы кыяфәтенә игътибар итә. Барыбызга да билгеле: бүгенге көндә без барыбыз да кешене күрүгә, иң беренче аның киемнәренә игътибар итәбез бит. Һәм шулвакыт башыбызда бу кеше хакында ниндидер уйлар, хисләр туа. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам белән дә шулай булган. Шуннан ул сәхабәгә: «Ник син ямьсез киенәсең?» – дими,

ә җайлап кына: «Синең малың бармы?» – дип сорый. Бу кешенең чыннан да байлыгы, акчасы барлыгын белгәч, ул аңа бик матур итеп яхшырак, сыйфатлырак киемнәр киярґә, ертылып беткән иске-москыдан йөрмәскә киңәш итә. Шуңа бу хәдистән без бик зур дәрес алырга тиеш – мөселман кешесен күргәндә, башка кешеләрдә, башка дин әһелләрендә безгә карата җирәнү хисләре туарга тиеш түгел. Чөнки безгә карап, кешеләр Ислам диненә, Аллаһыбыз китабы Коръәнгә бәя бирәләр. Тышкы кыяфәтебез чиста-пөхтә, карап торырга матур, күңелгә хуш килерлек булсын. Пычрак киемле, начар исле мөселманнарны күреп торсалар, әлбәттә, беркемнең дә безнең динебезне өйрәнәсе, мәчетләребезгә киләсе, ачык йөз күрсәтәсе килмәс. Мин бик кыйммәтле, башкаларда булмаган киемнәр киярґә, хатын-кызларны урамга бизәнеп-зиннәтләнеп чыгарга чакырмыйм. Юк, һәрнәрсәдә чикләрне сакларга, тыйнаклыкны югалтмаска кирәк. Мөселман, башка кешеләрне тирән ихтирам итеп, мөмкинлеге булса, алар янында пычрак, ертык киемнәр киярґә тиеш түгел.

Киенү рәвешенә карата тагы ике кагыйдәне истән чыгарырга ярамый:

1. Кием хәләл, рөхсәт ителгән акчаларга алынган булырга тиеш (риба, хәмер сату, отышлы уеннар белән акча табарга ярамый).

2. Кием мактану, үз-үзеңне башкалардан өстен күрсәтү, кемнедер кимсетү максатыннан киелергә тиеш түгел.

Шул рәвешле, Аллаһының рәхмәте белән, бүген без кием мәсьәләсендә кайбер сорауларга ачыклык керттек. Бу киң һәм кирәкле тема, аны һәр мөселман өстәмә өйрәнергә, хәдисләрдән мәгълүмат табарга тиеш. Шул хакта уйланыйк: кием – Раббыбыз биргән зур нигъмәт, билге. Кием биреп, Аллаһы Тәгалә адәм баласының хайваннардан өстенлеген – акыл, оят иясе икәнен күрсәтте, безне төрле табигать күренешләреннән саклады. Боларны онытмыйча, рәхмәтле булсак иде!

*ТҖ МДН Дәгъват бүлеге*

*21 июнь вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен белик!

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Безнең күңелләребезне иман, ислам нуры белән нурландырган Аллаһы Тәгаләгә чиксез хәмед һәм шөкраналарыбыз булса иде. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу гәләйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде. Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга Үзенең чиксез сәламен, киң рәхмәтен һәм бәрәкәтен ирештерсә иде! Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә ил-көннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсә иде.

Мөхтәрәм җәмәгать!

Илебездә Бөек Ватан сугышы хәсрәте кагылмаган бер генә гаилә дә юктыр. 1418 көн барган дәһшәтле сугыш еллары 27 миллионнан артык кешенең гомерен өзә һәм аларның күбесе мөселманнардан була. Дин кардәшләребез сугышның беренче көннәреннән үк Ватан хакына, тынычлык һәм Җир шарының иминлеге хакына үзләрен кызганмыйча, дошманнар белән батырларча көрәшкә чыга.

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ватанны сөю – иманнан», – дип әйткән. Әнә шул сәбәпле, олуг галим, шәех Зәйнулла Рәсүлевнең улы Габдрахман Рәсүлев, Россиянең мөфтие буларак, 1942 елда түбәндәге эчтәлекле фәтва чыгара: «Мөхтәрәм мөселман

кардәшләр! Аллаһы Тәгаләнең ошбу мөкаддәс аятьләре, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдис шәрифе илә гамәл кылып, кадерле Ватаныбызны, бөтен инсаният һәм исламият галәмен бу залимнәрнең золымыннан коткарырга сугыш мәйданында тырышыгыз. Сугыш артында куркаклык күрсәтми, ирләр һәм хатыннар сөбәт[1] илә, бөтен көчегез илә сугыш өчен кирәкле булган әсбапларны хәзерләүгә вә башка дөньяви эшләрне эшләргә тырышыгыз. Фашист Герман һәм иярченнәренә каршы бу мөкаддәс көрәштә үзебезнең хак юлда икәнлегебезне исбат кылып, Ватаныбызга тугрылыгыбызны бөтен җиһан алдында эш илә күрсәтегез. Мәсҗедләрдә, җәмигъләрдә, гыйбадәт йортларында Кызыл Гаскәрнең дошманга галиб[2] булуы хакында Аллаһы Тәгаләгә дога кылыгыз. Әгәр дошман җиңеп галиб булса, Ватаныбызга зур һәлакәт булып, галәм мәдәниятен, бөтен мөселманнарның диннәре, милләтләре, телләре, гореф-гадәтләре тәмам юкка чыгачагын һич хәтердән чыгармагыз. Без, Советлар Союзындагы ислам галимнәре, дин хадимнәре, мөкаддәс Ватаныбызны, ислам галәмен саклау юлында залим Герман фашистларга һәм иярченнәренә каршы иттифак кылып, бөтен мөселманнарны көрәшкә дәгъват кылабыз. Дошманнарга тиз вакытта мәгълүб булып, аларның залим-җәфалардан котылулары хакында, Рәхим-Рәхман Аллаһы Тәгаләгә ихласлык илә дога кылыгыз. Кодрәтле вә көчле Аллаһы ярдәме, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең рухани химаясы илә, ин шә Аллаһ, без галиб булачакбыз».

Рәсүлевнең әлеге фәтвасы Советлар Союзында яшәүче барлык мөселман халыклары телләренә тәрҗемә ителеп, алар яшәгән җирләрдә таратыла һәм мәчетләрдә вәгазь вакытында укыла торган була. Мөрәҗәгатьнең «Труд» газетасында басылып чыгуы мөселманнарның туплануына зур этәргеч ясый. Дин кардәшләребез Кызыл Армиянең җиңүенә әнә шулай итеп үз өлешләрен кертә.

---

[1] Сөбәт – батырлык, ныклык.

[2] Галиб – җиңүе.

Бөек Ватан сугышы елларында дин кардәшләребез фронт өчен акча, кием, азык-төлек җыйган, мәхәлләләр аша дәүләт займы облигациясен тараткан, армияне корал, кирәк-яраклар белән тәэмин иткән, яу кырында сугышкан һәм тылда эшләгән.

1943 елның 30 мартында «Известия» газетасында Габдрахман хәзрәт Рәсүлевнең телеграммасы басыла. Биредә ул түбәндәгене хәбәр итә: «Кызыл Армия уңышларына куанып, шәхсән үземнән танклар ясау өчен 50 мең сум акча кертәм һәм барлык мөселманнарны танклар төзелешенә фида кылырга чакырам». Шул рәвешле, мөфти Габдрахман Рәсүлев Бөек Ватан сугышы елларында тирән эз калдырган дин әһеле буларак тарихта кала.

Күрәсез ки, Совет заманында яшәгән мөселманнар Ватан алдындагы изге бурычларын үтиләр һәм туган җирләрен саклыйлар. Гитлер СССРда яшәүче мөселманнарның хәленнән яхшы хәбәрдар була һәм аларның ризасызлыкларын советка каршы пропагандада кулланырга планлаштыра. Әмма Гитлерның өметләре тормышка ашмый. Мөселманнар фашистларга каршы көрәштә менә нинди ватанпәрвәрлек һәм батырлык күрсәтәләр!

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кешеләргә рәхмәтле булмаган бәндә Аллаһыга да рәхмәтле түгел», – дип әйткән. Шуңа күрә без бүген һәр аяз көнебез өчен, тыныч тормышта укып, эшләп, балалар үстереп яши алуыбыз өчен Аллаһыга шөкер итәргә тиеш. Шулай ук, тыныч, якты көннәр килсен өчен гомерләрен биргән герой солдатларның якты истәлеген саклау – безнең изге бурычыбыз. Арабызда яшәгән ветераннарны да, сугыш кырларында ятып калганнарны да яки фронтта алган яралардан гомерләре өзелгәннәрне дә хәтердән чыгармыйк. Алар – үзләреннән соң килгән буын киләчәге өчен гомерләрен кызганмаган батырлар.

Адәм баласы бу дөньяга юкка гына килми. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

الَّذِي خَلَقَ الْمَوْتَ وَالْحَيَاةَ لِيَبْلُوَكُمْ أَيُّكُمْ أَحْسَنُ عَمَلًا ۚ وَهُوَ الْعَزِيزُ الْغَفُورُ ﴿٢﴾

**«Арагыздан кайсыгыз күркәмрәк гамәл кылганны сынап карау өчен үлем белән тереклекне бар итте. Ул (Аллаһы Тәгалә) һәрнәрсәдән өстен вә ярлыкаучы».**

«Мүлек / Патшалык», 67:2

Аллаһы Раббыбыз безне шатлык белән дә, авырлык белән дә, кайгы-хәсрәтләр белән дә сыный. Шуны онытмасак иде: адәм баласына нинди генә авырлык, сынау килсә дә, ул аңа сабырлыгы белән каршы торырга тиеш. «Әл-Бәкара» сүрәсендә болай дип әйтелә:

وَلَنَبْلُوَنَّكُم بِشَيْءٍ مِّنَ الْخَوْفِ وَالْجُوعِ وَنَقْصٍ مِّنَ الْأَمْوَالِ وَالْأَنفُسِ وَالثَّمَرَاتِ ۗ وَبَشِّرِ الصَّابِرِينَ ﴿١٥٥﴾

**«Ий мөэминнәр! Әлбәттә, без сезне курку һәм ачлык белән, маллар, җаннар, җиләк-җимешләр тарлыгы белән сыныйбыз. (Сыналган вакытларда) сабыр булучыларны исә шатландыр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:155

Бу дөньяда безнең белән нинди генә хәл булса да, аларның һәркайсы безне сынар өчен бирелгән. Нинди генә сынау килсә дә без, иң беренче чиратта, Аллаһыны искә төшереп, Аның ризалыгына омтылып, сабыр итә белергә тиешбез. Авырлыклар килгәндә сабырлык күрсәтү – иң зур савап. Түземлек үрнәге булып, беренче чиратта, Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең язмышы тора. Аллаһы Тәгалә аңа нинди генә сынаулар җибәрсә дә, ул аларны күтәрде, соңыннан исә Аллаһының рәхмәтенә иреште. Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә дә: «Адәм баласына сабырлыктан да зуррак байлык бирелмәде», – дип әйтелә.

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримнең түбәндәге аятендә сүрәсендә болай дип әйтә:

الَّذِينَ يُنفِقُونَ فِي السَّرَّاءِ وَالضَّرَّاءِ وَالْكَاظِمِينَ الْغَيْظَ وَالْعَافِينَ عَنِ النَّاسِ ۗ وَاللَّهُ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ ﴿١٣٤﴾

**«Аллаһы Тәгалә, чыннан да, шатлыкта да, кайгыда да малларын сарыф итүчеләрне, ачуларын тыючыларны һәм кешеләрне гафу итүчеләрне, изгелек эшлүчеләрне ярата».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:134

Ягъни, «Минем каршымда булган вазифаларыгызны, бурычларыгызны кайгылы вакытта да, сөенечле вакытта да, шатлыклы вакытта да үтәгез һәм ачуыгызны эчкә алыгыз», – дип әйтә.

Аллаһы Тәгалә җирләрне, күкләрне – барысын да безнең өчен, безгә хезмәт итәр өчен яратты. Без Җир йөзендә яшибез икән, иң әүвәл Аллаһы Тәгалә каршында булган вазифаларны үтәргә тиеш. Ватан алдында да бурычларыбыз бар. Ата-ана да – тәкъдир, Ватан да – тәкъдир, туган җир дә – тәкъдир, берәү дә туган җирен сайлап ала алмый. Кеше кайсы җирдә туган, шул җирне хөрмәт итәргә, яратырга һәм аңа куркыныч янаганда, гомерен дә кызганмыйча, сакларга тиеш.

Безнең арабызда үзләренең Ватан алдында изге вазифаларын үтәп кайткан бабаларыбыз яши. Аллаһы Тәгалә аларның шушы күргән афәтләрен, борчуларын гөнаһларына кәффарәт итеп, җәннәткә керүләренә сәбәпче итсә иде. Аллаһы Тәгалә тагын да хәерле гомерләр, хәерле сәламәтлекләр биреп, матур-матур, үрнәк бабайлар булып, балаларга үгет-нәсыйхәт бирүче һәм Аллаһының кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәүче бабайларның безнең араларыбызда озак яшәүләрен Үзе насыйп әйләсә иде. Безнең яшьләребез дә шушы бабайла-

рыбыздан үрнәк алып, алар өчен дога кылып, үзләре дә кирәк булса, дин өчен, Ватан өчен көрәшчеләр булып үссеннәр иде.

Кадерле дин кардәшләр! Раббыбыз туган җиребездә тыныч, имин тормыш насыйп итсен һәм бәлаләрдән, кайгы-хәсрәтләрдән сакласын. Һәм барыбызга да бәхет, сәламәтлек биреп, бәрәкәтле имин тормышлар насыйп итсен. Әмин!

*ТҖ МДН Дәгъват бүлеге*

*28 июнь вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Табигать – адәм балаларына әманәт

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн, әммә бәгъде: барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә булса иде. Һәм дә салават-шәрифләребез Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде.

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ, хөрмәтле дин кардәшләрем!

Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламне һәм аның кабыргасыннан яратылган Хәва анабызны иң элек җәннәттә яшәтте. Ләкин шәйтан ләгънәтуллаһ вәсвәсәсе белән икесе дә Җиргә төшерелде. Шул заманнан бирле адәм балалары соңыннан янәдән Раббылары хозурына әйләнеп кайту өчен шушы Җир шарында гомер итә. .

Раббыбыз Адәм галәйһиссәламне яратты һәм аны Җирдә хәлифә итте. Бу хакта Аллаһы Тәгалә «Әл-Бәкара» сүрәсендә:

هُوَ الَّذِي خَلَقَ لَكُم مَّا فِي الْأَرْضِ جَمِيعًا ثُمَّ اسْتَوَىٰ إِلَى السَّمَاءِ فَسَوَّاهُنَّ
سَبْعَ سَمَاوَاتٍ ۚ وَهُوَ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمٌ ﴿٢٩﴾ وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي
جَاعِلٌ فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً ۖ قَالُوا أَتَجْعَلُ فِيهَا مَن يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَاءَ
وَنَحْنُ نُسَبِّحُ بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ ۖ قَالَ إِنِّي أَعْلَمُ مَا لَا تَعْلَمُونَ ﴿٣٠﴾

**«Ул – Аллаһы җирдәге барча нәрсәне сезнең өчен халык кылды, соңра күкне төзергә теләде һәм күкне җиде кат итеп тергезде. Ул һәрнәрсәне белүче. Һәм әйтте синең Раббың фәрештәләргә:**

**«Мин, әлбәттә, җир өстендә хәлифә итеп Адәмне кылмакчымын. Фәрештәләр әйттеләр: «Ий, Раббыбыз! Бозыклык кылучы, сугышып кан түгүче затны җир өстенә хәлифә кыласыңмы? Без исә Сине мактап тәсбихләр әйтәбез, һәм Сине һәр кимчелектән пакьсең дип игътикад итәбез». Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә: «Дөреслектә, Мин сез белмәгәнне беләмен»,** – дип әйтә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:29-30

Шулай итеп, без яшәгән Җир шары: табигате, сулары, һавасы, хайван-бөҗәкләре – барысы да безгә әманәт итеп бирелде. Шуңа да аны саклап тоту – һәрберебезнең изге бурычы.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдис-шәрифендә: «Әгәр иртәгә Кыямәт буласын белсәң, бүген агач утырт», – дип әйткән. Шушы нәсыйхәтнең асыл мәгънәсе, әлбәттә, изгелек кылу турында. Ягъни кояш кире яктан чыкканчы, җаныбыз бугазыбызга терәлгәнче хәерле гамәлдә булырга тиешбез. Шул ук хәдиснең турыдан-туры мәгънәсе дә бик матур. Чөнки агач утырту – ул шулай ук изгелек. Аллаһы Тәгалә безгә табигать аша бихисап байлык бирә. Сулар һавабыз, эчәр суыбыз, ашар ризыгыбыз – барысы да әйләнә-тирәбездә, әмма Раббыбыз насыйп итмәсә – шушы нигъмәтләрнең берсен дә татый алмаячакбыз. Бер сулыш алырга да интегүчеләр, бер тәгам ризык каба алмаучылар бар – болар барысы да безгә бер кисәтү.

Шул агачны утыртуыбыз да, ниятебезгә карап – күркәм гамәл. Шушы агач һаваны чистартыр. Җимеш агачы икән – шул нигъмәтләр белән кешеләр, кошлар, хайваннар ризыкланыр. Еллар узып бу агач зур булып үсәр, җәелер. Юлчылар эссе көндә аның күләгәсендә хәл алыр. Без инде ул вакытта бакыйлыкка күчкән булырбыз. Ин шә Аллаһ, шул утырткан агачыбыз, садакатуль-җәрия булып, кешеләр, башка җан ияләре аннан файда күреп, безгә савабы ирешеп торыр.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Табигать мәсьәләсендә бик сак булсак иде. Аллаһының Илчесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәтта афәт килгән авыр чакларда да, әйтик, сугыш вакытында да табигатькә зыян салмаска куша. Хәтта сугыш вакытында да! Ә бездә бүген, әлхәмдүлилләһ, сугыш юк, ләкин табигатькә каршы әллә нинди вәхшәтләр кылабыз. Үзебез шунда яшибез, үзебез шул җирдән алынган ризыкны ашыйбыз – үзебез шушы нигъмәтләрне исраф итәбез. Икенче бер хәдисендә Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Һәрбер исраф – харам». Җылы чаклар җиттеме – табигатькә чыгабыз. Ял итәбез. Үзебезнең артыбыздан өем-өем чүп калдырабыз. Учак ягабыз дип, яшь-яшь тап-таза агачларны балта белән чабабыз. Аннары: «Бетерделәр бөтен урманнарны», – дип зарланабыз. Инде бүген агач утырту түгел, булганнарын саклау турында да уйланмыйбыз. Раббыбызга шөкер, авылларда әле бакчаларда агачлар үсә, ә шәһәрләрдә яшеллекләр кими. Хәтта шул паркларда утыртылган агачларны да әшәкелек белән әледән-әле сындырып торалар. Кемнәр? Ерткыч хайваннар түгел – үзебез, шушы Җирнең хәлифәләре. Гәрчә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шул агачның яфракларын да сәбәпсез өзмәгез, дисә дә. Шуңа да балаларыбызны кечкенәдән өйрәтик: агачны сындырма, хайваннарны рәнҗетмә, суны пычратма! Үзебез дә шушы мәсьәләдә үрнәк булыйк.

Сәнәгать үсеше соңгы дистә елларда күп кенә урман-суларны юк итте, пычратты. Бу дөнья күләмендә шулай. Әлеге мәсьәләне, ин шә Аллаһ, хәл итү насыйп булсын. Ил җитәкчеләренә, сәнәгатьчеләргә Аллаһы Тәгалә күркәм гакыл бирсен. Аңлашыла: җитештерү, адәм баласын тәэмин итү кирәк. Шул ук вакытта табигать ресурсларыннан сак куллану программаларын да гамәлгә ашыру әһәмиятле. Монысы глобаль мәсьәлә. Без үзебездән башлыйк. Кайбер җирлекләрдә күрәбез: елга буенда гаҗәеп гүзәл бер авыл утыра, ә якынрак килсәң: канализация чокырын казымас өчен юынтык суларын шул елгага җибәрәләр. Расүлебез Мөхәммәд

салләллаһу галәйһи вә сәлләм елга-суларга хәтта кече йомышыгызны да үтәмәгез, дип әйтеп калдырган! Табигать сакчылары Идел-суыбызны чистартканда нәрсә генә чыгармый. Үз кулларыбыз белән үзебез шул суга аткан чүпләр бит. Өйләребезне, каралты-кураларыбызны даими чистартып торыйк. Шәхси йортта торабызмы, фатирдамы – барыбер шул җирдән йөрибез. Берәр чүп ташладыкмы, гөнаһлы булырбыз. Пычрак күреп, шул урынны пакьләдек исә – ин шә Аллаһ, савап алырбыз.

Чүп мәсьәләсе бүген гомумән көн үзәгендә. Һәр кешедән көн саен әллә ничә килограмм чүп чыга. Бер күпкатлы йорттан контейнер-контейнер чүп алып китәләр. Бер шәһәр чүплегенә көн дә әллә никадәр машина чүп-чар китерелә. Ә бит шул ташлаган әйберләрне яңадан кулланып була. Кәгазь-картонны макулатура итеп тапшыра алабыз. Пластик әйберләрне эшкәртүгә тапшыру аеруча мөһим, чөнки ул таркалсын өчен 100-300 ел үтү кирәк. Агач утырттыкмы-юкмы, ул агач үстеме-юкмы, ә бүген чүп савытына ташлаган пластик шешәбез, пакетыбыз әле тагын 10 буын оныкларыбызга да калачак. Һич кенә дә күркәм мирас түгел бу.

Әлбәттә, бар чүпне бер капчыкка салып ташлап китү җайлырак. Берәр уйсу җирдә, урман эчендә аударып китү дә әллә ни көч сорамый. Ләкин мөселман кешесе хәтта шул чүп ташлауда да Ахирәт турында онытмаска тиеш. «Раббым биргән нигъмәтләрне пычратмыйм», – дип ниятләп эшкәртеп була торган чүпләрне аерым җыябыз икән – ин шә Аллаһ, савап. Шул макулатураны, пластик әйберләрне, иске батарейкаларны кабул итү пунктларына илтәбез икән – шулай ук әҗерен күрербез, Аллаһы боерса.

Гомумән, бүген чүплек яныннан үткәндә хәтта ризык та күрәбез. Бу бик куркыныч күренеш. Дөньяда күпме кеше ачлыктан интегә, ә без исә Раббыбызның нигъмәтләрен әнә шулай исраф итәбез. Берәр нәрсәнең кадерен белмәсәк, Аллаһы Тәгаләнең безне шул нигъмәттән мәхрүм итүе дә бар. Шуңа да ризыкны кирәгенчә генә алыйк, сакчыл карыйк. Күршеләребез белән дә бүлешик, әмма бозылыр дәрәҗәгә җиткермик,

исраф кылмыйк. Табигатькә, Раббыбыз биргән нигъмәтләргә шөкер кылучылардан булыйк. Ин шә Аллаһ, шунда бәрәкәт тә булыр.

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*5 июль вәгазе,*

*Зөлкагъдә аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Сабырлык

Гөнаһларны гафу итүче, тәүбәләрне кабул итүче Аллаһы Тәгаләгә олуглауларыбыз һәм мактауларыбыз булсын! Шулай ук Мөхәммәд пәйгамбәрнең рухына салаватларыбыз һәм сәламнәребез ирешсен.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем! Әгәр дә без дөньяда һәм дөньядан соң була торган Ахирәт дөньясында уңышка ирешергә теләсәк, һичшиксез, сабыр булырга тиешбез. Сабырлык сыйфаты булмаса, без бәхет дигән бүләкнең исен дә сизмәячәкбез, чөнки дөнья һәм Ахирәт бәхетенә ирешкән бөтен кешеләрнең күңелләрендә сабырлык сыйфаты нигезләнгән иде, алар сабырлык белән коралланып, дөньяның авырлыкларын җиңделәр һәм аларны сынар өчен бирелгән авырлыклар сөенеч көннәренә әйләнде.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем, нинди генә хәлдә булсак та, бу дөнья сынау йорты икәнлеген һәм безнең дә бу сынау йортына сыналыр өчен килгәнлегебезне онытмыйк. Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында, бик күп аятьләрендә дөнья йортының сынау йорты икәнлеге турында әйтеп уза. Шушы әйтелгәннәрнең кайберләрен ишетеп узыйк.

وَلَنَبْلُوَنَّكُم بِشَيْءٍ مِّنَ الْخَوْفِ وَالْجُوعِ وَنَقْصٍ مِّنَ الْأَمْوَالِ وَالْأَنفُسِ
وَالثَّمَرَاتِ ۗ وَبَشِّرِ الصَّابِرِينَ ﴿١٥٥﴾ الَّذِينَ إِذَا أَصَابَتْهُم مُّصِيبَةٌ قَالُوا إِنَّا
لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ ﴿١٥٦﴾ أُولَٰئِكَ عَلَيْهِمْ صَلَوَاتٌ مِّن رَّبِّهِمْ وَرَحْمَةٌ ۖ
وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُهْتَدُونَ ﴿١٥٧﴾

**«Әлбәттә, без сезне курку, ачлык белән; маллар, җаннар, җиләк-җимешләр тарлыгы белән сынаячакбыз. (Сыналган вакытларда) сабыр булучыларны исә шатландыр. Ул сабыр булучыларга берәр авырлык килсә, алар: «Без Аллаһы Тәгаләнеке һәм Аңа кире кайтачакбыз», – дип әйтәләр. Шуларга Раббылары тарафыннан ярлыкау һәм мәрхәмәт насыйп булачак, дөреслектә, алар туры, дөрес юлда булучылар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:155-157

Шулай ук тагын бер аятьтә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

أَحَسِبَ النَّاسُ أَن يُتْرَكُوا أَن يَقُولُوا آمَنَّا وَهُمْ لَا يُفْتَنُونَ ﴿٢﴾ وَلَقَدْ فَتَنَّا الَّذِينَ مِن قَبْلِهِمْ ۖ فَلَيَعْلَمَنَّ اللَّهُ الَّذِينَ صَدَقُوا وَلَيَعْلَمَنَّ الْكَاذِبِينَ ﴿٣﴾

**«Әллә кешеләр: «Без иман китереп, инандык!» – дип әйткәч, аларга авырлыклар килмәс һәм алар сыналмаслар дип исәплиләрме?! Аларга кадәр булган кешеләр барысы да сыналды. Аллаһы кайсылары дөрес сөйли һәм кайсылары ялганлый икәнен белә».**

«Гәнкәбүт / Үрмәкүч», 29:2-3

Аллаһы Тәгалә шулай ук:

الَّذِي خَلَقَ الْمَوْتَ وَالْحَيَاةَ لِيَبْلُوَكُمْ أَيُّكُمْ أَحْسَنُ عَمَلًا ۚ وَهُوَ الْعَزِيزُ الْغَفُورُ ﴿٢﴾

**«Кайсыларыгыз яхшырак гамәлле икәнлегеннбелер өчен, Ул үлемне һәм тереклекне халык кылды. Ул һәрнәрсәдән өстен вә ярлыкаучы».**

«Мүлек / Патшалык», 67:2

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем! Димәк, адәм баласы якты дөньяга килгәннән соң акыл камиллегенә ирешеп, соңгы сулышларына кадәр гомерен сынауда уздыра. Ирләр, хатыннар, яшьләр, картлар, байлар, ярлылар, көчлеләр, көчсезләр – барысы да, барыбыз да сынауда. Кем үзен Аллаһы Тәгалә каршысында ничек күрсәтә. Яшьләр – яшьлекләре белән, картлар – картлыклары белән, байлар – байлыклары белән, ярлылар – ярлы булулары белән сынала. Кайбер вакытта: «Эх, бабай булсам иде…»; «Эх, чибәр булсам иде, көчле булсам иде…», – дип, үзләренең хәлләреннән канәгать булмыйча, башка кешеләрнең хәлләренә кызыгучыларны ишетергә туры килә.

Бу сүзләрне әйтүчеләр нәрсәгә кызыкканнарын аңламаучылар һәм белмәүчеләр, чөнки әгәр гыйбрәт күзе белән уйлап карасак, күп вакытта байлык белән, көч белән, чибәрлек белән сыналу ярлылык һәм көчсезлек, ямьсезлек белән сыналуга караганда авыррак.

Аллаһы Тәгалә китабында болай дип әйтә:

لَا يُكَلِّفُ اللَّهُ نَفْسًا إِلَّا وُسْعَهَا ۚ ﴿٢٨٦﴾

**«Аллаһы беркемгә дә күтәрә алмаган сынаулар йөкләмәс…»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:286

Ягъни һәр кешегә сынавын хәленә карап бирә: арттырмый да, киметми дә.

Сынау дигән сүзне күп кабатладым. Ни өчен? Чөнки һәрбер сынау бездән сабырлык көтә һәм сынауларга сабырлык белән генә каршы торып була.

Сабырлык берничә төрле була. Беренчесе – Аллаһы Тәгаләгә итагать итүдә, ягъни Аллаһы Тәгалә безнең өстебезгә нәрсәләрне йөкләгән булса, шуларны үтәгән вакытта кирәкле булган сабырлык – намаз уку, ураза тоту кебек һәм башкалар. Икенчесе – Аллаһы Тәгалә безгә тыелырга кушкан нәрсәләргә карата сабырлык. Мәсәлән, аракы эчмәү, дуңгыз ите

ашамау, тәмәке тартмау кебек һәм башкалар. Өченчесе – бәла-казаларга карата сабырлык, ягъни авыруларга, ачлыкларга, якын кешеләрнең үлеп китүләренә карата сабырлык.

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән шундый хәдис риваять ителә: «Аллаһы Тәгалә: «Берәр бәндәмә авырлык килсә һәм шушы вакытта ул, Миңа сыену чараларын эзләп, Миңа ялварса, һичшиксез, Мин аңа сораганчы ук бирермен һәм догасын кылыр алдыннан ук догасына җавап кайтарырмын. Ә инде бәндәмә авырлык килгәннән соң, Мине онытып, башка берәүгә сыгынса, алардан чаралар эзләсә, күк ишекләрен ябармын (ул бернинди яхшы нәтиҗәгә ирешә алмас)», – дип әйтә».

Башка бер хәдисендә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Кем берәр төнне авырып уздырса һәм үзенең хәленә сабыр булса, Аллаһыдан разый булса, газиз әнисеннән туган көнне гөнаһсыз булган кебек гөнаһларыннан пакьләнер. Әгәр авырсагыз, сәламәтлек сорамагыз», – дип әйткән. Ягъни Пәйгамбәребезнең соңгы җөмләсендәге сүзнең мәгънәсе шулайрак: «Әгәр авырган вакытыгызда гөнаһларыгыздан пакьләнү һәм Аллаһы Тәгалә каршысына нинди бөек дәрәҗәләргә ирешүегезне белсәгез, сәламәтлек сорамас идегез. Ләкин бәндә буларак без тынычлык һәм сәламәтлек телибез».

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем! Сабырлык үрнәге буларак Әюб галәйһиссәламнең тормышын искә төшереп узыйк. Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында аның турында:

إِنَّا وَجَدْنَاهُ صَابِرًا ۚ نِّعْمَ الْعَبْدُ ۖ إِنَّهُ أَوَّابٌ ﴿٤٤﴾

**«Без аны сабыр итүче дип таптык. Хакыйкатьтә, ул – Аллаһыга тәүбә белән кайтучы күркәм коллардан булды».**

«Сад», 38:44

Әюб галәйһиссәлам үзенең халкына пәйгамбәр булып җибәрелгән иде һәм Аллаһы Тәгалә аны бәлки башка пәйгамбәрләрне сынамаган

сынаулар белән сынады. Әюб галәйһиссәламнең мул җимеш бакчалары, балалары, хатыннары һәм һич тә борчымый торган сәламәтлеге бар иде. Муллыгына карамастан, Аллаһы Тәгалә аның өстенә йөкләгән бөтен эшләрне Әюб галәйһиссәлам кимчелек китермичә, ялкаулык күрсәтмичә, җиренә җиткереп үтәп бара иде. Көннәр үтә торгач, Әюб галәйһиссәламгә сынаулар килә башлады. Иң беренчесе – җимеш бакчасы уңыш бирмичә, бакчасындагы бөтен агачлары һәлак булды. Шәйтан аның янына килеп: «Ташла гыйбадәтеңне, бераз үзеңне кайгырт», – дип әйтте. Бу сүзләрне ишеткәч, Әюб галәйһиссәлам: «Без Аллаһыныкы һәм аңа кайтачакбыз. Ул Үзе бирде, Үзе алды, биргән әйберен кире алганы өчен мин ничек итеп Аңа ачуланыйм?!» – дип әйтте һәм шәйтанны куып җибәрде. Ләкин Әюб галәйһиссәламнең сынаулары моның белән бетмәде. Берсе артыннан берсе газиз балалары төрле сәбәпләр белән үлә башлады һәм иң соңында бөтен балалары да үлде. Шәйтан янәдән кеше сурәтендә аның янына килде: «Әй, Әюб, мин сине кызганам, бакчаларың һәлак булды, таянычың булган балаларың үлеп бетте, ә син һаман да Аллаһы, Аллаһы дисең. Ташла бу эшне, бераз үзеңнең хәлеңне кайгырт», – дип әйтте.

Шәйтанның бу сүзләрен ишеткән Әюб галәйһиссәлам: «Без Аллаһыныкы һәм аңа кайтачакбыз. Ул Үзе бирде, Үзе алды, биргән әйберен кире алганы өчен мин ничек итеп Аңа ачуланыйм?!» – дип шәйтанны куып җибәрде. Бу сынаудан соң Аллаһы Тәгалә Әюб галәйһиссәламнең сәламәтлеген алды: авыруы көннән-көн арта иде, янында хатыныннан кала беркем калмады. Әюбнең авылдашлары: «Әй, Әюб, зәһәр авыруың безгә иярмәсен өчен, авылдан чыгып кит», – дип әйтәләр. Әюб галәйһиссәлам туып-үскән, яшәгән авылыннан хатыны белән чыгып китә һәм авылдан бик ерак булмаган бер җиргә барып урнаша. Әюбнең хатыны авылга барып, аннан ризык алып килә иде. Әмма авыруы көннән-көн көчәя. Шәйтан тагын кеше сурәтендә Әюб галәйһиссәлам янына килеп җитә һәм аңа: «Әй, Әюб, мин синең хәлеңә хәйран калам, бакчаларың,

җиләк-җимешләрең юк, балаларың үлеп бетте, Аллаһы Тәгаләң сиңа авыру бирде, сине авылыңнан чыгардылар, хатыныңның кулына калдың, ә син һаман да Аллаһыны мактыйсың. Ташла бу эшеңне, оныт ул Аллаһыны», – дип әйтә. Әюб галәйһиссәлам: «Без Аллаһынныкы һәм аңа кайтачакбыз. Ул Үзе бирде, Үзе алды», – дип әйтте. Шәйтан бу сүзләрне Әюб галәйһиссәлам янына килгән саен ишетте һәм өметсезләнеп аның яныннан китеп барды. Әюб галәйһиссәлам торып, гыйбадәтен үти алмый башлагач кына кулларын күтәреп, Аллаһы Тәгаләгә ялварды:

أَنِّي مَسَّنِيَ الضُّرُّ وَأَنتَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ ﴿٨٣﴾

**«Әй мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе! Миңа авырлык кагылып китте».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:83

Ягъни башка төрле сүзләр белән әйткәндә: «Әй Раббым, торып гыйбадәт итә алырлык сәламәтлек насыйп ит миңа», – дип әйтте ул. Бөтен сынауларга каршы сабыр, түземле булганы өчен Аллаһы Тәгалә догасын кабул итте һәм җимеш бакчаларын, балаларын, сәламәтлеген, хатыннарын, дәрәҗәсен ике тапкыр арттырып, кире кайтарды. Әюб галәйһиссәлам дөньяда дөнья хөрмәтенә, Ахирәттә Ахирәт бәхетенә иреште.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем! Әюб галәйһиссәламнең сабырлык, түземлек мисаллары барыбызга да үрнәк булса иде. Нинди генә хәлдә булсак та, Әюб галәйһиссәламнең әйткән сүзләрен бер дә онытмыйк: «Без Аллаһынныкы һәм Аңа кайтачакбыз», – һәм аларны һәрвакыт исебездә тотыйк. Сабырлыкка багышланган вәгаземне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисе белән тәмамларга телим: «Мөэмин кешенең хәле бик гаҗәп: аның бөтен хәлләре аңа яхшылык китерә. Бу өстенлек фәкать мөэмингә генә насыйп була. Әгәр дә аңа берәр шатлык килсә – шөкер итә һәм ул аңа хәерле була. Берәр авырлык килсә – сабыр итә һәм ул да аңа хәерле була». Ягъни без мөселманнарга берәр

шатлык, сөенеч килсә, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтәбез һәм ул сөенеч ике өлеш артыграк була, ә инде берәр авырлык килсә, сабыр итәбез, Аллаһы Тәгаләдән түземлек сорыйбыз һәм ул авырлык киләчәктә безнең өчен сөенеч җимешенә әйләнә.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем! Сабырлык безнең калканыбыз булсын, сабырлык безнең коралыбыз, безгә дөнья һәм Ахирәт бәхетенә юл күрсәтә торган дустыбыз булсын.

*Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин,*

*«Шамил» мәчете имам-хатыйбы*

Редакция хаты

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

# Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

**Хөрмәтле имамнар, укучыларыбыз!**

«Шура» журналының 23 санында Габдулла хәзрәт Әдһәмовның «Дингә өндәү нигезләре һәм имамның вазифалары» китабыннан урнаштырылган мәкаләдә («Җеназа мәсьәләләре» мәкаләсе, 91 б.) хата җибәрелгән. Мәкаләдә: «Мәетне һәрвакыт аягы белән алга таба каратып алып баралар», дип әйтелгән. Ләкин дөресе – «Мәетне һәрвакыт башы белән алга таба каратып алып баралар».

«Шура» журналында вәгазьләрегез, мәкаләләрегез, әдәби әсәрләрегезне урнаштырасыгыз килсә, shura@huzur.ru электрон почтасына яки 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы 6/27 («Шура» журналына» дип) адресына хатлар юллый аласыз.

# Үрнәк затлар

# Бишенче тугры хәлифә – Гомәр бине Габделгазиз

**Тулы исеме:** Әбү Хафс Гомәр бине Габделгазиз бине Мәрван бине Әл-Хәкәм бине Әл-Гас бине Өмәйя бине Габдешшәмс.

**Әтисе:** Габделгазиз бине Мәрван.

**Әнисе:** Ләйлә өмме Гасыйм бинте Гасыйм бине Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе.

**Яшәгән еллары:** 680 елда (һиҗри белән 62 нче ел) Мәдинәдә туган. 720 елда Димәшкъта вафат булган.

**Хәлифәлек еллары:** 717 – 720 (2 ел 5 ай дәвамында хәлифә булып торган).

**Балалары:** улы – Габделмәлик бине Гомәр бине Габделгазиз.

## Нәселе

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дүрт сәхабәсе идарә иткән дәвердә (30 ел дәвамында) Гарәп хәлифәлеге кечкенә дәүләттән бәйсез дәүләткә әверелә.

Гарәп хәлифәлеге тарихында күпчелек тарихчылар тагын бер хәлифә – Гомәр бине Габделгазиз (Гомәр II) идарә иткән дәверне аерып карыйлар. Дәүләт белән идарә итүдә күрсәткән хезмәтләре һәм үзеннән алда идарә итүчеләрнең эшчәнлеген намус белән дәвам иттергәне өчен аны «бишенче тугры хәлифә» дип атыйлар.

Гомәр бине Габделгазиз 680 елда (кайбер чыганакларда 682 елда) Мәдинәдә дөньяга килгән, Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһе нәселеннән.

Гомәр бине Габделгазизнең әтисе – Габделгазиз бине Мәрван, өмәвиләр хәлифәсе Габделмәликнең ир туганы булган. Әтисе Мисыр әмире итеп билгеләнгәч, улын үзе белән Мисырга алып китәргә тели,

ләкин Гомәр этисенә болай дип әйткән: «Минем өчен файдалырак булган нәрсәне сиңа әйтимме?» Әтисе аннан: «Нинди нәрсә ул?» – дип сораган. Гомәр аңа: «Мине Мәдинәгә җибәр, мин анда галимнәрдән гыйлем алып, аларның әхлакларын үземә кәсеп итәрмен», – дип җавап кайтарган.

## Гомәрнең Мәдинәдә укуы

Мәдинәдә Гомәр бине Габделгазиз бөек сәхабәләр белән очрашкан. Губадәтү бине Самит, Тәмим Әд-Дари кебек сәхабәләрдән һәм Сәгыйд бине Мөсаййиб, Гурвәтү бине Зөбәйр, Сәлим бине Габдуллаһ бине Гомәр, Гобәйдуллаһ бине Габдуллаһ бине Готбәт кебек табигыйннәрдән (Аллаһының рәхмәтендә булсыннар) белем алган.

Мәдинәдә Гомәр бине Габделгазиз олыгая, зур гыйлемнәргә ия була. Әмир улы булуына да карамастан, ул үзен бик тыйнак тоткан.

## Мәдинә әмире булуы

Мәдинәдә укыганнан соң, этисенең авыруы сәбәпле, ул кире Мисырга кайтырга мәҗбүр була. Улы кайтканнан соң этисе озак яшәми, вафат була. Шуннан соң ул Димәшкъка күчә. Анда ул Габделмәлик абзасының тәрбиясендә яши. Абзасы аны үзенең кызы Фатыймага өйләндерә. 705 елда Габделмәлик вафат булгач, аның урынына хәлифә булып улы Вәлид килгән. Ул Гомәрне хәлифәлектән читләштерү өчен аны Мәдинәгә әмир итеп билгели. Гомәр Мәдинәгә кайтуына бик сөенә. Ул монда үзе янына ун мәшһүр галимне чакырып, болай дип әйткән: «Мин сезне изгелек эшләргә чакырамын. Миңа хәерлекне таратырга булышыгыз. Хаталарымны күрсәгез, төзәтегез. Мин исә үз чиратымда сезнең ихтыяҗларыгызны үтәрмен». Ул аларны үзенә ярдәм итәргә өнди. Әгәр берәр золымлыкны күрсәләр, аңа хәбәр итәргә куша һәм бөтен эшләрдә дә алар белән

киңәшләшә. Шул рәвешле, аның идарәсендә тугры хәлифәләр чалымнары күренә башлый. Халык аны ярата, якын күрә.

Мәдинәдә булган вакытында бер вакыйга аңа бик нык тәэсир итә. Бервакыт Гомәр хезмәтчесенә ачуланып, аңа сугарга тели. Хезмәтчесе бик акыллы кеше булып, аңа хикмәтле сүз әйткән. Гомәр бу вакыйга турында үзе болай дип искә алган: «Мин аңа сукмакчы идем, әмма ул миңа: «Кыямәт көнен исеңә төшер», – дип әйтте. Бу сүзләрдән соң Гомәр бине Габделгазиз үзгәреп китә, аның тәкъвалыгы арта.

6 ел әмир булу дәверендә Гомәр зур эшләр башкара: яңа юллар салына, авыл хуҗалыгы эшләре өчен каналлар һәм коелар казыла. Шуннан соң, бу вазифаны калдырып, ул хәлифәлек гаскәрендә гади солдат булып хезмәт итә.

Вәлид вафат булганнан соң, хәлифәлек аның энесе – Сөләйман бине Габделмәликкә күчә. Сөләйман белән Гомәрнең мөнәсәбәтләре яхшы булу сәбәпле, ул Гомәрне кире хәлифәлеккә чакыртып ала һәм аны үзенең ярдәмчесе итеп билгели.

## Гомәрнең хәлифәгә нәсыйхәт бирүе

Сөләйман бине Габделмәлик хәлифә булгач, ул Гомәргә: «Әгәр син мөселманнар өчен файдалы берәр нәрсәне белсәң, миңа хәбәр ит», – дип әйткән. Шул рәвешле, Гомәр Сөләйманга мөмкин булган кадәр киңәшләрен биргән, нәсыйхәт кылган. Мәсәлән, ул вакытларда кайбер намазлар вакытыннан соңрак укыла торган булган, Гомәр исә ул намазларны вакыты кергәч үк укырга киңәш иткән. Шулай ук Гомәрнең киңәше белән Сөләйман хәлифә залим, гадел булмаган әмирләрне алыштырган.

Гомәр Сөләйман белән бергә булып, аңа һәрдаим Ахирәтне, җаваплылыкны искә төшереп торган.

Бервакыт алар хаҗда булганда, Сөләйман кешеләрнең күплегенә сокланып, Гомәргә болай дип әйткән: «Күрче, күпме кеше Аллаһы Тәгаләне

ярата. Боларның санын фәкать Аллаһы гына белә». Гомәр бу мизгелне Сөләйманга нәсыйхәт әйтер өчен кулланып: «Әйе, син бүген аларның саны белән мактанасың, сөенәсең. Кыяməттә син аларның һәрберсе өчен җавап тотасыңны онытма!» – дип җавап кайтарган. Сөләйман аның сүзләрен ишетеп, мәгънәсен аңлап елаган.

Икенче вакыт Гомәр белән Сөләйман күк күкрәп, яшен яшьнәгәнен күргәннәр. Сөләйман Гомәрдән: «Нинди куркыныч төн. Синең мондый төнне күргәнең һәм мондый тавышны ишеткәнең бармы?» – дип сораган. Гомәр исә бу юлы да хикмәтле җавап кайтарган: «Әй мөэминнәрнең әмире! Син Аллаһының рәхмәт тавышын ишетәсең. Әгәр Аллаһы Тәгаләнең ачуы тавышын ишетсәң, ни булыр?»

## Хәлифә вазифасын үз өстенә алуы

Сөләйман озак вакыт хәлифәлек итә алмаган. Авырып, үлем түшәгенә яткач, ул хәлифәлекне кемгә калдырырга, дип уйлана башлаган. Вәзирен чакыртып, аның белән киңәшләшкән, үз фикерләре белән уртаклашкан. Вәзире Гомәргә ишарә иткән. Ләкин моңа киртә булып, Сөләйманның әтисе Габделмәликнең васыяте торган. Аның васыяте буенча, Гатика исемле хатынының Язид бине Габделмәлик исемле улы хәлифә булырга тиешле. Ләкин Сөләйман үз вәзиренең киңәшен тотып, васыять язган. Ул васыять буенча, иң элек Гомәр бине Габделгазиз, аннан соң Язид бине Габделмәлик хәлифә вазифасына билгеләнергә тиешле булган.

Гомәр хәлифә булыр алдыннан, минбәргә менеп, болай дип әйткән: «Әй, мөселманнар, мин бу урынны үзем теләмәдем, бу – минем өчен имтихан, әгәр мин сезгә ошамасам, үзегез өчен башка кешене сайлый аласыз».

Халык бик гаҗәпләнгән, чөнки бу сүзләр аларга тугры хәлифәләр заманын исләренә төшергән. Алар барысы да: «Без риза», – дип кычкырганнар. Халык тынычлангач, Гомәр тагын сүзен дәвам иткән: «Мин сезгә

тәкъвалы булырга нәсыйхәт итәм. Үлемне күбрәк исегезгә төшерергә тырышыгыз. Бу өмәттә Раббылары һәм Китаплары аркасында каршылык булмас, бәлки динар һәм дирһәм сәбәпле каршылык булыр. Мин һәр кешегә аның хакын гына бирермен. Әгәр мин Аллаһы Тәгаләгә буйсынсам, сез дә миңа буйсыныгыз, әгәр мин Аллаһы Тәгаләгә буйсынмасам, сез дә миңа буйсынмагыз».

## Гомәр бине Габделгазизнең хәлифәлеге

Гомәр хәлифә булгач, үзенә һәм туганнарына хаксыз кергән малларны хәлифәлек казнасына кайтарган. Бу гамәлне ул үзеннән башлый. Үзенең һәм хәлифә сараеның бөтен зиннәтләрен казнага кайтарган. Ул тулаем купшы тормыш рәвешеннән баш тарткан. Өмәвиләрнең зиннәтле сараен ташлап, гади генә бер йортта яшәгән. Үзенең барлык мал-мөлкәтен хәлифәлек казнасына сарыф иткән. Хәлифә булган көнне аның еллык хезмәт хакы кырык мең динар булса, үлгән көнне дүрт йөз динар гына тәшкил иткән.

Шулай ук ул үзенең хатынына да: «Әй Фатыйма, сайла, яки син үзеңнең зиннәтләреңне казнага кайтарасың, яки инде миңа сине талак кылырга рөхсәт ит. Мин бу малның өебездә булуын теләмим», – дип әйткән. Хатыны озак уйламыйча, алтыннарын, үзенең барлык зиннәтләрен казнага кайтарган. Гомәрнең бердәнбер кереме – Сувәйдә шәһәрендәге җир биләмәсе булган, анысы да елына бары тик 200 динар гына китергән.

Гомәр бине Габделгазиз идарә иткән дәвердә хәлифәлектә гаделлек хөкем сөргән, мөселманнарда мал күбәеп киткән. Ярлыларга үзләренең тормышларын яхшыртырга мөмкинлекләр тудырылган. Гомәр бурычлыларга үзләренең әҗәтләрен кайтарырга булышкан, ярлылык сәбәпле өйләнә алмаучыларга акчалата ярдәм иткән. Йортлары булмаган кешеләргә йорт салырга, утырып йөрергә хайваны булмаган кешеләргә утырып йөрер өчен хайван алып бирергә кушкан. Шуннан соң да халыкта

мал артык калган. Ул малга Гомәр бодай сатып алып, кошлар ач булмасыннар өчен, тауларга чәчәргә кушкан. Әйткәнебезчә, халык шундый мул тормышта яшәгән ки, хәтта үз малын ярлыларга садака буларак таратырга теләгән кеше, бу акчаларны алырлык ярлы кеше таба алмаган һәм башка җирләргә барып, ярлы кешеләрне эзләргә мәҗбүр булган.

Гомәр хәлифә халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә зур игътибар биргән. Үзе идарә иткән дәвердә ул элеккеге коеларны төзәткән һәм яңаларын казыган, яңа юллар салып, күп мәчетләр төзегән. Ул моңа кадәр идарәдә булган түрәләрне дә хаксыз рәвештә алган малларын кире казнага кайтарырга мәҗбүр иткән. Шулай ук, халыкка да хаксыз алынган малларын кире кайтарткан.

Гомәр бине Габделгазиз ил белән гадел идарә итеп кенә калмаган, ул галим дә, хафиз, дин белгече һәм мөҗтәһид тә булган. Ул мәчетләрдә михраблар (Мәккәгә таба юнәлешне күрсәткән мәчетнең эчке диварындагы уем) ясый башлаган. Коръәнне өйрәнүгә бик зур игътибар биргән һәм башкаларны да шуңа өндәгән. Гомәр идарә иткән дәвердә хәдисләрне язып ала һәм җыя башлаганнар.

Гомәр бик тәкъва һәм нык гыйлемле кеше булган. Һәрдаим Аллаһы Тәгаләгә сыенып, Аңа гыйбадәт кылган, булганына канәгатьлек белдереп, шөкер иткән.

## Гомәрнең гаделлеге

Гомәр идарә иткән дәвердә казнага күп мал керсә дә, ул үзенә бер дирһәм дә алмый. Киресенчә, ул казна кеременнән генә түгел, хәтта сарай ярдәмчеләреннән дә баш тарткан. Киемнәреннән дә бары тик бер пар кием калдырган. Аны шактый озак кигәнгә, киеме таушалып, ямаулар салынган булган. Кайчакларда, шул киеме юылып, кибеп җитмәгәнгә күрә, ул барасы җиренә соңарган.

Гомәрнең гаделлеген тагын бер вакыйгага бәйле карап үтик.

Гомәр бине Габделгазиз заманында мөселман гаскәре Сәмәрканд шәһәренә бәреп керә. Сәмәрканд әһелләре мөселманнарның гаделлеген белеп, Гомәргә илчеләр җибәреп, Кутайбә исемле гаскәр башлыгын шикаять кылалар: «Ул тиешле булган вакыт көтеп тормыйча, безнең шәһәребезгә бәреп керде», – дип әйтәләр. Гомәр шәһәр башлыгына хат яза. Ул хатта казыйны билгеләп, бу мәсьәләне чишәргә куша. Шәһәр башлыгы казыйны билгели дә, казый шундый хөкем чыгара: «Мөселман гаскәре Сәмәрканд шәһәреннән чыгып, тиешле булган вакыт көтеп торырга тиеш була. Аннан соң, яңа килешү төзелергә тиеш, шуннан соң гына мөселман гаскәре кире шәһәргә керергә хаклы була».

Мөселман гаскәре бу хөкемне үти, Сәмәрканд шәһәреннән чыгып тора, аннан соң Сәмәрканд әһелләре белән яңа килешү төзеп, кире шәһәргә керә. Мондый гаделлекне күреп, күп кеше Ислам динен кабул иткән.

## Гомәрнең вафат булуы

Гомәр бине Габделгазиз өч елга якын идарә иткәннән соң, аның кинәт сәламәтлеге начарлана. Кайбер чыганакларда аның яман шеш авыруыннан газапланганын әйтәләр, ә кайберләрендә исә үлемен агулану сәбәпле дип күрсәтәләр. Гомәр өмәвиләрдән хаксыз алынган малларын казнага кайтарта. Шул сәбәпле, алар аңа агу эчерәләр. Кешеләр аның турында сихерләгәннәр, дип уйлыйлар. Ләкин ул үзе: «Мин үземнең агу эчкән сәгатемне беләм», – дип әйткән. Аннан соң хезмәтчесен чакыртып: «Ни сәбәпле син миңа агу эчердең?» – дип сораган. Хезмәтчесе аңа болай дип җавап кайтарган: «Мең дирһәм өчен һәм азат ителүем өчен». Аннан соң Гомәр хезмәтчесенә мең дирһәмне китерергә кушкан. Хезмәтчесе акчаны алып килгәч, Гомәр ул мең дирһәмне казнага кайтарган, чөнки ул мал хак белән табылмаган.

Үлеме алдыннан Гомәр бик күп тапкыр Коръәни Кәримнең түбәндәге аятен кабатлый:

تِلْكَ الدَّارُ الْآخِرَةُ نَجْعَلُهَا لِلَّذِينَ لَا يُرِيدُونَ عُلُوًّا فِي الْأَرْضِ وَلَا فَسَادًا ۚ وَالْعَاقِبَةُ لِلْمُتَّقِينَ ﴿٨٣﴾

> **«Без Ахирәтне, иман китерүдән вә Аллаһыга итагать итүдән олугланмаган һәм җир өстендә бозыклык фәсәд кыйлмаган хак мөэминнәр файдасына кылырбыз. Аллаһыга карышудан гөнаһлы булудан сакланучы мөэминнәргә эшенең ахырында уңыш, Ахирәттә бәхет булыр».**

«Касас / Хикәя», 28:83

Гомәр бине Габделгазиз һиҗри белән 101 нче елда (милади белән 720 ел) раҗәб аеның беренче көнендә 40 яшендә вафат булган. Ул Димәшкъта җирләнгән.

# Мөэминнәрнең анасы – Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә

## Нәселе

Аның әтисе – Әбү Өмәйә бине Әл-Могыйра – Мәхзүм кабиләсенең иң мәшһүр һәм күренекле җитәкчеләренең берсе булган. Ул гарәпләр арасында үзенең юмартлыгы белән дан тоткан. Моның өчен аны «мосафирларга изгелек кылучы» дип йөрткәннәр.

Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһәнең ире Габдуллаһ бине Габделәсәд радыялллаһу ганһе исемле кеше – беренче ун мөселманның берсе булган. Аңа кадәр Әбү Бәкер белән берничә кеше генә Ислам кабул иткән.

Өмме Сәләмә 580 нче елда Мәккәдә туган. Аның үз исеме Һинд булган, ләкин бөтен кеше дә аны Өмме Сәләмә дип белгәннәр. Бу кушамат киләчәктә аның чын исемен алыштырган.

## Һиҗрәте

Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә ире белән Ислам кабул итеп, беренче мөслимәләрдән саналган. Эзәрлекләүләр һәм рәнҗетүләр түзә алмаслык дәрәҗәгә җиткәч, Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам мөселманнарга ватаннарын калдырып, Хәбәшкә (Эфиопия) күчеп китәргә рөхсәт иткән. Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә һәм аның ире мөһаҗирләрнең беренче төркемендә була. Монда күченеп килгәч тә, мөселманнар үз туган якларын бик нык сагыналар һәм озакламый кире әйләнеп кайталар. Ләкин монда мөшрикләр мөселманнарны җәзалап, куркытып, шуннан тәм табалар.

Шушы шартларда Мөхәммәд галәйһиссәлам сәхабәләренә Мәдинәгә күчеп китәргә рөхсәт биргән. Өмме Сәләмә һәм аның ире динне һәм үзләрен саклап, корәешлеләрдән качып китүче беренче мөһаҗирләр була.

Әмма аларның һиҗрәтләре алар уйлаганча гади һәм җиңел эш булып чыкмый. Мәккәдән чыкканда ук аларны Бәнү Мәхзүм, ягъни үз кабилә кешеләре камап алалар. Алар иренә: «Әгәр дә син үзеңнең җаныңны һәлак итәргә телисең икән, бу хатынның ни гаебе бар?! Ул безнең кабиләдән. Ни өчен без аны сиңа чит җирләргә алып китәргә рөхсәт итәргә тиеш?!» – дип әйтәләр. Шуннан соң иренә ташланалар, ә Өмме Сәләмәнең үзен кулга төшерәләр.

Иренең кабиләсе Бәнү Габделәсәд кешеләре Өмме Сәләмәнең үзен һәм улын кулга алуларын күргәч: «Без бу баланы сездә калдырмыйбыз. Ул – безнең кабилә баласы, һәм без – аның тәрбиячеләре», – дип әйтәләр.

Шуннан соң ике як кешеләре дә баланы үзләренә тарта башлыйлар. Тартыша торгач, хәтта кулын каймыктыралар.

Бу хәлләр барысы да аның күз алдында була. Баласын Габделәсәд кабиләсе кешеләре үзләре белән алып китәләр. Ире җаны һәм дине чакыруы буенча Мәдинәгә юнәлә. Өмме Сәләмәне исә Бәнү Мәхзүм кешеләре кулга алып, үзләрендә калдыралар.

Ул һәр көнне сахрага чыгып, бу фаҗига булган урында утырган. Шулай бер ел вакыт узып та киткән. Бервакыт агасының улы аны кызганып, кабилә башлыкларыннан аңа карата мәрхәмәтле булуларын сорый. Шул рәвешле, аңа ире янына китәргә рөхсәт итәләр, баласын да үзенә кире кайтаралар.

Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһәнең бер дә Мәккәдә каласы килмәгән. Шуңа да ул кечкенә улын алып, Мәдинәгә юнәлгән.

Мәккәдән өч миль ераклыктагы Тәним дигән урынга җиткәч, юлында аңа Госман бине Талхә радыяллаһу ганһе очраган һәм аннан: «Син кая юнәлдең, әй Өмме Сәләмә?» – дип сораган. Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә аңа: «Мин ирем янына Мәдинәгә барам», – дип җавап кайтарган. «Син үзең генә барасыңмы, яныңда беркем дә юкмы?» – дип сораган аннан Госман бине Талхә. Өмме Сәләмә: «Аллаһы белән ант итәм,

Аллаһыдан һәм улымнан кала минем белән беркем дә юк», – дип җавап кайтарган. Госман моңа бик борчылып: «Аллаһы белән ант итәм, син Мәдинәгә җиткәнче, мин сине үзеңне генә калдырмыйм», – дип Өмме Сәләмәне тынычландырган.

Юлда барганда Госман бине Талхә Өмме Сәләмәгә нык итагать күрсәткән. Өмме Сәләмә үзе бу хәлләр турында түбәндәгечә искә алган:

«Аллаһы белән ант итәм, минем гомеремдә дә аннан намуслырак, киң күңеллерәк юлдашым булмады. Без ял итәргә туктаганда ул минем дөямне тезенә чүктерә дә, мин иярдән төшеп урнашканчы читкә китеп тора. Шуннан соң килеп дөяне туара һәм агачка бәйләп куя иде...».

Мәдинә янындагы Куба авылын күргәч, Госман бине Талхә аңа: Синең ирең бу авылда. Аллаһының рәхмәте белән шул авылга кер», – дип әйткән һәм үзе яңадан Мәккәгә юнәлгән.

Озак вакыт аерылып торганнан соң гаилә янәдән кушылган.

Шуннан соң Өмме Сәләмәнең ире Бәдер сугышында катнашкан. Аннан Өхед сугышында катнашып, бик каты яраланган. Ярасы ялкынсынып, ул урын өстенә ятарга мәҗбүр булган.

## Иренең вафаты

Авырып ятканда ире хатынына: «Әй Өмме Сәләмә, мин Аллаһы Илчесенең болай дигәнен ишеттем: «Кемгә дә булса кайгы килсә, ул: «Дөреслектә, без Аллаһыныкы һәм Аңа әйләнеп кайтачакбыз. Әй Аллаһы, мин карышусыз әлеге бәхетсезлекне кабул иттем. Әй Аллаһы, миңа арттырып савап бир», – дип әйтсен, Аллаһы һичшиксез аның теләген үтәячәк».

Түшәктә ятканда хәлен белергә аның янына Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дә килгән. Ул китәргә дә өлгермәгән, Әбү Сәләмә радыяллаһу ганһә вафат булган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзенең мөбарәк куллары белән аның күзләрен йомдырган.

Иренең вафатыннан соң Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән иренең рухына ничек дога кылырга кирәклеген сораган. Пәйгамбәребез аңа җавап итеп болай дип әйткән: «Йә Аллаһым! Мине һәм аны да гафу ит, кичер. Миңа аннан соң (иремнән) тагын да яхшыракны насыйп ит», – дип әйт». Өмме Сәләмә шул рәвешле дога кылган, ләкин үзенә Әбү Сәләмәдән дә хәерлерәкне уйламаган.

Мөселманнар барысы да Өмме Сәләмәнең кайгысын уртаклашканнар. Әле үсеп, тернәкләнергә дә өлгермәгән кечкенә балаларыннан кала, Мәдинәдә аның беркеме дә булмаган.

## Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһәнең Мөхәммәд галәйһиссәлам белән никахы

Үзенең дине өчен Өмме Сәләмә бик күп авырлыклар кичергән. Ләкин төрле сынаулар алдында да ул югалып калмаган, диненнән дә баш тартмаган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дүрт бала белән тол калган сәхабә хатынының бу хәленә тыныч кына карый алмаган.

Өмме Сәләмәнең гыйддәсе беткәч, аңа Әбү Бәкер яучы җибәргән, ләкин ул аның тәкъдимен кабул итмәгән. Аннан соң Гомәр бине Хаттаб тәкъдим ясаган, Өмме Сәләмә аннан да баш тарткан.

Аннан соң Өмме Сәләмә янына Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм килгән. Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә: «Әй Аллаһының Илчесе, минем өч сыйфатым бар: мин бик көнче хатын, шуңа күрә, син миңа ачуланырсың да, моның өчен Аллаһы мине җәзалар дип куркам. Моннан тыш, мин инде олы яшьтә һәм минем балаларым бар. Минем яктан бернинди ышанычлы кеше дә юк», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аңа болай дип җавап биргән: «Син үзеңнең артык көнче булуың турында искә алдың. Мин Аллаһыга дога кылып, синең әлеге сыйфаттан котылуыңны сораячакмын. Син үзеңнең яшең турында искә алдың, әмма мин дә синең кебек үк яшьтә. Балаларыңа

килгәндә, мин аларны үземнеке дип саныйм. Син үз ягыңнан ышанычлы кеше юк дип әйтәсең. Ләкин андый ышанычлыларның берәрсе монда булса яки булмаса да, сине миңа кияүгә бирергә каршы булган берсе дә юк».

Алар 4 нче һиҗри елның шәүвәл аенда никахлашалар. Өмме Сәләмә үзенең намуслылыгы һәм тәкъвалыгы белән башкалардан аерылып торган. Хатын-кыз сәхабәләр арасында фикһка бәйле мәсьәләләрне яхшы белгән. Шулай ук хәдисләр тапшыруда да ул үзеннән зур өлеш керткән. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән 378 хәдис тапшырган.

Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә акыллы, үткен булган, иң авыр хәлләрдән дә чыгу юлларын таба алган. Ул хәтта Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә дә кайбер мәсьәләләр буенча карар кабул иткәндә үз киңәшләрен биргән. Мәсәлән, Хөдәйбия килешүе төзегәннән соң, Аллаһының Илчесе сәхабәләргә корбаннар чалырга һәм чәчләрен кыркырга (ихрамнан чыгарга) боера. Ләкин сәхабәләр килешүнең шартлары белән ризалашсалар да, Мөхәммәд галәйһиссәламнең әмерен тыңламыйлар. Аллаһының Илчесе үз сүзләрен өч тапкыр кабатласа да, беркем ул әйткәнчә эшләргә ашыкмый. Пәйгамбәребез галәйһиссәламне бу хәл бик борчый һәм ул бу турыда Өмме Сәләмәгә дә әйткән. Өмме Сәләмә исә аңа: «Йә Аллаһының Илчесе, синең әмереңне үтәүләрен телисеңме? Бар, үзең корбан чал һәм чәчеңне кыркыт (алдырт). Сәхабәләргә бернәрсә дә әйтмә!» – дип әйткән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аның киңәшен тыңлаган. Сәхабәләр дә аның артыннан нәкъ шулай эшләгәннәр.

Мөэминнәрнең анасы Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә һиҗри белән 61 нче елда 84 яшендә вафат була. Җеназа намазын аңа Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһә укый. Аны Җәннәт Әл-Бакыйгъ зиратына күмәләр.

# Фән

# Шәригать хөкемнәре

## Бисмилләһир-рахмәнир-рахим

1. «Таләбүл гыйльми фәридатүн галәә-күлли мүслимин вә мүслимәтүн».

Мәгънәсе: Шәригать гыйлемен белергә тырышу һәрбер мөселман иргә һәм мөселман хатын– кызга фарыз (үтәлергә тиеш эш).

2. «Әт-тәфәккуһу фид-диини хәккун галәә күлли мүслимин».

Мәгънәсе: Дин хөкемнәрендә галим булу һәр мөселманга тиешле эш.

3. «Иннәллааһә Тәгалә фәрада фәраанда фәләә түдыйгууһәә вә хәддә хүдүүдән, фәләә тәгтәдүүһәә вә хәррамә әшйәә-ә фәләә тәңтәһикүүһәә вә сәкәт ган әшйәә-ә рахмәтәл-ләкәм гайра нисйәәниң, фәләә тәбъхәсүү ганһәә».

Мәгънәсе: Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә берничә гамәлләрне фарыз кылды. Сез аны әда (түләү, үтәү) кылмыйча зайг кылмагыз (әрәм-шәрәм итеп югалтмагыз). Вә дәхи ничә чикләр тәгаен кылынды (билгеләнде), ул чикләрне сез һич үтмәгез. Вә янә берничә төрле гамәлләр харам кылынды, аларны сез һичбер вакытта кылмагыз. Вә дәхи берничә төрле эшләрнең сөйләнми калулары, онытылганлыктан түгел, бәлки сезгә мәрхәмәт өчен (шәригатьтә бәян кылынмаган, аңлатылмаган гамәлләрнең хөкемнәрен күп тикшереп гөнаһлы булмагыз).

## Шәригать

Шәригать – кешеләрнең гамәлләре хакында Ислам дине тарафыннан боерылган хөкемнәр димәктер. Шәригать хөкемнәрен белү һәрбер мөэмин-мөселманга фарыздыр. Ләкин мәгълүмдер: һәрбер мөселманга шәригать хөкемнәрен олуг гарәби китаплардан укып белү насыйп булмый,

чөнки дөнья мәгыйшәте бәласе мөселманны кәсеп вә һөнәр гыйлемнәре илә шөгыльләнергә мәҗбүр кыладыр. Ни кылмак кирәк?

Дөньяда торуыбыздан дөнья гыйлеме вә дөнья мөгамәләләре дә лазем, хәтта бер микъдары шәригать буенча фарыздыр. Ләкин дөнья мөгамәләсе илә мәшгуль булган кешеләргә дә фарыз булган шәригать гыйлеменнән бөтенләй мәхрүм калу һич мәгъкуль түгелдер. Камил мөэмин вә мөселманмын дигән кешегә шәригать хөкемнәренең һәрберсен белеп тору һәм шәригатьтә боерылган эшләрне кылырга вә тыелган эшләрдән сакланырга тырышу бик тиешледер. Ошбу китап гыйлеме, азлыгы яки вакыты тарлыгы сәбәпле, олуг китаплардан карап, шәригать хөкемнәрен аңлый алмаган кешеләр өчен язылды. Монда шәригатьнең һәрбер мәшһүр хөкемнәре кыскалык илә саналмыштыр. Тәфсилләп белүне теләгән кеше өчен, олуг китаплардан карарга һәрвакыт юл ачык. Башка китаплардан карап аңлый алмаслык кешеләр, ошбу китаптан файда хасил итәчәкләрдер, ин шә Аллаһ. Хосусан мәктәп шәкертләре бу китапны укып һәрбер хөкемен хәтерләренә алып калырга тиешледер. Чөнки яшь вакытта укылган китапларның күбесе олуг булгач та хәтердән чыкмый. Чыкканнары да кабат каралганда тиз искә төшә.

Бәндәләрнең гамәлләре Ислам дине буенча сигез төрледер: фарыз, вәҗиб, сөннәт, мөстәхәб, мөбах, харам, мәкруһ, мөстәкрәһ.

## Фарыз гамәлләр

Фарыз – шул гамәлдер ки, шәригатьтә аны кылырга боерылмыштыр. Аны кылган кеше саваплы булыр, кылмый калдырган кеше гөнаһлы булыр. Аның фарызлыгына ышанмаган кеше имансыз булыр.

Фарыз гамәлләре ике төрледер: берсе – фарыз гайн, икенчесе – фарыз кифаядер.

Фарыз гайн – шул гамәлдер ки, аны һәрбер мөэмин бәндә үзе үтәргә тиеш. Бер җәмәгать эчендә берничә кешенең кылуы илә башка кешеләрнең өстеннән төшми. Мәсәлән: намаз уку, ураза тоту кебек гамәлләр.

Фарыз кифая – бер җәмәгатьнең мәҗмугына җыелып кылу тиешле булган фарыздыр. Араларыннан берсе генә үтәсә дә, башкаларның өстеннән төшәдер, ягъни башка кешеләр кылмый калсалар да, гөнаһтан котылырлар. Ләкин никадәр кеше кылса да, кылган бар кеше саваплы була. Әгәр дә бер җәмәгать эчендә һичбер кеше кылмый калса, шул җәмәгать эчендә булган кешеләрнең һәркайсы гөнаһлы була. Мәсәлән: ятимнәрне вә зәгыйфь картларны, вә ялгыз авыруларны тәрбияләү, мәетләрне дәфен кылу, вә аларга җеназа намазлары уку кебек гамәлләр фарыз кифая буладыр.

## Фарыз гайн булган гамәлләр

Мөэмин-мөселман булган кешегә фарыз булган гамәлләр йөздән артыктыр. Ошбу фарызлардан фарыз гайн булганнары илле дүрттер. Алар ошбулардыр:

1. Аллаһы Тәгаләнең барлыгына вә берлегенә, вә күркәм сыйфатларына игътикад кылу (ышану).

2. Мөхәммәд галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең безләргә Ислам динен өйрәтү өчен җибәрелгән хак пәйгамбәре, дип игътикад кылу.

3. Ислам диненең хаклыгына вә Ислам динендә булган хөкемнәрнең һәрберсенең хаклыгына игътикад кылу.

4. Үзеңнең мөселманлыгын вә Ислам диненең хаклыгын тел белән икърар кылу (раслау).

5. Һәр көн биш вакыт намаз уку.

6. Рамазан аенда һәр көн руза тоту.

7. Бай кеше фәкыйрьләргә малының зәкятен бирү.

8. Дәүләте җитәрлек кеше Мәккә-и Мөкәррәмәгә барып, гомерендә бер мәртәбә булса да хаҗ кылу.

9. Үскән ашлыкларның, печәннәрнең вә балларның гошерен фәкыйрьләргә бирү.

10. Кылу фарыз булган гамәл вә гыйбадәтләрне өйрәнү.

11. Җомга көн җомга намазын уку.

12. Аллаһы Тәгаләнең хөкемнәренә риза булу.

13. Һәр гыйбадәтне ихлас белән Аллаһы Тәгалә өчен генә кылу.

14. Аллаһы Тәгаләне мөмкин кадәр һәрвакыт истә тоту.

15. Аллаһы Тәгаләдән куркып, гөнаһ эшләрдән саклану.

16. Кылган гөнаһлар өчен үкенеп тәүбә кылу.

17. Мәхлүкатне күреп, Аллаһы Тәгаләнең кодрәтен вә камиллеген тәфәккер (фикерләү, уйлау) кылу.

18. Биргән нигъмәтләре өчен Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылу.

19. Сәбәбенә керешкәннән соң, һәр эшне Аллаһы Тәгаләнең тәкъдиренә, кодрәтенә тапшыру.

20. Үзенә килгән бәла вә казаларга Аллаһы Тәгаләнең каза вә тәкъдире дип күңелдән риза булу.

21. Нәфес теләге күңелгә бер гөнаһ эш кылырга уй кертсә, ул гөнаһны кылудан саклану.

22. Сүздә вә һәрбер эштә тугрылыкта вә хаклыкта булу.

23. Мәхкәмәдә (судта) шаһит булган кеше күргәнен тугры сөйләү.

24. Үзен вә бала-чагасын тәрбия кылырлык кадәр мал кәсеп кылу.

25. Зарур кирәк кадәр тәгам ашау.

26. Зарур кадәр су заты эчү.

27. Зарурый тиешле киемнәр кию.

28. Хаксызлык белән кергән кеше малын иясенә тапшыру.

29. Вакытында укылмый калган намазларны каза кылу.

30. Тотылмый калган Рамазан рузаларын каза кылу.

31. Нияте белән керешелгән Рамазан рузасын ихтыяры белән бозган кеше руза кифарәтен үтәү.

32. Вакытында бирелми калган зәкят вә гошерләрне бирү.

33. Бурычларын үти алмаган кеше, үзе вафат булганчы, варисларына калган малыннан шул бурычларны үтәү белән васыять әйтү.

34. Варислар мәетнең тапшырырга әйтеп калдырган бурычларын, үзләренә мирас һич калмаслык булса да, тапшырып бетерү.

35. Ир хатынын гаделлек вә тугрылык белән, җәбер кылмыйча тәрбия кылу.

36. Ир хатыны һәм үзе өчен аерым бер йорт яки бүлмә әзер кылу.

37. Ир хатынын гадәтчә кирәкле киемнәр белән киендерү.

38. Ир хатынын хәләл тәгамнәр белән туйдыру.

39. Бала ата-анасын мөмкин кадәр хөрмәт, хезмәт, итагать вә тәгъзыйм, түбәнчелек белән разый кылу.

40. Ата сабый балаларын кирәгенчә тәрбия кылу.

41. Бала фәкыйрь ата-анасын тәрбия кылу.

42. Сабый йә зәгыйфь булган, мәхрүм, өлешсез калган мескен ир кардәшләрен вә фәкыйрь кыз кардәшләрен тәрбия кылу.

Бу тәрбияләр көче вә дәүләте җитәрлек кешеләргә генә фарыздыр, зәгыйфь вә фәкыйрь кешеләргә гаҗиз (көчсез) булганнары өчен мәгъзурдыр (тиеш түгелдер).

43. Нәзер итеп әйтелгән гыйбадәтләрне үтәү.

44. Имин илә кылырмын йә кылмамын, дип әйтелгән эшне үтәү.

45. Имин итеп (ышанычлы) әйтелгән эшне кыла алмаган кеше имин кифарәтен үтәү.

46. Коръән укыганны ишеткән кешегә тыңлап, тик тору.

47. Ир хатынның мәһәрен күңел хушлыгы белән бирү.

48. Җөнеб вә арусыз булган кеше госел кылу.

49. Хәездән арынган хатын госел кылу.

50. Нифәстән арынган хатын госел кылу.

51. Сүз үтәрлек кешеләрне фарыз булган эшләрне кылырга димләү.

52. Сүз үтәрлек кешеләрне харам эшләрне кылмаска димләү.

53. Шәригатьтә харам булган эшләрне кылудан саклану.

54. Фарыз булган гыйбадәтләрне җәмигъ фарызлары белән үтәү. Мәсәлән: тәһарәттә – 4 фарыз, тәяммүмдә – 4 фарыз, госелдә – 3 фарыз, намазның тышында – 8 фарыз, эчендә – 8 фарыз, рузада – 3 фарыз, хаждаа – 3 фарыз.

## Фарыз кифая булган гамәлләр

Әһле Ислам җәмәгатенә кылуы фарыз-кифая булган гамәлләрнең мәшһүрләре 15тер:

1. Шәригать гыйлемлекләрен бик камил белү.

2. Надан кешеләргә шәригать хөкемнәрен өйрәтү.

3. Коръәнне күңелгә бикләп, бөтен Коръәнне күрмичә укырлык хафиз булу.

4. Дөнья тереклеге өчен адәмнәргә зарури булган кәсепләрне кылу.

5. Һич ярдәмчесе булмаган фәкыйрь, зәгыйфь вә карт кешеләрне тәрбия кылу.

6. Һич ярдәм кылыр кешесе булмаган зәгыйфь авыруларга хөрмәт вә ярдәм кылу.

7. Ятим калган балаларны тәрбия кылу.

8. Авыруларның хәлләрен белеп тору.

9. Мәетне юып кәфенләү.

10. Мәеткә дога кылу өчен, җеназа намазы уку.

11. Кабер казып, дәфен кылу.

12. Сәлам биргән кешегә каршы сәлам кайтару.

13. Төчкергәч «Әлхәмдүлилләһи» дигән кешегә «Ярхәмүкәллаһү» диеп әйтү.

14. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең исем шәрифе зекер кылынганда, салават әйтү.

15. Ватанны дошманнардан саклау өчен гаскәрлек кылу.

## Вәҗиб гамәлләр

Вәҗиб гамәлләр дә фарыз кебек шәригатьтә кылырга боерылган гамәлдер. Вәҗиб гамәлне кылган кеше саваплы булыр, гозерсез (сәбәпсез) кылмаган кеше гөнаһлы булыр, вәҗиблегенә ышанмаган кеше имансыз ук булмаса да, зур гөнаһлы булыр. Мөэмин вә мөселман булган кешегә кылуы вәҗиб булган гамәлләрнең мәшһүрләре 40тыр:

1. Йорт кирәкләреннән артык малы булган кеше Рамазаннан соң фәкыйрьләргә үзе һәм сабый балалары өчен фитыра садакасы бирү.

2. Йорт кирәгеннән артык малы булган кешегә Корбан гаете булган көннәрдә үзе өчен корбан чалу.

3. Ихрам кылып, кәгъбәне тәвәф кылып һәм Сафа илә Мәрвә таулары арасында йөреп, гомерендә бер мәртәбә гомрә хаҗын (гомрә хаҗы фарыз булган хаҗдан башкадыр, кайсы айда кылынса да дөрес).

4. Гает-фитыр вә гает-корбан намазлары уку.

5. Һәр көн ястү намазыннан соң витр намазын уку.

6. Зөлхиҗҗә аенда Гарәфә, гает вә тәшрикъ көннәрендә җәмәгать белән укылган фарыз намазларны укып, сәлам биргәч тә тәкбир-тәшрикъ әйтү.

7. Коръәнне тәҗвид кагыйдәләренә муафыйк итеп, дөресләп уку.

8. Коръәндәге 14 сәҗдә аятьләреннән берсен укыган вә ишеткән кеше сәҗдә-и тиләвәт кылу.

9. Вәгъдә вә гәһед (килешү) кылып әйтелгән эшне үтәү.

10. Аллаһы Тәгаләнең исемен тәгъзыйм белән олылап (Тәгалә, Тәкаддәсә, Вә җәллә шә’нүһү) диеп зекер кылу.

11. Киләчәк заманда бер эш кылуны сөйләгән вакытта «ин шә Аллаһ, кылырмын» дию.

12. Хатын – иренә, ир – хатынына ягымлы булу.

13. Шәкерт остазын күреп, тәгъзыйм кылу.

14. Күңел илә һәр кешегә хәер эшләрне вә яхшылыкны теләү.

15. Көче җиткән кадәр адәмне вә хайваннарны һәлакәтлектән коткарырга тырышу.

16. Бирелгән бүләк вә һәдияне кабул итү.

17. Бүләккә каршы бүләк бирү.

18. Үзеңә яхшылык иткән кешегә яхшылык итү.

19. Хәләл тәгамле мәҗлескә чакырган кешенең мәҗлесенә бару.

20. Үзеңнең җәбереңтигән кешедән гафу кылып бәхилләвен үтенү.

21. Алучыга сатлык малыңның гаепләрен сөйләү.

22. Иман әһеленең дөньяда рәхәтлеге вә Ахирәттә изгелеге өчен кулыннан килгән кадәр хезмәт вә ярдәм кылу.

23. Иманлы кешенең эшен мөмкин кадәр яхшылыкка юрау.

24. Мосафир кешегә өйлә, икенде вә ястү кеби намазларда дүрт рәкәгать фарызларны ике рәкәгать итеп кыскартып уку.

25. Бер мәҗлестә бер кешегә кылмаган гаепне кылды дип бөһтан (нахак) вә ифтира (яла ягу) кылынса, белгән кеше хаклык илә ул кешенең гаебе юклыгын сөйләп, аны яклау.

26. Ачу килгән кешегә, дин вә гыйбадәтенә зарар килмәслек булганда, өч көн тулгач, тышкы кыяфәттән булса да, үпкәне бетерү.

27. Муафыйк (лаеклы) кеше сораганда, үзенең ризалыгы белән кыз баланы кияүгә бирү.

28. Ихрамлы кешегә кылу харам булган эшне кылган хаҗига тиешле корбан вә тиешле җәзасын үтәү.

29. Күркәм холыклар белән холыклану.

30. Һәр нәрсәгә гыйбрәт күзе белән карап, гыйбрәтләнеп, холыкны төзәтү.

31. Казый вә түрә булган кешегә мазлумнарның шикаятен (гозерен) тыңлап, тугры хөкем кылу.

32. Галим булган кешегә белер өчен соралган мәсьәләгә җавап бирү.

33. Казага калган намаз вә рузалары өчен үзе вафат булганчы, варисларына фидия садакасы бирү илә васыять әйтү.

34. Үзе вафат булганчы, калачак малдан вакытында бирелми калган зәкят гошерләрен үтәү илә варисларына васыять әйтү.

35. Өстенә хаҗ фарыз булып та, вакытында кыла алмаган кеше, варисларына калган малдан бәдел хаҗы кылдыру илә үзе вафат булганчы васыять әйтү.

36. Варис булган кешеләр калган малның өч өлештән бер өлеше кадәресе белән мәетнең әйтеп калдырган васыятьләрен үтәү.

37. Ата-ана балаларына дин, гыйбадәт вә әдәпне өйрәтү.

38. Мөхтәрәм кардәш вә туганнар бер-берсенә дуслык кылышу.

39. Ике хатыны булган кеше хатыннарына тәрбиядә вә нәүбәтләрендә тигезлек вә гаделлек кылу.

40. Һәр гыйбадәттә вәҗиб булган гамәлләрне үтәү. Мәсәлән: намазда – 22 вәҗиб, хаҗда – 5 вәҗиб, гомрәдә – 2 вәҗиб бардыр.

## Сөннәт гамәлләр

Сөннәт шул гамәлдер: пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм ул гамәлләрне күп заман кылмыш вә ул гамәлне кылган кешегә савап булыр, дип сөйләмештер. Хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәламнең өммәтеннән булган кешегә сөннәт гамәлләренең һәркайсын кылырга тырышу тиешледер. Сөннәт гамәлне кылган кеше саваплы булыр, гозерсез (сәбәпсез) кылмаган кеше зур гөнаһлы булмаса да, Кыямәт көнендә шелтәгә тиешле булыр. Вә дәхи Пәйгамбәребезнең

шәфәгатенә лаек булмас. Мөэмин вә мөселман кешегә кылу тиешле булган сөннәт гамәлләренең мәшһүрләре 70тер:

1. Һәрбер яхшы вә изге эшләрне «Бисмилләһ» диеп башлау.

2. Төчкергәннән соң «Әлхәмдүлилләһ» дию.

3. Иманлы кешеләргә очраганда сәлам бирү.

4. Аш ашарга утырганда ике кулны юу.

5. Аш ашап бетергәннән соң, авыз, ике кулны юу.

6. Ашый вә эчә башлаганчы «Бисмилләһ»не әйтү.

7. Ашап-эчеп бетергәннән соң «Әлхәмдүлилләһ» дип, Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылу.

8. Тәгамне утырып ашау.

9. Ашны уң кул белән алып ашау.

10. Эчкәндә касәне уң кул белән тоту.

11. Чүлмәк, чынаяк һәм агач савытлардан ашау-эчү.

12. Икмәктән төшкән валчыкларны җыеп ашау.

13. Күбесенчә арпа икмәге ашау.

14. Аштан элек вә соңра бераз гына тоз кабу.

15. Хатыны вә бала-чагалары белән бергә бер табында ашау.

16. Сөт, зәм-зәм суы вә хуш исле нәрсәләр бирелгәндә, кабул итеп алу.

17. Ак, яшел вә кара төсле киемнәр кию.

18. Киемнәрне нәҗестән саклап, пакь тоту.

19. Киемнәрне тузганчы кию.

20. Тузган киемнәрне юып фәкыйрьләргә бирү.

21. Намаз укыганда башка чалма кию.

22. Йокыга ятканда тәһарәт белән яту.

23. Йокыга ятканда мисвәк, щетка белән авызны чистарту.

24. Тәһарәт алганда мисвәк истигъмал кылып, авызны пакь тоту.

25. Таң атканчы йокыдан тору.

26. Коръән уку алдыннан «Әгузе»не әйтү.

27. Фарыз намазларны җәмәгать белән уку.

28. Фарыз намазларны укыр алдыннан азан вә камәт уку.

29. Намазларны мәхәллә мәчетендә уку.

30. Иртәнге, өйлә, ахшам, ястү вә җомга намазларын сөннәтләре белән уку.

31. Рамазанда тәравих намазларын уку.

32. Тәравих намазларында сүрә-и «Фәтихә» артыннан куша-куша Коръәнне хәтем итү.

33. Рамазанда аз булганда бер тәүлек кадәр мәчеттә гомер кичерү.

34. Рамазанда кояш баегач, ахшам укыганчы авыз ачу.

35. Рамазанда таң алдыннан сәхәр ашау.

36. Җомга көннәрендә, ике гает көннәрендә, Гарәфә көнендә госел коену.

37. Гает фитыра көнендә таң аткач, кояш чыкканчы бер татлы тәгам белән ифтар кылу.

38. Гает корбан көнендә таң атканнан соң, гает намазы укыганчы, руза кеше һичбер тәгам вә су капмыйча тору.

39. Гает корбан намазыннан соң бер татлы тәгам белән яки корбан шулпасы белән ифтар кылу.

40. Гает көннәрендә яхшы киемнәр кию.

41. Авызны истән вә тәгамнән пакь тоту.

42. Мыекның авызга керерлекләрен кисеп, кыскарту.

43. Тырнакларның артыкларын кисү.

44. Култык вә касык төкләрен алу.

45. Ир балаларны унынчы яшенә кадәр сөннәткә утырту.

46. Хатын-кызларга бармакларына кына ягу.

47. Олы кешеләрне олылау.

48. Кечкенә кешеләргә шәфкатьле вә мәрхәмәтле булу.

49. Якын кардәшләрне вә күршеләрне һәм дусларны чакырып кунак итү.

50. Килгән кунакны каршы алу.

51. Һәркемгә дәрәҗәсенә күрә илтифат вә хөрмәт кылу.

52. Кеше йортына кергәнче, рөхсәт сорау.

53. Кеше белән күрешкәндә кул тотышу.

54. Тәрбия кылырга көче җитәрлек булган кешегә хатын алып, өйләнү.

55. Сәламәт булган кызга үсеп җиткәч, кияүгә бару.

56. Туйны халыкка изхар (ачык) кылып, мәшһүр итү.

57. Туй мәҗлесе өчен аш әзерләү.

58. Адәмгә зарар китерә торган хайваннарны бетерү.

59. Имансыз кешеләргә тәүфыйк вә һидаять теләп, дога кылу.

60. Ачуланышкан кешеләрне килештерергә тырышу.

61. Үзенә булуын теләгән эшнең башка кешегә булуына да күңеле разый булу.

62. Үзенә булмавын теләгән эшнең башка кешегә дә булмавын теләү.

63. Ышанычлы мохтаҗ кешеләргә бурычка акча биреп тору.

64. Гарәп телен өйрәнеп, яхшы белү.

65. Хатын-кыз җәмәгатенә һәрбер урында ригая[1] вә ярдәм кылу.

66. Йорт киңәшләрен хатыныңа киңәш итү.

67. Юлга вә сәфәргә юлдашлар белән чыгу.

68. Гыйбрәтләнү өчен каберләрне зиярәт кылу.

69. Авыру булганда, табибка күрсәтеп дәва кылу.

70. Һәрбер гыйбадәтне сөннәтләре белән үтәү. Мәсәлән: тәһарәттә – 20 сөннәт, тәяммүмдә – 6, госелдә–10, намазда – 25, рузада – 6, хаҗ кылуда –10 сөннәт бардыр.

*Әхмәдһади Максудиның «Шәригать хөкемнәре» китабыннан*

---

[1] Ригая – игътибарлылык.

# Коръән ничек саклanган

Коръән берьюлы тулы килеш түгел, ә төрле шартларга һәм вакытка бәйле рәвештә өлешләп иңдерелгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм яшәгән дәвердә аны берьюлы бер китап рәвешендә саклау мөмкин булмаган. Ләкин шуңа да карамастан, Аллаһы Тәгалә аны башка илаһи китаплар арасыннан аерып күрсәткән.

Коръән үзенең саклануы белән каләмгә караганда күбрәк хәтергә бурычлы, дип әйтсәк, арттыру булмас. Мөслимнең «Сахих» җыентыгындагы бер хәдистә Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә: «Ул сиңа су белән дә юылмаслык Китап иңдерәчәк», дип ышандырган.

Бу хәдистән күренгәнчә, төрле афәтләр сәбәпле китаплар юкка чыгачак. Тәурат һәм башка илаһи китаплар белән шулай булды, әмма Коръән кешеләрнең йөрәкләрендә (хәтерләрендә) саклаearначак һәм аңа юкка чыгу куркынычы да янамас.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм пәйгамбәрлегенең башлангыч дәверендә, хәтерендә саклау өчен, вәхи иңдерелгәч тә ул сүзләрне (аятьләрне) кабатлаган. Шуннан соң, Аллаһы Тәгалә Коръәндәге түбәндәге аятьләр белән аңа вәхи иңгәч үк аятьләрне ашыгып кабатлауның кирәк түгеллеген аңлаткан:

لَا تُحَرِّكْ بِهِ لِسَانَكَ لِتَعْجَلَ بِهِ ﴿١٦﴾ إِنَّ عَلَيْنَا جَمْعَهُ وَقُرْآنَهُ ﴿١٧﴾

**«(Җәбраил галәйһиссәлам китергән вәхине тыңлаганда берәр нәрсәне онытa күрмим дип, ул бетергәнче укый башлаган Мөхәммәд!) Аны тизрәк отып алыр өчен телеңне дә кузгатма! Һичшиксез, аны (синең хәтереңдә) җыю һәм укыту да – Безнең өстебездә».**

«Кыямәт», 75:16-17

Аллаһы Тәгалә Үзенең Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмне шундый күркәм хәтер белән бүләкләгән, хәтта Пәйгамбәребез вәхи иңдерелгәч, ул сүзләрне бер генә тапкыр ишетеп тә хәтерендә калдыра торган булган һәм аларны онытмаган. Шул рәвешле, аятьләр иңгәннәр һәм шул ук вакытта аның хәтерендә саклanганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Изге Коръәнне йөрәгендә саклаган һәм шуңа да анда бернинди ялгышлар һәм хаталарга урын калмаган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өстәмә саклык күрсәтеп, һәр елның Рамазан аенда, ә гомеренең соңгы елында ике мәртәбә Җәбраил галәйһиссәлам белән Коръәнне тикшереп, кабатлап чыга торган булган. Җәбраил галәйһиссәлам белән Коръәнне соңгы тапкыр кабатлау «гардә ахирә» дип аталган (Фәтхүл-Бәри, том 9, 36 б.).

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләренә Коръәннең мәгънәсен аңлату белән генә чикләнмәгән, алар шулай ук текстны да өйрәнгәннәр. Коръәнне өйрәнү һәм күңелдән белү теләге сәхабәләрдә шул дәрәҗәдә көчле булган ки, аларның һәммәсе берберсен уздырырга тырышкан. Бер сәхабә хатын-кыз булачак иреннән мәһәр өчен бернәрсә дә сорамыйча, бары тик Коръән өйрәтүен сораган. Йөзләгән сәхабәләр төрле дөньяви теләкләреннән баш тартып, үзләренең тормышларын бары тик Коръән өйрәнүгә багышлаганнар. Алар аны яттан өйрәнеп кенә калмаганнар, ә һәрдаим тәһәҗҗүд намазларында кабатлаганнар. Гобадә бине Әс-Самит (Аллаһы аннан разый булсын) тапшыра: әгәр берәү Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылса, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам ул кешегә әнсарларның берсенә Коръән өйрәтергә кушкан. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең мәчетендә укучыларның һәм Коръән өйрәтүче остазларның тавышлары яңгырап торган, шуңа да Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам хаталарны булдырмас өчен, аларга артык кычкырып укымаска кушкан (Мәнәхил Әл-Гыйрфан, том 1, 234 б.).

Гарәпләр үзләренең үзенчәлекле хәтер сәләтенә ия булулары белән бөтен дөньяга танылганнар. Гасырлар дәвамында җәһилияттә булганнан соң, аларга кулланма буларак Коръәни Кәрим бирелә. Шуңа да алар өчен ул иң кыйммәтлесе булып тора, хәтта алар моны тормышларындагы иң зур казаныш, дип саныйлар. Шул рәвешле, аз гына вакыт эчендә күп кенә сәхабәләр (Аллаһы алардан разый булсын) бик камил дәрәҗәдә Коръәнне яттан белгәннәр. Алар арасында Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Талхә, Сәгъд, Ибне Мәсгуд, Хөзәйфә бине Йәмән, Сәлим Мәвлә Әби Хөзәйфә, Әбү Һөрайра, Габдулла бине Гомәр, Габдулла бине Габбас, Әмир бине Әл-Гас, Мөгавийә, Габдулла бине Зөбәйр, Габдулла бине Әс-Сәгъиб радыяллаһу ганһүмнәр һәм Гайшә, Хафса һәм Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһүннәләр

Кыскача әйткәндә, Исламның беренче елларында Коръәннең саклануы хәтергә нигезләнгән. Бу заманасына күрә иң ышанычлы һәм куркынычсыз чара булган, чөнки ул вакытларда укый һәм яза белүчеләр саны бик аз, ә басма станоклар яки башка нәшер итү төрләре бөтенләй дә булмаган. Әгәр дә Коръәнне саклау язып алуга гына нигезләнгән булса, аны һәр җиргә тарату һәм саклау да мөмкин булмас иде.

Моның урынына Аллаһы Тәгалә гарәпләрне искиткеч камил хәтер белән бүләкләгән. Хәтта гади генә гарәп кешесе дә меңәрләгән шигъри юлны хәтерендә калдырып, теләгән очракта сөйләп бирә алган. Гади халык үзләренең нәсел шәҗәрәсен, кабиләсен һәм хәтта атларын да яттан белгән. Аларның искиткеч хәтер сәләтләре нәтиҗәсендә Коръән Гарәбстанның бик ерак почмакларына кадәр барып ирешкән.

## Коръәннең язма рәвештә җыелуы

Нигездә, Коръәнне саклау сәхабәләрнең хәтеренә бәйле булса да, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның язма рәвештә дә саклануы турында кайгырткан. Зәйд бине Сабит радыяллаһу ганһе риваять иткән:

«Мин Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен Коръән аятьләрен язып бару белән шөгыльләндем. Вәхи иңдерелгән вакытта, аңа бик нык эссе була иде, тир тамчылары аның тәненнән энҗе бөртекләре сыман тәгәриләр иде. Аның бу халәте тәмамлангач, мин калак сөяге яки берәр тукыма кисәген табып, ул миңа әйтеп торганны яза идем. Аягым Коръән язмаларының авырлыгыннан хәлсезләнгәнче язуымны туктатмадым. Аларның авырлыгы шул дәрәҗәгә җитә иде ки, хәтта бу аягым башка йөри алмас инде, дип уйлый идем. Язуымны тәмамлаганнан соң, Аллаһының Илчесе: «Укы», – дип әйтә иде һәм мин язып алганнарны укый идем. Анда ниндидер бер кимчелек булса, ул аны төзәтә иде. Шуннан соң гына кешеләргә тәкъдим итә иде».

Зәйд бине Сабит радыяллаһу ганһедән кала күп кенә башка сәхабәләр Коръәнне язма рәвештә теркәгәннәр. Аларның кайберәүләре: Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали, Өбәй бине Кәгъб, Зөбәйр бине Әл-Гәввам, Мөгавийә, Могыйра бине Шөгъбә, Халид бине Әл-Вәлид, Сабит бине Әл-Кайс һәм Әбан бине Сәгыйд.

Госман радыяллаһу ганһе тапшыра: «Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм чираттагы вәхи иңгәннән соң, язып баручыга шушы иңгән өлешне кайсы сүрәдә һәм кайсы аятьтән соң куярга кирәклеген әйтә иде һәм аның өчен бу гадәти бер эш булды».

Гарәп ярымутравында кәгазь сирәк товар булганга, Коръән аятьләре, нигездә, таш плитәләргә, күн пергаментка, хөрмә ботакларына, бамбук кисәкләренә, агач яфракларына һәм хайваннарның сөякләренә язылган. Шулай ук, сирәк булса да, кәгазь дә кулланылган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм яшәгән дәвердә аның күзәтүе астында Коръәннең күчермәсе (мосхаф) әзерләнә, ләкин ул бер китап кебек түгел, ә аерым кулъязмалар рәвешендә була. Шулай ук, кайбер сәхабәләр Коръән аятьләренең күчермәләрен ясап, үзләрендә саклаганнар. Бу пәйгамбәрлекнең беренче чорында ук таралган. Мәсәлән,

Гомәр радыяллаһу ганһе Ислам динен кабул иткәнчегә кадәр аның апасы һәм җизние (апасының ире) үзләрендә Коръән аятьләренең кулъязмаларын саклаганнар.

## Коръәннең Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе чорында саклануы

Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам яшәгән дәвердә Коръән күчермәләре төрле материалларда языла: кайберләре – күндә, берәүләре агач яфракларында, кайберләре хайван сөякләрендә. Коръәннең тулы күчермәләре бик аз булган. Кайбер сәхабәләрдә бер генә сүрә, икенчеләрендә 5-6 сүрә, өченчеләрендә бөтенләй берничә аять кенә булып, ә кайберләрендә исә аятьләр белән бергә аңлатмалы язмалар да булган.

Шул сәбәпле, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе үзе идарә иткән дәвердә Коръәннең таралган өлешләрен бергә туплау һәм саклау кирәклеген аңлый. Бу олуг бурычны үтәгәндә нинди ысуллар кулланылганы турында Зәйд бине Сабит радыяллаһу ганһе түбәндәгеләрне сөйләгән:

«Бервакыт, Йәмәмә сугышыннан соң ук Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе мине үзенә чакыртты. Мин аның янына килгәч, анда Гомәр радыяллаһу ганһе дә бар иде. Әбү Бәкер миңа: «Гомәр миңа Йәмәмә сугышында күп санлы хафизлар шәһит китүен хәбәр итте. Әгәр хафизлар шул рәвешле һәлак булсалар, Коръәннең күп өлеше юкка чыгар, дип куркам. Шуңа да мин сиңа Коръәнне төрле җирләрдән җыеп, бергә тупларга киңәш итәм», – дип әйтте. Мин Гомәрдән: «Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзе эшли алмаганны, без аны ничек эшләрбез соң?» – дип сорадым. Гомәр: «Аллаһы белән ант итәм, бу иң хәерлесе», – дип әйтте һәм мин аның фикере белән ризалашканчы ул үз сүзләрен кабатлады.

Шуннан соң Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе миңа: «Син яшь һәм акыллы. Сиңа барысы да ышаналар. Син Пәйгамбәр галәйһиссәлам исән чагын-

да ук һәрдаим язып бардың. Шуңа да Коръәннең барлык аятьләрен табып, бергә тупла», – дип әйтте. Аллаһы белән ант итәм, Коръәнне җыю бурычына караганда, иңнәремдә тауны күтәреп бару да миңа җиңелрәк йөк булыр иде кебек. Шул вакытта мин аннан: «Сез ничек Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам үзе эшләмәгән эшкә алынырга карар кылдыгыз?» – дип сорадым. Ул миңа: «Аллаһы белән ант итәм, бу иң хәерлесе», – дип әйтте һәм мин аның һәм Гомәр радыяллаһу ганһенең фикерен кабул иткәнчегә кадәр үз сүзләрен кабатлады. Шуннан соң мин Коръән аятьләрен эзли башладым, шулай ук хөрмә ботакларында, ташлы плитәләрдә язылган һәм кешеләрнең хәтерләрендә сакланган Коръән аятьләрен дә туплап, ахыр чиктә тулы Коръәнне җыйдым».

Монда бер нәрсәне асссызыклап үтәргә кирәктер – Зәйд бине Сабитның Коръәнне ни рәвешле, нинди ысуллар ярдәмендә җыюын төгәл аңлау кирәк. Алда искә алып үткәнчә, ул үзе дә хафиз булган. Шуңа да ул Коръәнне тулысынча үз хәтере буенча яза алыр иде. Шулай ук, бу вакытта әле йөзләгән Коръән-хафизлар исән була, шуңа да ул аларның кайберләренә мөрәҗәгать итә алган.

Шулай ук, Зәйд бине Сабит радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дәверендә яздырып алынган Коръәннең күчермәләрен дә куллана алган. Ләкин үзенә карата булган зур җаваплылыкны тоеп, ул бу ысулларның берсе белән генә чикләнмәгән. Киресенчә, аларның барысын да кулланып, өзлексез иснәд (хәдиснең бирелү чылбыры) аша язма һәм телдән әйтелгән дәлилләрен тикшермичә, бер аятьне дә төп мосхафка кертмәгән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күзәтүе астында яздырылган Коръән аятьләре сәхабәләрдә сакланган. Зәйд бине Сабит радыяллаһу ганһе бер күчермә ясар өчен аларның барысын да бергә җыйган. Шулай ук, кемдә күпме яздырылган аятьләр бар, аларны Зәйдкә китерергә, дип халык алдында игълан ясалган. Язылган аятьләрне аңа

китергәч, иң элек ул аларны хәтерендә булганнар белән чагыштырган. Шуннан соң үзе дә хафиз булган Гомәр радыяллаһу ганһе (бу эштә Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе аларның икесенә дә катнашырга кушкан) үзенең хәтерендә булганнар белән чагыштырган. Ике ышанычлы шаһит билгеле бер аятьнең Пәйгамбәребез галәйһиссәлам катнашында язылганлыгын расламыйча бернинди язма аять тә кабул ителмәгән.

Соңыннан, язма аятьләр төрле сәхабәләрнең үзләре өчен ясалган тупланмалар белән чагыштырылган.

Зәйд бине Сабит радыяллаһу ганһе бары тик саклык өчен генә өченче ысул белән дә раслауны көткән. Коръән аятьләре Зәйд бине Сабит радыяллаһу ганһе тарафыннан тәкъдим ителгән ысуллар белән тикшерелгәннәр һәм күп кенә сәхабәләрнең язмаларында табылганнар.

Коръән аятьләрен Зәйд бине Сабит радыяллаһу ганһе җентекләп, мөмкин булган барлык ысулларны да берьюлы кулланып җыйган һәм аларны кәгазь битләренә билгеле бер тәртиптә урнаштырып барган. Әмма һәрбер сүрә аерым язылып барган. Шул рәвешле, әлеге мосхаф аерым сәхифәләрдән торган, ә Коръән гыйлеме терминологиясендә исә әлеге мосхаф Өмме (сүзгә-сүз тәрҗемәсе «ана», ягъни «төп асыл нөсхә» мәгънәсендә) дип аталган.

Бу төп мосхафта Коръән аятьләре Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам күрсәткән тәртип буенча урнаштырылган. Ләкин сүрәләр үзләре тәртип буенча булмаганлыктан, һәрбер сүрә аерым төзелгән һәм аерым сакланган. Шулай ук, әлеге мосхафка Коръәннең җиде төр укылышы да кертелгән.

Бу мосхаф хира (куфә) язуы белән дә язылган. Әлеге мосхафка Коръәнне укулары кире кагылмаган кешеләрнең генә аятьләре кертелгән. Бу хезмәтнең төп максаты – өммәтнең бердәм тырышлыгы ярдәмендә билгеле бер тәртипкә салынган мосхаф әзерләү.

Аерым сүрәләрдән торган һәм Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең әмере буенча язма рәвештә теркәлгән бу мосхаф үзе вафат булганчы анда сакла-

на. Аннан соң – Гомәр радыяллаһу ганһедә. Ул шәһит булып киткәннән соң, әлеге мосхаф саклау өчен мөэминнәрнең анасы Хафса радыяллаһу ганһәгә тапшырыла.

Хафса радыяллаһу ганһәнең вафатыннан соң, Мәрван бине Әл-Хәким (Аллаһы аннан разый булсын) аларны ягарга боера, чөнки бу вакытка инде Госман радыяллаһу ганһенең мосхафлары әзер була. Мосхафлардагы язу (шрифт) һәм сүрәләрнең тәртибе дә Госман мосхафларына яраклаштырылырга тиеш дип килешенгән була. Мәрван бине Әл-Хәким (Аллаһы аннан разый булсын) әлеге шрифтка һәм тәртипкә туры килмәгән теләсә кайсы күчермәне калдыруны кирәк түгел дип санаган.

*Islam-today*

# Тарих

# Габденнасыйр Курсави

**(1774/76–1812)**

XIX гасырның икенче яртысыннан Идел–Урал мөселманнары тарихында яңа бер дәвер башлана. Бу дәверне галимнәр «Яңарыш чоры» дип атыйлар. Җәдитчелек хәрәкәте аның иң югары ноктасы булып санала. Бу чордагы тирән үзгәрешләр җәмгыятьнең барлык якларына кагыла, бигрәк тә кешенең рухи хәятенә, дөньяга карашының төп нигезен тәшкил иткән дин өлкәсенә үтеп керә. Әлбәттә, бу күренеш кинәт кенә, бер сәбәпсез барлыкка килә алмый. Аның тамырлары тирәнгә китә. Яңарышка «фатиха» бирүче, аңа нигез салучы дип Габденнасыйр Курсави (Әбү Насыйр Габденнасыйр бине Ибраһим Әл-Курсави ) санала. Туган авылы бер чыганакларда – Макса башы, икенчеләрендә – Курса. Туган елы да төгәл билгеле түгел – 1774, 1776 ...

## Кем була соң ул Курсави?

Галимнәр әле дә бу хакта уртак фикергә килә алмыйлар. Совет чорында ул татарларда дини ислахчылыкка нигез салучы, рационалистик фикерләүне яклаучы буларак искә алына. Чит ил галимнәре Хәмид Әлгар, Михаэль Кемпер Курсавины традицион ислам гыйлеме вәкиле, шул өлкәдә формалашкан һәм иҗат иткән мөфәккир дип саныйлар. Иң тулы мәгълүматны туплаган чыганаклар Шиһабетдин Мәрҗани һәм Риза Фәхреддин әсәрләре – Курсави иҗатына карашларның үз чорыннан башлап каршылыклы булуын ачык күрсәтә. «Мөстәфадел-әхбар»ны ачсак, кайбер чордашларының сүзенә караганда, Курсави «бик зур галим булмаса да, сәламәт табигатьле, дөрес фикерле, алдан күрүчән, әкрен генә, сеңдереп кенә сөйли торган, батыр йөрәкле, замандашлары арасында тиңдәшсез булган». Ә менә Мәрҗани үзе: «Ул чын мәгьнәсендә гыйлем һәм мәгърифәт иясе, ә нотыгы матур һәм нык ышанычлы иде. Каты

холыклы, әче телле булганлыктан, гасырда галим исемен йөрткән бик күпләрнең хәтерен калдырып, аларны үзенең дә һәм фикеренең дә дошманына әйләндерде.

...Әгәр ул ашыкмыйча, мөлаемрак итеп, акыллырак рәвештә, сүзләрен йомшак, матур итеп өйрәтү юлын тота алган булса иде, күпләр, хакыйкый хәлнең һәм мәсьәләнең асылына ирешеп, аның йөзендә үзләренә җитәкче табып, ялгышу һәм имансызлыктан азат була алган булырлар иде»,— дип язды. Сәйфетдин бине Әбүбәкер Әс-Сабави исә: «Һай, шул нәрсәне[1] Бохарада асып куймадылар ләбаса!» – ди. Габделхәбир бине Габделваһһаб Әл-Мөслими: «Курсави үзенең зирәклек куәте белән мәгърифәт хәзинәсенең тылсымлы йозагын ачты һәм, андагы гыйлемнәрне аңлатып биреп, халык алдына кыйммәтле җәүһәрләр чәчте, моңа кадәр буй җитмәстәй тоелган чәчәкләрне һич кызганмыйча халкына таратты», – дип әйтте. Бохара галимнәре дә төрле караш-та. Казый Рәхмәтулла бине Габдерәхим: «Әбү Насыйр, Аллаһы Тәгалә хәзрәтеннән тәүфыйк ихсан ителгән бер бәндәсе иде, ләкин нә чара, аның сүзен аңларлык куәт безнең галимнәрдә булмады», – дип әйтте. Әбү Габделмөэмин Фазыл бине Гашур Әл-Гыйждувани: «Гыйлем бабында Әбү Насыйрга каршы торырлык һичкем юк иде, ләкин җәнабе Аллаһы аны яшьлегендә вафат итте», – дип әйтте.

## Курсавиның тормыш юлы

Курсавиның тормыш юлына ачыклык кертү өчен ул яшәгән чорда Россия һәм Урта Азиядә урын алган тарихи вакыйгаларны күзаллау мөһим. Чуалган тарих сукмакларының очын эзләгәндә, борынгы заманнарны да искә алырга кирәк. Элек-электән Идел–Урал буйларында һәм Урта Азиядә яшәүче халыклар тыгыз бәйләнештә гомер сөргәннәр. Борынгы чорда Харәзем, Мавәраәннәһердән сәүдәгәрләр һәм суфи

[1] Язуны

дәрвишләр аша Болгар җиренә Ислам дине үтеп керә. Сәүдә, икътисади, сәяси бәйләнешләрдән тыш, халыкларны аеруча уртак рухи, әдәби мирас якынайта. Гасырлар буе үсеп-ныгып барган туганлык хисе Казан ханлыгы җимерелү белән яңа төсмер ала. Ислам динен кысрыклау сәясәтен алга сөргән Россия хөкүмәте кул астында яшәүче халыкка, төп мәгърифәт учаклары булган мәчет-мәдрәсәләре кырып бетерелгәннән соң, үз ватанында белем алу мөмкинлеге калмый. Шул сәбәпле, мөселман кешесенең иң мөһим вазифаларыннан берсе булган белем эстәү өчен бердәнбер чара – чит төбәкләргә, ислам дәүләтләренә барып уку кала. Шималь төркиләрнең карашы изге Бохара җиренә юнәлә. XVIII йөзнең икенче яртысында укучылар саны аеруча артып китә. Бу күренеш Россия хөкүмәте үткәргән сәясәт белән тыгыз бәйле. Күптәннән Кытай – Һиндстанга туры юл ачарга өмет иткән Россия Кече җүз казакъларының ханы Әбелхәер белән килешү (1730) нәтиҗәсендә үз максатына ирешә башлый. 1734 елда Оренбург аша Урта Азиягә туры кәрван юлы ачыла. Ләкин рус сәүдәгәрләре тел һәм дин аермалары булу сәбәпле, шактый кыенлыкларга очрыйлар. Рус хакимияте бу очракта татарларга мөрәҗәгать итәргә һәм татар сәүдәгәрләренә зур мөмкинлекләр тудырырга мәҗбүр була. Татар сәүдәгәрләре, тиз арада ныгып китеп, сәүдә өлкәсендә зур уңышларга ирешәләр. Татар кәрваннары Кытай–Һиндстан якларына йөри башлый. Сәүдәнең җанлануы Урта Азия белән башка мөнәсәбәтләрне дә җайга салырга мөмкинлек тудыра. Екатерина II идарә иткән вакытта Идел–Урал халкы тормышында яңа чор башлана, ул мөселманнарга карата рус хакимияте сәясәтенең уңай якка үзгәрүе белән бәйле. Ислам дине «куылган» диннән «рөхсәт ителгән» дингә әверелә, дистәләрчә авылларда мәчетләр ачыла, мәдрәсәләр салына башлый. Бу шартларда имам-хатыйб, мөдәррисләр кирәклеге аеруча сизелә. Бохарага барып, белем алырга теләүчеләрнең саны тагын да арта. Кагыйдә буларак, Урта Азиядә укучы шәкертләр, мәдрәсәдә белем алудан тыш, суфичылык тәгълиматын да үзләштерә килгәннәр. Исламны бары тик тыш-

кы гыйбадәт формалары белән чикләми, «йөрәк дине» буларак аңлаткан суфичылык кешедә югары әхлакый нормалар, рухи камиллеккә омтылыш тәрбияли. Ләкин шуны да истә тотарга кирәк: вакытлар узу белән суфичылыкта тискәре күренешләр сизелә башлый – төрле «бәрәкәт» ияләре, «әүлия» каберләрен саклаучылар, «могҗиза» сатучылар барлыкка килә. Төрки халыклар арасында XV гасырдан алып Нәкышбәнди тарикате киң таралган була, соңга таба аның бер ботагы – Нәкышбәндия-Мөҗәддидия аеруча шөһрәт казана. XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башында Бохара һәм Кабулда яшәгән ике мәшһүр шәех – Ниязколый Төркмәни һәм Фәезхан Кабули шул тарикать вәкилләре буларак, Идел–Урал якларыннан килгән шәкертләргә суфичылык серләрен ачалар. Ниязколый Төркмәни – үз заманында бидгать һәм мәҗүсилек белән бозылмаган пакь ислам тарафдары һәм шәригать кагыйдәләрен саклаучы буларак билгеле шәхес.

Шундый каршылыклы заманда дөньяга килгән Габденнасыйр Курсави башлангыч белемне Мәчкәрә мәдрәсәсендә ала. Остазы Мөхәммәдрәхим Ашыти-Мәчкәрәви, аның гадәттән тыш зирәклеген күреп: «Бу балада рөшд[1] галәмәтләре күрелер, Аллаһы Тәгалә гомер бирсә фазыйләт сахибе булса кирәк», – дип әйтә торган булган. Атасының вафатыннан соң, 1770 елларда сәүдә белән шөгыльләнүче абыйсы Габделхаликъ еш кына Бохара якларына бара. Бохарада ул танылган шәех Төрекмәни хакында ишетеп, аның мәҗлесләренә йөри башлый. Ихтимал, абыйсының карашлары яшь Габденнасыйрга да тәэсир иткәндер. Мәчкәрә мәдрәсәсен тәмамлагач, ул Бохарага китә. Бу чорда Төркиядә, Мисырда ил хөкемдарлары, Европа илләренең фәнни-техник үсешен күреп, киләчәктә мөстәкыйльлекне тулысынча югалтмау өчен бу өлкәдә тирән үзгәрешләр үткәрү зарурлыгын аңлап, армия, мәгариф системасына үзгәрешләр кертә башлыйлар. Мондый яңалык җилләре Урта Азиянең Хива, Коканд, Бохара ханлыкларын әлегә читләтеп уза. Мәгърифәт учагы саналган Бохара мәдрәсәләрендә уку

[1] Рөшд – дөрес юлда булу.

программасы 400 ел үзгәртелмәгән була. Курсави килү белән мәдрәсәдә гыйлем тәхсиленә керешә, аеруча кәлям фәненә игътибар бирә һәм табигый сәләте, хәтере һәм тырышлыгы ярдәмендә тиз арада остазларын да, танылган Бохара галимнәрен дә куып җитеп, артта калдыра. Ләкин Бохара мәдрәсәләренең чәчәк аткан чоры күптән үткән була инде. Бөтен уку тәртибе урта гасыр әсәрләренең күп санлы шәрех-хәшияләрен ятлау, мәгънәсез бәхәсләшү, буш мәсьәләләр өчен сүз көрәштерүгә кайтып кала. Сабакташларының күпчелеге бары тик имам-хатыйб, мулла, казый вазифаларын башкарырга җитәрлек мәгълүмат алырга тырыша, арада чын ислам гыйлемен эзләүчеләр бик сирәк очрый. Мәдрәсәдә хөкем сөргән схоластика Курсавиның үткен зиһенен канәгатьләндерми, төп дини мәсьәләләрдә күпчелек галимнәрнең наданлыгы һәм караңгылыгы, биредә чын белем, җанлы фикернең булмавы анда ризасызлык уята. Күп санлы шәрех-хәшияләр ятлау, гомумән, мәдрәсәдә рәсми укытуның нәтиҗәсезлегенә инанган Курсави, үзлегеннән борынгы заман мөфәккирләренең – танылган тәфсир, хәдис җыентыклары төзүчеләрнең әсәрләрен өйрәнә башлый. Әбү Хәнифә, Мәлик бине Әнәс, Әш-Шәфигый, Суфьян Әс-Сәури, Мөхәммәд Әш-Шәйбани кебекләрнең китапларында Курсави үз күңеленә ятышлы фикерләр, кәлямны тәнкыйтьләү, исламның башлангыч чоры – «гасре сәгадәт»нең тормыш һәм иман тәртипләренә юнәлеш тотуга өндәү таба.

Рухи эзләнүләр аны шәех Төрекмәни янына китерә һәм Габденнасыйр аның җитәкчелегендә тәсаввуф дөньясына адым ясый. Шәех тирәсендә шулай ук мәдрәсә тәкъдим иткән уку белән чикләнмичә, хакыйкый гыйлем эзләгән яшьләр җыела. Шул даирәдә ул үз фикердәшләрен, соңыннан иң якын дусларын, «Курсави мәсләгенә» иярүчеләрне (Нигъмәтулла Әстәрли, Фазыл Кизләви, Бәшир Казани һ. б.) таба. Курсави, үз ватанына кайтып, Курса авылында мәдрәсә салдыра, имам-хатыйб, мөдәррис булып шәкертләр укыта башлый, әсәрләре өстендә эшли. Ләкин озакламый, 1808

елда яңадан Бохарага китә. «Әл-иршад лиль-ибәд» – Курсавиның иң танылган, аңа шөһрәт китергән хезмәте. Әсәрнең эчтәлеген «Усул әл-фикһ» (фикһның асыллары) фәненә хас проблематика тәшкил итә. Әсәрдә дини мәсьәләләргә мөрәҗәгать иткән авторның иҗтимагый, әхлакый карашлары да чагылыш тапкан. «Әл-иршад» хәдис, иҗтиһад, тәкълид, бидгать һ. б. темаларга багышланган аерым фасылларга бүленә.

Әсәрнең язылу сәбәпләрен Курсави замандашлары арасында «үзләрен гыйлемгә нисбәт итүчеләр»нең булуы һәм аларның «хикәятләре һәм тудырган бозыклыклары» таралу белән аңлата. Рисаләсенең максатын «гыйлем ияләре киеменә төренеп тә һаман наданлык ишекләренә ябышып ятучы кешеләрне» фаш итүдә күрә һәм аларның «сүзләренең бозыклыгын ачып бирүне һәм сөйләгән мәкаләләрен кире кага баруны халык өчен файдалырак, нәтиҗәсе мактаулырак булыр» дип өметләнә. Аның фикеренчә, гыйлемгә карата ялкаулык һәм ваемсызлыктан галимнәр арасында таралган наданлык бидгатькә – башлангыч ислам нормаларын бозган яңалыкларга, шул исәптән, ислам дөньясының таркалуына юл ача; дөрес хәдисләрне ялганнарыннан аера белмәү сәбәпле, Пәйгамбәребез сүзләрен кешеләр тәмам оныттылар, арадашчыларның аңлатуларына ышанып, алар хакыйкый дин чыганакларыннан, ислам принципларыннан һәм аларның берсе булган иҗтиһадтан читкә киттеләр. Иҗтиһад мәсьәләсе әсәрдә төп урынны ала, шуңа күрә аңа аерым тукталырга кирәк. «Иҗтиһад» термины тамыры белән «җиһад» сүзенә тоташа. Ләкин, әгәр дә «җиһад» тышкы дошман (Пәйгамбәребез сүзе буенча «Кечкенә җиһад») яки эчке камилсезлеккә каршы («Олы җиһад») көрәштә ихтыяр көчен куеп тырышу булса, «иҗтиһад» – ниндидер бер мәсьәләне хәл итү өчен акыл көчен куеп тырышу була. Бу төшенчәнең барлыкка килүе мөселман хокукы – фикһ тарихына бәйле.

Мәгълүм булганча, фикһ мөстәкыйль фән буларак хәдисләр җыелу белән бергә VII—X гасырда формалаша. Баштан ук фикһның төп нигезләре

буларак Коръән һәм Сөннәт (хәдисләр җыентыгы) кабул ителә, соңрак аларга иҗмаг, ягъни Пәйгамбәребез сәхабәләренең яисә башка ышанычлы затларның уртак бер фикере кушыла. Вакыт узу белән тормышта очрый торган һәрбер яңа сорауга Коръән һәм Сөннәттә туры җавап, яисә иҗмаг фикере булмавы ачыклана бара. Бу очракта фәкыйһләр Коръән һәм Сөннәт күрсәтмәләреннән чыгару юлы белән яңа алымнар куллана башлыйлар, төп алым итеп «кыяс» – аналогия, чагыштыру нәтиҗәсендә хөкем чыгару сайлана. Болар барысы бергә иҗтиһадның асылын, димәк, фикһ мәсьәләләре буенча хөкем чыгару хокукын тәшкил итә. Мондый хокукка ия галимнәр – мөҗтәһидләр гарәп телен камил, Коръән һәм Сөннәтне яттан белергә, аларның тәфсирләрен, кыскача бөтен дини тәгълиматны үзләштерергә тиеш булалар. IX гасырның икенче яртысыннан алып, фикһта бары тик XIX гасырның олы фәкыйһләре генә иҗтиһад хокукына ия була һәм фикһның төп мәсьәләләре инде хәл ителгән дигән фикер әкренләп тамыр җәя башлый, һәм тора-бара иҗтиһад заманы бетә, «иҗтиһад мөнкарыйз» гыйбарәсе какшамас булып урнаша. Шулай булса да иҗтиһад мәсьәләсе мөселман галимнәрен гасырлар буе борчый килә. Шул исәптән, Курсавиның кызыксынып бу мәсьәләгә мөрәҗәгать итүе бер дә очраклы түгел. Кайберәүләр инде «мөҗтәһид заманнары бик күптән бирле узып киткән, мөкаллиднең дәлиле фәкать мөҗтәһиднең сүзе генә булыр, бу заманнарыбызда кәлям һәм фикһ китаплары безне Коръән мәгънәләреннән бушатты, аларга ихтыяҗыбызны калдырмады», – дип уйлыйлар. «Мондый сүзләр кешеләр арасында наданлык чәчте, бозык сүзләргә ышану гыйлем әһелләре арасында таралды»,— дип яза ул. Җәмгыятьне төзәтү юлын Курсави бидгатьне бетерүдә, диннең пакь асылларына – Коръән һәм Сөннәткә кайтуда һәм иҗтиһад хокукын торгызуда күрә. Һәрхәлдә, мөҗтәһид хатасы өчен гаепләнми, чөнки хакыйкатьне эзләүдә куелган көч, дөрес булмаган хөкемгә китерсә дә, аны аклый.

Пәйгамбәребезнең «Әгәр дә мөҗтәһид тырышып, дөреслеккә ирешсә – аңа ике әҗер, хаталанса бер әҗер булыр», – дигән сүзләре моңа ачык дәлил. Мөҗтәһид, Курсави фикеренчә, ихлас иманнан тыш, зирәк акыл һәм көчле холыкка ия булырга, һичшиксез, Коръән һәм Сөннәтне, хәдисләрнең текстын тапшыручылар чылбыры (иснәд) белән бергә белергә, гарәп телен камил үзләштерергә тиеш. Ләкин бу очракта чыганакларны тулысынча белү күздә тотылмый, бары тик хөкем чыгаруга бәйле күрсәтмәләрне белү зарури, аларны ятларга да кирәк түгел – Коръән һәм «Сахих» кебек ышанычлы хәдис җыентыклары мөҗтәһид янында булса җитә. Шулай ук иҗмаг карашы хакында хәбәрдар булу тиешле. Мөҗтәһид фәтвасы Коръән, Сөннәт һәм иҗмаг фикеренә каршы килергә тиеш түгел һәм, ниһаять, мөҗтәһидкә кыяс алымнарын өйрәнеп, аларны куллану шартларын белү зарури. Бу таләпләргә җавап бирә алган кеше мөҗтәһид булып, аңа дәлилләрен тикшермичә һичкемгә иярергә рөхсәт ителми.

Тәкълидне бары тик ахыр чиктә – һичбер дәлил таба алмаса гына файдаланырга мөмкин. Мәсьәләнең болай хәл ителүе мөстәкыйль рәвештә фикер йөртүче һәм изге китапларга турыдан-туры мөрәҗәгать итеп, аңлатма бирү хокукына ия булган кешеләр даирәсен шактый киңәйтә – гамәлдә һәрбер югары гыйлем алган мөселман кешесе мөҗтәһид була ала. Шулай да иҗтиһад хокукы теләсә кайсы кешегә бирелә дигән сүз түгел. Курсави фикер йөртү сәләтенә карап җәмгыятьне гаммә (төркем) һәм хассага (элитага) бүлеп карый. «Гади кеше мөфти фәтвасына иярергә тиеш»,— ди ул.

«Мөгамәләт» өлкәсендә, ягъни кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләренә кагылышлы өлкәдә иҗтиһад хокукын, кешенең үз фикере булуы мөмкинлеген яклау – чынлыкта дөньяны аңлауда акыл куәтен, заман таләпләренә туры китереп тормышны үзгәртү хокукын раслау иде. Коръән һәм Сөннәтгә катгый ияруне таләп иткән Курсави, алардагы дингә кагылышлы кагыйдәләрнең камиллегенә һәм даимилегенә, һичбер үзгәрешкә

мохтаҗ булмаганлыгына басым ясый, иҗтиһад бары тик хокукый нормаларда кулланылырга тиешле, ди ул. Иҗтиһад кулланылган сфераны чикләү ул шулай ук схоластика, Аллаһының Заты, сыйфатлары, фәрештәләр, кабер газабы һ. б. акыл җитмәслек әйберләр хакында мәгънәсез бәхәсләшү белән шөгыльләнә торган кәлям вәкилләренә каршы чыгу иде. Курсави аларны Коръәнгә каршы килүдә, тәшбиһ (антропоморфизм) – Аллаһыга кеше сыйфатларын бирүдә гаепли. Кеше акылы илаһи серләрне төшенә алмый, шунлыктан дин асылларында иҗтиһад куллану, ягъни тәүһид – Аллаһының берлеге, аның гаделлеге, нубуввәт – пәйгамбәрлек, Кыямәт көне кебек мәсьәләләрдә үз фикеренә таянып хөкем чыгару – имансызлыкка тиң олы гөнаһ, ди ул. Шулай итеп, иҗтиһадны бары тик социаль-хокукый сферада калдырып, Курсави басымны иҗтимагый мәсьәләләргә күчерә, мөселман кешесен тормышта эшчән, актив булырга өнди. Курсави суфичылыкның тупас якларын (күрсәтмә тышкы тәкъвалык, читтән тыш заһидлек һ. б.) тәнкыйтьли. Аның өчен иң мөһиме – бу тәгълиматның әхлакый принциплары. Җәмгыятьтәге җитешсезлекләрдән һәм наданлыктан котылу чарасын ул кешенең әхлакый һәм гыйльми яктан камилләшүендә күрә. Имам Газали тарафдары буларак, Курсави суфичылык рухы белән тышкы шәригать кагыйдәләрен җанландырырга, акыл һәм йөрәк, гыйлем һәм иманны берләштерергә омтыла. Мондый идеалны ул «гасре сәгадәт»тә яшәгән сәхабәләр, Заһидләр, Хәсән Әл-Басри, Әбү Талиб Әл-Мәкки кебек борынгыларның карашларында таба. Бидгать – яңалык, Курсави фикеренчә, ике төрле: яман гына түгел, яхшы да булырга мөмкин— «Әгәр шәригать ысулларының берсеннән чыгарылган булса, ул яхшы бидгать – мәктәпләр салдыру, китаплар язып тарату кебек, чөнки бу эшләр мәгърифәт чәчү – шәригатьне өзелүдән саклап калу теләкләре белән эшләнә торган булса диннең асылларының асылы булырлар». Башка төрле, шәригатькә каршы килә торган бидгатьләрне Курсави ачы тәнкыйтьли. Аеруча ул якты җәйге төннәрне ястү намазын уку хакында

барган бәхәсләргә туктала, аның өчен бу мәсьәләдә шикләнүгә урын юк – төнге намаз, табигый шартлар үтәлмәсә дә, фарыз булып кала, моңа каршы килүчеләр – бидгатьчеләр. Бохара әмире һәм голямасының «зат һәм сыйфат» мәсьәләсендә Нәсафи һәм Тафтазани кебек какшамас авторитетлар кәлямен тәнкыйть итүе Курсавиның ачуын чыгара. Нәтиҗәдә җаһиллектә гаепләнгән «гыйлем әһелләре» Курсавидан үч алырга телиләр, аны хөкемгә тарталар. «Болгар дәүләтенең изге фәкыйһләренә билгеле булсын: Габденнасыйр исемле шәхес тарих 1223 (1808) елда хәерле сәфәр аенда мактаулы Бохара дәүләтенең падишаһ сараена китерелеп, әмир хәзрәтләре, дин галимнәре һәм иминлек саклаучылары хозурында, дәһрилектә, динне танымауда, имансызлыкта, намаз вакытында имамга иярмәгәнлектә гаепләнеп үлемгә хөкем ителде. Соңыннан үзенең фикерләреннән кире кайтып тәүбә итте. Чынлыкта, эш шулай тора. Үзенең тәкълидтән баш тартырга өндәгән акылсыз рисаләләрен юк итте. Шуннан соң югарыда телгә алынган шәхес әлеге дәүләттән качты...» – дип яза казый Турсунбакый Әл-Бохари 1810 елгы хатында. Курсавины кулга алсалар да, үтерергә куркалар. Морад Рәмзинең сүзенә караганда, шәех Ниязколый Төрекмәни, Габденнасыйр азат ителмәсә, әмиргә каршы халыкны күтәртү белән куркытып, мөритен яклап чыга. Курсави Бохарадан качарга мәҗбүр була. Хива, Хаҗитархан аркылы туган иленә кайта. Мәдрәсәдә Курсави үз программасы буенча укытуны дәвам итә, аның җитәкчелегендә мәсләгенә тугры булган шәкертләр тәрбияләнә. Ал арның берсе, Әхмәд бине Сәгыйд Әш-Ширдани, остазы хакында сокланып: «Гыйлемдә булган мәртәбәсе шул дәрәҗәдә иде ки, һәр фән вә һәр бабын дәлилләрен һичкемнең иганәтеннән башка вә һич китапка мөрәҗәгать итмәй күңелдән бәян итәргә моктәдир иде»,— дип яза. Шул ук вакытта, «дәһри» һәм «кяфер» буларак даны чыккан Курсавиның эшчәнлеге, Бохара тарафдары булган руханиларның күпчелегендә тискәре мөнәсәбәт уята.

Шәмсетдин Җәбәли, Таҗетдин Иштирәки Курсавига каршы рисаләләр язып, аның фикерләрен инкяр итәргә тырышалар, ахун Фәтхулла Орыви Мөхәммәдҗан мөфтигә Курсави өстеннән донос җибәрә. 1812 елның язында, хаҗга бару нияте белән, Курсави бер туганы белән сәфәргә чыга. Ләкин изге җиргә барып җитү аңа насыйп булмый, ул Истанбулда Рамазан аеның соңгы көннәрендә (сентябрь аена туры килә) ваба (холера) авыруыннан вафат була һәм Үскүдар зиратында җирләнә. Курсавиның рухи варисы – Шиһабетдин Мәрҗани, 1880 елда Истанбулда булып, аның кабер ташын күреп кайта. Соңыннан, гасыр узгач, Риза Фәхреддин: «Аның кеби камил затны бу заман күзе биш йөз елдан бирле күрмәмеш иде»,— дип, Курсави эшчәнлегенә югары бәя бирә. Мәрҗанинең карашлары турыдан-туры Курсави әсәрләре йогынтысында формалаша, аның хезмәтләрендә Курсави фикерләре дәвамын таба. Мәрҗани, үз чиратында, Риза Фәхреддиневнең галим буларак үсешенә тәэсир итә. Инде XX йөз башында Курсави фикерләре Муса Бигиев, Зыя Камали әсәрләрендә яңа чагылыш таба. Курсавига хас хакыйкатькә омтылу, мөстәкыйль фикерне яклау – җәдитчелек хәрәкәтенең нигезенә салына.

*«Татар зыялылары: тарихи портретлар» җыентыгыннан.*

*Төзүчесе – Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин. «Мәгариф»нәшрияты, 2003.*

# «Зәңгәр» мәчет һәм «Халидия» мәдрәсәсе

«Зәңгәр» мәчетнең (яки 4 нче мәчет) мәхәлләсе XVIII гасырның соңгы чирегендә оешкан. Ул чорларда, Ш. Мәрҗани мәгълүматларыннан күренгәнчә, Казанның дүртенче (агач) мәчете төзелгән.

1815–1819 елларда әлеге мәчет Суыксу авылына күчерелгән, аның урынында Казан сәүдәгәре Әхмәт Исхаков (хәзерге вакытта сакланган) кирпеч мәчет төзеткән. 1864 елда сәүдәгәр Габделмәннан Биккенә улы Мөстакыймов үз җире исәбенә мәчетне (фасад буенча өч тәрәзә киңлегендә) киңәйткән, гыйбадәтханә тирәли кирпеч дивар салдырган (архитекторы П. И. Романов). Беренче гильдия сәүдәгәре, җир биләүче һәм промышленник Габдрахман Әхмәт улы Ишморатов 1907 елда мәчетнең михрабын һәм саклау корылмасын зурайттырган.

«Зәңгәр мәчет»тә озак еллар дәвамында ике нәсел вәкилләре имам вазифаларын башкарган.

Беренче имамнардан Габденнасыйр Рахманколов (1835 елда вафат) исеме мәгълүм. Ул Казан губернасы Тәтеш өязендә (Кама Тамагы районына карый) туган, Оренбург янындагы Каргалы авылы мәдрәсәсендә укыган; 1825 елда Казанга килеп, 4 нче мәчетнең имам-хатыйбы һәм мөдәррисе булып билгеләнгән. Габденнасыйр хәзрәт беренче тапкыр мәдрәсә оештырган. Сәүдәгәрләр Йосыф һәм Корбангали Арсаевлар әлеге уку йорты өчен бина төзеткәннәр. 1825 елда (Г. Рахманколовның вафатыннан соң) имам вазифалары аның туганы Хәбибулла Рахманколовка (1780–1850) күчкән. Аны Тәтеш өязенең Яңасала авылы (Татарстанның Кама Тамагы районына керә) кешесе Хәммәт Халитов алыштырган. Соңгысының төпчек улы Фатих Халиди (1850–1923) – күренекле мәгърифәтче, беренче татар драматургларының берсе. Х. Халитов 1864 елда вафат булган һәм аның урыныда Рахманколовлардан соңгы имам Гыязетдин Хәбибулла

улы Рахманколов расланган. Гыязетдин – Ш. Мәрҗанинең иң яраткан укучыларының берсе булган. Күренекле галим үз шәкертенең сәләте һәм кешелек сыйфатлары хакында югары фикердә булган. Ул «Зәңгәр мәчет»тә алты ел дәвамында имам булып торган, 1897 елда вафат булган. 4 нче мәчетнең имам-хатыйбы вазифаларын 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр Хәммәт Халитов оныклары башкарган. 1870 елда әлеге урынга Мөхәммәтзакир Хәммәт улы Халитов (1893 елда вафат), 1894 елда аның улы Ибраһим Халитов (туган елы – 1869) билгеләнгән. Мәхәллә зур булган. XX гасыр башында анда 89 хуҗалыкта яшәгән 780 ир-ат исәпләнгән.

Мәдрәсә 1825 елда оешкан. Аны төрлечә (Арсаев, Айтуганов, Мөстәкыймов, «Халидия» мәдрәсәсе) атаганнар. Шулай да күпләр аны «Халидия» дип атаган, XX гасыр башында анда 155 шәкерт укыган. XIX гасыр ахырыннан 1917 елга кадәр мәдрәсә Мөстәкыймов йортында (Екатеринская һәм Икенче Аркылы урамнары чаты) урнашкан. Уку-укыту иске алымнар буенча башкарылган (бинаның хәзерге урыны – Тукай ур., 68/16).

XIX гасырның 90 нчы еллар башында «Халидия» мәдрәсәсендә драматург Г. Г. Камал, 1895–1904 елларда тарихчы-галим Г. С. Гобәйдуллин һәм шагыйрь Г. Сөнгати укыган.

*«Татарстан Җөмһүрияте: татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре» китабыннан, «Фест» нәшрияты, 1995 ел*

# Мирас

# Тәрбияле ата

## Бисмилләһир-рахмәнир-рахим

Тәрбияле ата булмак өчен әүвәл өйләнгәнче изге нияттә булмак тиешледер. Мәсәлән: өйләнмәк булса, Аллаһы Тәгаләнең бер бәндәсен үзенә хәләл кылып, аны тәрбия кылмак һәм аннан килгән балаларны тәрбия кылып укытып, кәсеб вә һөнәр өйрәтеп, угыл булса, хәләллек берлә өйләндереп, кыз булса, хәләл урынга тәрбия кылып кияүгә бирмәк ниятендә булмак тиешледер.


تربیه‌لی آتا
اثر
ا. ا.
ابراهیم ادریسف نك خراجتی ایلان
قزانده چیرکوف ورثه‌لرینڭ مطبعه‌سنده طبع ایدلدی
منتصف رمضان سنه ۱۳۱۸
Казань.
Типо-Литографія насл. М. Чирковой
1900

Бәлки моның хилафынча бай җирдән алып, аның аркасында рәхәт киченермен диеп, акчалы кыз яки акчалы хатын булса да алып, акчасын җайлап, булмаса көчләп алу ниятендә булып, Ходага тәвәккәлсезлек кылу, тәрбияле ата исемен күтәрәчәк булган егетләргә мөнасиб эш түгелдер. Бәлки бу эш егет булган кешегә хурлыктыр, чөнки адәм баласының әгъзалары сәламәт булса, үзе акчадыр. Әгъзаларын тиешле хезмәткә куша белсә, яманлыктан сакланса, ризык шөбһәсез киләчәктер, ин шә Аллаһ.

Югарыдагы ният берлә өйләнеп, җәмәгать илә мәгыйшәт итә башлагач, әүвәл хатынына табигатенең ни рәвешле булып, кайсы эшләрне яратып, кайсы эшләрне яратмавын җәмәгатенә яхшы аңлатмага тиеш, чөнки икесенең арасында камил ислах булсын өчен.

Соңра ата вә анасына түбәнчелек илә, булмага мөмкин кадәрле аларның хезмәтен әда кылмага тиешле икәнен аңлатмага кирәк. Аларны «атаң, анаң» дип иренә нисбәт илә итүдән тыеп, халык арасында мәгъруф булганча «әткәй, әнкәй» дип дәшергә тиешледер.

Аннан соң йорт гадәтләрен, йортта булган ашау-эчү, аш хәзерләү, ризыкларны барлау кеби эшләрне тәмам кат-кат өйрәтмәгә тиешледер.

Мин ир дигәч тә, төшенеп җитмәгән ят иргә килгән бер кызны тиз генә орыша башламаска тиеш. Янә өйдән рөхсәтсез чыкмаска һәм тиешсез кешене өйгә кертмәскә әүвәл бик яхшы аңлатмага тиеш. Кемгә барырга ярый, кемнәр өйгә кереп сөйләшеп утырырга ярый, кемнәрдән тел яшермәгә тиеш, кемнәрдән йөз яшермәскә ярый, җәмгысын әүвәл аңлатмага тиеш.

Имди хатын тарафыннан аңламау сәбәплеме яки гадәтләнмәү сәбәплеме, боларның хилафы садир булса, күргәч тә орып бәрмәскә тиеш. Бәлки әүвәл мәртәбәсендә: «Чү, алай ярамый, бу эшне миңа икенче мәртәбә күрсәтмә», – дип нәсыйхәт кылмага тиеш.

Икенче мәртәбә янә беленсә, түшәгендә аркан яту шикелле, караңгы чырай күрсәтү шикелле эшләр илә тәнбиһ кылып , ярамаган гадәтләрен куйдырырга иҗтиһад кылмага тиеш. Бәгъзе борынгы бабаларыбызның әйтүләре буенча чәч толымыннан шәйтанын куалыйм дип, хатынын өстерәп кыйнамаска тиеш. Хосусән, әүвәл мәртәбә сукмаска бик тырышмак кирәк. Бер суга башласаң, кулың һаман сукмага җитешер, үзең сизми дә калырсың. Соңра уйлап карасаң, һич кирәкмәскә яки орышып үтә торган урынга үзең илә мәгыйшәт кыла торган җәмәгатеңне орып, арада булган мәхәббәтнең дәрәҗәсен киметкәнеңне уйлап үкенерсең, мәгыйшәтнең ләззәтсез үтүен, йортның бәрәкәте китүен уйласаң, Аллаһ, ни кадәр зарар иткән булырсың.

## Балаларың тәрбиясе хакында

Тәрбияле аталар балаларга сабый вакытында һәрдаим шәфәгать күзләре илә карап, аларга ашамак-эчмәк, кимәк кеби аслыя хаҗәтләрен хәләлдән хәзерләп китерерләр. «Сез миңа җәфа булдыгыз, имгәкләр», – кеби сүзләр илә шикаять юлында сүз сөйләмәсләр. Бәлки башта әйтеп үткәргән рәвешчә, болар Ходаның бәндәсе, боларның булуына сәбәпче мин булдым, тәрбиясе миңа фарыз һәм лазем дип белеп, кәсебе аркылы

Аллаһыдан килгән нигъмәтне сөенә-сөенә алып кайтып тәрбия кылырлар. Аллаһыдан әҗерен өмид итәрләр. Шул ният илә тәрбия кылсалар, әҗере, шөбһәсез, булачак, ин шә Аллаһ.

Балага азрак гакыл кереп белә башлагач, ата вә анасы бер сүздә булып, балага әдәп вә әхлакны өйрәтмәгә иҗтиһад итәрләр.

Мәсәлән: баланың бер гаебе булып, атасы орышканда, анасы аркылы төшмәс. Бәлки анасы янә нәсыйхәт бирер: «Менә, балам, икенче мәртәбә алай кылма, атаң сине тиешле урынга орышты», – дип, үз тарафыннан салкынлык күргәзер.

Тәрбияле аталар балаларына асла ялган сөйләшүне ихтыяр кылмаслар. Әүвәл балаларына әйтерләр: «Бер нәрсәне мин күрмәгәндә ватсагыз яки бер нәрсәне ашасагыз, соңра беленеп, сораганда «Мин ватмадым» яки «Мин ашамадым», дип ялган итмәгез, бәлки дөрес әйтегез, әгәр дөрес әйтсәгез, сезгә шәфкатем булыр, гаебегезне кичерермен, әгәр котылып калмакчы булып ялган итсәгез, ул ялган миңа кайчан да беленер. Ул вакыт минем сезгә җәзам бик каты булыр», – дип балаларның колакларына кат-кат әйтерләр. Имди баланың бер гаебе беленсә, әүвәл әйтер: «Балам, ялган әйтмә, ялган харам, дөрес сөйлә», – дияр. Соңра баладан сорар: «Бу эш ничек булды?» Ул вакыт бала, шаять, дөресен әйтер, дөресен әйтсә, югарыдагы вәгъдә буенча баланы кыйнамас. Бәлки балага әйтер: «Бу юлыга гаебеңне кичердем, икенче алай итмә», – диеп кисәтер. Һәм баладан: «Әти, бу юлыга гафу ит, икенче мәртәбә алай кылмам», – дип әйттереп вәгъдә алыр.

## Тәрбияле аталар балаларының өс-башларын, кул вә йөзләрен пакь йөртмәк рәвеше

Тәрбияле аталар балаларын пакь йөртмәк илә һәм кул вә аяк тырнакларын җиткән саен кисмәк илә аналарына яки хадимәләренә әмер итәрләр.

Ир бала булса, алтын, көмеш, салам эшләпә, ефәк кеби харам киемнәр кидертмәсләр, бәлки шәригать кушкан киемнәрне киендерерләр. Өй, тегермән, көймә, арба, чана кеби җансыз нәрсәләр сурәте булган уенчыкларны алып биреп, балаларны сөендерерләр.

Тәрбияле аталар балалары 10 яшенә җитсә, намазларын һәр вакытта күздән үткәреп укытмага иҗтиһад итәрләр. Сабый вакытта мәсҗедкә йөртеп, әдәпсез балалар илә мәсҗедтә уйнашып, намазны тәхфиф кылып укытып өйрәтмәсләр.

Үзе базарга кәсебенә чыкса, җәмәгатенә әйтеп чыгар: «Балалар йокыдан торгач намазларын укысыннар», – диеп, кич кайткач җәмәгатеннән сорар: «Балалар һәр намазларын укыдылармы?» – диеп. Әгәр укымаган булсалар, калган намазларын үз күзеннән карап укытырлар.

Шул рәвешчә тәрбия кылсалар, балаларга намаз укымаклык яшь вакыттан гадәт булып, намазларын калдырмый торган булырлар.

## Тәрбияле аталар балаларына сабак башлатмак вә өйрәтмәк рәвеше

Тәрбияле аталар балаларына «сабакка бар» диеп кенә бер балага ияртеп җибәрмәсләр, хәлфә кулына гына да җибәрмәсләр, бәлки мәдрәсәнең мөдәррисе булган мулласына үзе алып барыр. «Хәзрәт, сезгә бер бала китергән идем, кабул итеп үзегезгә мәслихәт булган хәлфәдән сабак өйрәттерсәгезлә, үзегез дә кай арада баланың укуына күз салуыгызны үтенәмез», – диеп кулыннан килгән кадәр садакасын бирер. «Әүвәл Аллаһыга, икенче сезгә тапшырдым», – дип, ул хәзрәтне Аллаһы Тәгаләгә шәрик кылмас. Һәм: «Баланың тиресе илә сөяге миңа, ите – сиңа», – дип уртакка асрамага биргән сарык бәтисе кеби кылмаслар. Аллаһыга тапшырдым, дип кенә сүзен тәмам итәрләр. Баласы сабакны укый башлагач, кай сәгатьтә сабакка барасы, кай сәгатьтә сабактан кайтасы вакытларын хәлфәдән сорап белешер.

Баланың кайтуына ашарга хәзерләп; башка эшкә кушмаенча, барасы сәгате җиткәч, кичектерми җибәрерләр. Һәм хәлфә баламны укыта диеп, үзе тыныч ятмас, бәлки хәлфәдән даим белешеп торыр: «Бала сабагына вакытында барамы? Сабак укыган вакытта уйнап утырмыймы? Барганда, кайтканда уйнап сугышып йөрмиме?» – барысын да тәфтиш кылыр. Һәм пәнҗешәмбе садакасын атасы биргәнчә хәлфәсенә илтеп бирәме? Яки акчасының беразына юлда прәнек яки келәвә кеби нәрсәләр ашап, хәлфәгә калганын илтеп биреп кенә йөрмиме? Шуларның барысын хәлфәдән белешер.

Тәрбияле аталар балаларының уку әсбабын тоткар итмичә алып бирерләр. Китап, кәгазь, карандаш, каләм, кара кеби нәрсәләрне тоткар итмәсләр. «Хәзер генә алып биргән идем, кая куйдың», – диеп баланы орышып, кулын бәйләгән кеби язудан һәм сабактан ихласын чыгармаслар.

Тәрбияле аталар хәлфәгә пәнҗешәмбе садакасын бик аз бирмәсләр, хәлфәләрнең балаларына никадәр хезмәтләре кергәнен белерләр. Үзләре бер кешегә көн саен бер сәгать утын ярсалар яки әвен суксалар, ничә тиен алырга риза булырлар иде? Шуннан үлчәп хәлфәләргә әҗрә бирсеннәр. Хәлфәләр Аллаһы ризасы өчен укыталар, дип белеп, пәнҗешәмбе көн 3 тиен, 5 тиен биреп, хәлфәләрнең бала укытудан булган рәгъбәтләрен сүндермәсләр. Югарыда әйтелгәнчә, көн саен бер хезмәтне үзләре кешегә Аллаһы ризасы өчен кыласылары килерме? Үзеннән хисап кылып һәм хәлфә дә үзе шикелле бер инсан, фәрештә түгел, ашамак-эчмәге, өс-башы бар дип, инсафы илә хәл иткән әкалль мәртәбә 10 тиен, йә 20 тиен бирер.

Һәм уку кәйфәятен карар, баланың кабилияте була торып, хәлфә тарафыннан укытуда косур[1] беленсә, алып икенче мәдрәсәгә бирер. Хәлфәдән баламны алсам, бала илә үзем җәһәннәмгә китәм, диеп игъ-

[1] Косур – җитешсезлек.

тикад кылмас. Бәлки баламның газиз вакыты бушка үтмәсен, дип, надан калып дөнья вә ахирәте харап булмавын исендә тотарлар.

Һәм кыз балаларны югарыда әйтелгән рәвешчә укытмага иҗтиһад кылырлар. Кыз балаларга язу кирәкмәс, язу белсә, егетләргә хат язарлар, диеп тыймаслар. Бәлки кызларының кияүгә барган соңында иренә хат язмак булганда һичкемгә әйтергә ярамый торган мәхәббәт йөзеннән килгән сүзләрен, бер ят кешегә әйтеп яздырып серне фаш кылуын лаек күрми, мөмкин кадәрле язуга өйрәтмәгә иҗтиһад кылырлар. Һәм кул эшләренә, аш пешерү гыйлемнәренә өйрәтдермәгә акчалар сарыф кылып иҗтиһад кылырлар. Кыз баланың ят кеше кулларына барып төшкән вакытында, эш белмичә гаҗизә калып , кайната-кайнана тарафыннан киленнән уңмадык дигән сүзләрне, кызы өстенә сөйләнүне исендә тотып, ир балага караганда да яхшырак әдәп бирдермәгә иҗтиһад кылырлар. Тәрбияле аталар кызын кияүгә биргәч тә тынычлап рәхәт булып тормаслар, бәлки кызының рәхәт гомер кичермәге өчен кирәкле булган хәлләрне кайгыртырлар. Мәсәлән: кызының кайнатага-кайнанага һәм иренә камил итагать кылырга; аларга каршы сүз әйтеп, аларның әмерен тотмаенча, үзе теләгәнчә эш кылып, иренең күңелен суытмаска тырышуны аңлатып үгетләрләр.

## Тәрбияле ирләрнең хатыннарын кунакка җибәрү рәвеше

Тәрбияле ирләр хатыннарын чакырган бер җиргә җибәрмәсләр. Бәлки кайсына бармый калырга ярамый, шуңар гына җибәрерләр. Һәм барганда да иң әгълә киемнәрен киеп, кершән ягынып, урамда очраган ирләрнең күзләре төшеп: «Ий бу хатын миңа булсачы», – диеп кызыгырлык хәйсиятчә барырга кушмаслар, бәлки мәзкүр киемнәрнең өстеннән гадәтчә генә җилән яки чапан бөркәнеп бармага әмер итәрләр. Әгәр ат берлән барачак булса, арба түренә ялгыз утыртып, кучер илә генә җибәрмәсләр, янына

хәдимә яки бала утыртырлар. Хатыннар үзләре кунак җыймакчы булсалар, тиешле булган хатыннарны гына чакырмага әмер итәрләр.

Аш-суны да тәкәллеф илә кылмаска кушарлар, аштан соң кемнәрне чакырдың, дип тәфтиш кылырлар. Тәрбияле ирләр, хатыннары кунак чакырган көнне, ничә хатын ничә вакыт намазны калдырып, бөтен көнне заигъ иттертмәсләр. Тиз җыелып, тиз таралмаклары берлә әмер итәрләр.

## Тәрбияле ирләрнең хатыннарына кием-салым ясау рәвеше

Тәрбияле ирләр хатыннарына үз милләтебезгә охшашлы киемнәр илә киенергә әмер итәрләр. 50 сумлык кием урынына 200 сумлык кием ябындырмаслар. Тәрбияле ирләрнең хатыннары күлмәклек сорасалар, урыны илә кия торган 5-6 пар күлмәгеннән башка сандыкта яткан 10-15 пар күлмәге булуыннан хәбәрле булыр. Бәлки үзенең кәсебеннән килгән файда ни рәвешле (алачакны хисапламыйча, бирәчәкне хисаплап), кулындагы малына чамалап, кием ясалыр.

## Тәрбияле ирләрнең үзләренә кием ясау рәвеше

Тәрбияле ирләр үзләренең кәсебе рәвешенә карап кием ясарлар, урыны илә яхшы киемнәрне киярләр. Кәсебе уртача булып, яхшы киемнәр кияргә хәле җитмәсә, барынча керсез һәм пакь итеп киярләр.

Тәрбияле ирләр кәсепләренең алга китүенә бик тырышырлар. Әмма биш вакыт намазларын һич калдырмаслар. Чәйханәләргә кереп, төрле кешеләр илә суган сатып вакыт үткәрмәсләр. Бәлки сәүдәләре сәбәпле күрергә тиешле булган кешеләр илә үзенә нәсыйхәт һәм мәслихәт бирә торган кешеләр илә генә утырышып, башка вакытларын кәсепләренең өстендә кичереп, кич кайтыр вакытта җәмәгать вә балаларын зарыгытмыйча өйләренә кайтып, әһел , әүладләренең хәтерләрен табарлар.

## Тәрбияле ирләрнең балаларына 15тән үткәч әдәп бирү рәвеше

Тәрбияле аталар балаларының бер яманлыгын күрсәләр, яшь чакта үземез дә шулайрак булган идек, диеп гафу итмәсләр. Тиешле җәзасын бирерләр һәм үзенең яшь вакытында яман хәлдә булганнарын балаларына һәм үз кардәшләренә аслан белгертмәсләр. Гүя үзе ул сыйфатта булмаган төсле булып, балаларына әдәп, гасырдашларына нәсыйхәт итәрләр.

Тәрбияле аталар үзенең яшь вакытындагы яман хәлләрен кешегә белендереп, үрнәк булуыннан куркырлар. Үзе яшь вакытындагы гадәтен ташлаган булса да, икенче кешеләрнең яшь вакытындагы гадәтләрен ташлый алмыенча гомерләрен хараплыкта үткәргәннәрен күреп, яшь уллары өчен бигрәк тә кайгыртырлар.

## Тәрбияле ирләрнең голәмәгә мөнәсәбәте

Тәрбияле ирләр үзенең мәхәлләсендә булган бер мулласын гына яратып яки баласына остаз булган бер мулланы гына сөеп, башкаларын һич ихтирам итмичә: «Кая безнең фәлән хәзрәткә җитәргә», – диеп муллаларга нумер сукмаслар. Бәлки кайсыдыр мулла мәсҗедләрдә, мәҗлесләрдә үз гасырдашларымызны вәгазь итүче булганлыктан, бәгъзесе мөселман кардәшләремезнең балаларына дин өйрәтеп хезмәт кылганлыктан, хаһ аның мәхәлләсендә булмасын, хаһ баласының остазы булмасын, җәмигъ сун сөярләр, тел озатмаслар.

## Тәрбияле ирләрнең сүз сөйләү рәвеше

Тәрбияле ирләр сүзне үлчәп, урыны илән сөйләшерләр. Мәсәлән: бер мәҗлестә үзеннән артык булучы кеше булмаса, әдәп илә генә сөйләшер. Кечекләргә нәсыйхәт кылыр. Бер эш хакында бер адәмнән бер сүз ишетсә, ышанып, бөтен кабынып китмәсләр. Ул кешедән андый эш садир булырга

охшыймы? Әүвәл шунысын бик яхшы уйларлар. Әгәр ул кешенең ул эшне эшләмәге мөмкин булса, Аллаһы инсаф бирсен, диярләр. Әгәр хак булырга охшамаса, ифтира булмагае иде дип, сөйләүчеләрне тәнбиһ итәрләр.

Күзе илә күреп, колагы илә ишетмәгән эшкә ышанмый калу гөнаһ эш түгел, бәлки саваптыр. Кыскасы, шул һәр кешедән ишетелгән сүз барсы да раст дип белеп ышанмаслар. Шәригатьтә дөрес булган эшне гадәткә хилаф булса да кабул итмәк, шәригатьтә харам булган эшне гадәттә дөрес булса да тәрк итмәк – инсаниятты. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә барчаларымызга инсаф бирсен. Әәмин.

*«Тәрбияле ата» китабы, 1900 ел.*

*Мөәллиф:* ا.ا. *(Ибраһим Идрисов)*

*Ибраһим Идрисовның хәраҗаты белән.*

# Ураза

# Рамазан аеның фазыйләтләре

1. Факыйһ үзенең иснәде белән Ибне Габбастан риваять итә. Ул Пәйгамбәр галәйһиссәламнең болай дип әйткәнен ишеткән: «Дөреслектә, Рамазан ае өчен, җәннәт ел буе зиннәтләнә һәм хәзерләнә. Әгәр Рамазан киченең башы җитсә, Гареш астында җил исәр. Ул җилне «Мәсира» дип атыйлар. Оҗмах агачларының яфраклары, ишек капкачларының боҗралары (бертөрле) чыңлый башлар. Ишетүчеләрнең ул аваздан күркәмрәк аваз ишеткәннәре булмас. Хур кызлары җәннәтнең югары урыннарына кадәр басып, карарга чыгарлар: «Безне Аллаһы Тәгаләдән яучылап сораучы бармы? Аллаһы Тәгалә ул яучыны безгә өйләндерсен иде», – диярләр. Соңыннан: «Әй, җәннәт башлыгы, бу нинди кич?» – дип әйтелер. Ризван ул хур кызларына: «Ни кушсагыз, шуны әзерләрмен», – дип җавап бирер. «Әй, күркәм изге кызлар, бу кич – Рамазан аеның беренче киче», – дип әйтелер. Аллаһы Тәгалә: «Әй, Ризван, Мөхәммәд галәйһиссәлам өммәтенең ураза тотучылары өчен җәннәтләрнең ишекләрен ач. Әй, Мәлик, Мөхәммәд галәйһиссәламнең өммәтеннән булган ураза тотучыларга тәмуг ишекләрен биклә. Әй, Җәбраил, җиргә төш, шәйтаннарның көчлеләрен чылбырлар белән бәйлә һәм аларны диңгез төбенә ташла. Ул шәйтаннар Минем дустым булган Мөхәммәд өммәтенең уразаларын бозмасыннар», – дип әйтер. Рамазан аеның һәр кичендә Аллаһы Тәгалә өч мәртәбә әйтер: «Миннән сораучы бармы? Мин аның сораганын бирермен. Әй, тәүбә итүче бармы? Мин аның тәүбәсен кабул итәрмен. Ярлыкау сораучы бармы? Мин аны ярлыкармын».

Соңыннан бер кычкыручы: «Кем бернәрсәгә дә мохтаҗ булмаганга, алганны һич киметмичә кайтаручыга әҗәткә биреп торыр иде? Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә Рамазан аеның һәр кичәсендә ифтар вакытында тәмуггтан мең һәм тагын мең колны коткарыр, аларның һәрберсенә газап вәҗиб булса да; җомга киче һәм җомга көне җиткәч,

ул җомганың һәрбер сәгатендә җәһәннәмнән мең һәм тагын мең кол азат ителер, аларның һәркайсына газап вәҗиб булса да. Рамазан аеның соңгы көне җиткәч, бу көндә айның башыннан ахырына кадәр азат кылынган кадәр кол азат ителер. Әгәр Кадер киче җитсә, Аллаһы Тәгалә Җәбраилгә фәрештәләр җәмәгате белән җиргә иңәргә боерыр. Җәбраилнең яшел әләме булыр, аны, җиргә төшкәч, Кәгъбә алдына кадап куяр. Җәбраилнең алты йөз канаты бар, ике канатын һичкайчан ачмас, мәгәр Кадер кичәсендә генә ачар. Бу өммәткә Җәбраил фәрештәләрне күндерер: алар һәрбер утыручыга, һәрбер намаз укучыга һәм һәрбер зикер әйтүчегә сәлам бирерләр. Фәрештәләр өммәт белән күрешерләр, таң атканга кадәр өммәтнең догаларына «әәмин» дип әйтерләр. Әгәр таң атса, Җәбраил галәйһиссәлам: «Әй, фәрештәләр җәмәгате, китәргә, китәргә», – дип кычкырыр. Фәрештәләр болай дип әйтерләр: «Мөхәммәд галәйһиссәлам өммәтләренең хаҗәтләре хакында Аллаһы Тәгалә ни кылды»? Җәбраил: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә мөэминнәргә карады, ягъни алардан явызлыкларны алды һәм дүрт төрле халыктан кала, барысын да ярлыкады», – дип әйтер. Фәрештәләр: «Кемнәр алар?» – дип сорарлар. Җәбраил галәйһиссәлам болай дип әйтер: «Беренчесе, даими хәмер эчүче; икенчесе, ата-анасын ачуландыручы; өченчесе, кардәшләренең хәлләрен белмәүче; дүртенчесе, көнчелек итеп, дошманлык саклаучы».

2. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Ә инде фитыр гаетенең кичәсе булса, бу «рөхсәт киче» дип аталыр. Фитыр гаете көненең иртәсе җиткәч, һәр шәһәргә фәрештәләр җибәрелер. Алар җиргә иңәрләр, йорт башларында торырлар һәм бертавыштан: «Әй, Мөхәммәд өммәтләре, юмарт булучы Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә чыгыгыз. Ул Аллаһы Тәгалә күп итеп бүләк бирер һәм олуг гөнаһларны да ярлыкар», – дип кычкырырлар. Аллаһы Тәгалә яраткан мәхлүкъларның барчасы да бу тавышны ишетерләр, мәгәр адәмнәр һәм җеннәр генә ишетмәсләр. Кешеләр гает намазын укый торган урыннарына чыккач, Аллаһы Тәгалә

Үзенең фәрештәләренә: «Әй, Минем фәрештәләрем, әгәр гамәлен кылса, хак алучының әҗере ни булыр?» – дип сорар. Фәрештәләр: «Әй, безнең Хуҗабыз, аның әҗерен Син Үзең бирүче (Шулай ук: «Аның әҗере – хакын тулысынча кайтарудадыр», – дип килә)». Аллаһы Тәгалә болай дип әйтер: «Әй, фәрештәләр, Мин сезне шаһит итәм, дөреслектә, Мин аларга Рамазан аендагы көндез ураза тотулары һәм кич уяу торулары өчен Үземнең ризалыгымны һәм гөнаһларын ярлыкауны бирәм».

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтер: «Әй, Минем бәндәләрем, Миннән сорагыз, Үземнең хөрмәтем һәм олуглыгым белән ант итәм, бу көнне дөнья һәм Ахирәт өчен ни генә сорасагыз да бирәм».

3. Әбү Һөрайрадан риваять ителә, Расүлуллаһ галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Рамазан аенда өммәтемә биш төрле хасият бирелде. Аннан элек булган өммәтләргә болар бирелмәгән иде: ураза тотучы кешенең авызыннан чыккан ис Аллаһы Тәгалә каршында яфәрдән дә хуш ислерәк; фәрештәләр (ураза тотучы) өммәт авыз ачканга кадәр алар өчен ярлыкауны сорарлар; Рамазан аенда шәйтаннарның көчләләре бәйләнеп куелыр; бу айда шәйтаннар (Рамазаннан кала) котылып була ала торган вакытка кадәр котыла алмаслар. Аллаһы Тәгалә Үзенең җәннәтен һәр көн бизәр һәм аңа болай дип әйтер: «Минем изге бәндәләремә якынай. Алардан мәшәкать һәм рәнҗеш ташланды. Алар сиңа омтылырлар, актык кичтә (Рамазанның соңгы кичендә) аларның гөнаһлары ярлыканыр». «Әй, Расүлуллаһ, ул кич, Кадер киче түгелме?» – дип соралды. Ул: «Юк, мәгәр үз эшен үтәсә, шул гамәлне кылучыларга әҗер-хакы бирелер», – дип әйтте.

4. Әбү Һөрайрадан риваять ителә, Расүлуллаһ галәйһиссәлам үзенең сәхабәләрен сөендереп: «Тәхкыйк, сезгә мөбарәк Рамазан ае килде. Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә сезнең өчен Рамазанның уразаларын фарыз итте. Рамазанда җәннәт ишекләре ачылыр һәм җәһәннәм ишекләре бикләнер. Рамазанда шәйтаннарның куәтлеләре бәйләнеп куелыр һәм

Рамазанда Кадер кичәсе бар. Ул кичә мең айдан да артыграк», – дип әйтте.

5. Хайсәмәдән риваять ителә, ул болай дип әйткән: «Әгәр зур гөнаһлардан саклансалар, бу Рамазаннан Рамазанга, хаждан хажга, җомгадан җомгага һәм намаздан намазга кадәр арада булган кечкенә гөнаһларга кәффарәт була», – дип әйтә торганнар иде».

6. Гомәр радыяллаһу ганһедән риваять ителә, ул Рамазан ае керсә: «Хуш килдең безне пакьли торган (ай). Рамазанның һәр көне изге. Көндез ураза тотулар, кич уяу торулар һәм бу Рамазанда малны сарыф итү – ул малны Аллаһы юлында тотуга тиң», – дип әйтә иде.

7. Әбү Һөрайра Пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять итә. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: «Адәм баласы уразадан башка кыла торган һәр изгелек уннан җиде йөз өлешкә кадәр. Ә ураза – ул бары тик Минем ризалыгым өчен генә һәм ул бәндәгә уразасы бәрабәренә әҗерен Мин генә бирүчемен. Ул бәндә Минем өчен ашау-эчүне һәм күңел теләкләрен ташлый. Ураза – ул уттан пәрдә. Ураза тотучының ике шатлыгы бар: берсе – авыз ачканда, икенчесе – Кыямәт көнендә Аллаһыга юлыккан вакытта».

8. Факыйһ үзенең иснәде белән Сәлман Әл-Фәрисидән риваять итә. Ул әйтте: «Шәгъбанның соңгы көнендә Расүлуллаһ безгә хөтбә сөйләде: «Әй, адәмнәр, тәхкыйк, сезне күләгәләп мөбарәк һәм олуг ай килде. Ул айда Кадер кичәсе бар һәм ул кичә мең айдан артыграк. Янә Аллаһы Тәгалә бу айда көндез ураза тотуны фарыз, кич уяу торуны нәфел кылды (нәфел гамәл башкару) гүя Рамазаннан башка айларда фарызны үтәгән кебектер. Бер кеше Рамазанда фарызны үтәсә, гүя Рамазаннан башка вакытта җитмеш фарызны үтәгән кебек булыр. Рамазан ае – ул сабырлык ае.

Сабырлыкның савабы – җәннәт. Ул ай тигезлек ае, бу айда мөэминнең ризыгы арттырылыр. Берәү ураза тотучыга авыз ачтырса,

аңа кол азат итү әҗере булыр һәм гөнаһлары ярлыканыр». Без: «Әй, Расүлуллаһ, безнең беребез дә ураза тоткан кешене авыз ачтырырга әйбер тапмыйбыз», – дип әйттек. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Аллаһы Тәгалә бу савапны сөт, хөрмә, яки бер йотым су белән авыз ачтыручыга да бирә. Бер кеше ураза тотучыны туйдырса, аның гөнаһларына ярлыкау булыр һәм ул кешене Раббысы минем махсус күлемнән бер мәртәбә эчерер. Бер мәртәбә эчкәннән соң, оҗмахка кергәнчегә кадәр һич сусамас», – дип әйтте.

9. Пәйгамбәребез: «Авыз ачтыручыга ураза тоткан кешенең әҗере кебек, һич ким булмаган әҗер булыр. Ул шундый ай – аның башы рәхмәт, уртасы гөнаһларны ярлыкау, ахыры җәһәннәмнән азат итү булыр. Бер кеше ураза вакытында хезмәтчесенең хезмәтен җиңеләйтсә, Аллаһы Тәгалә ул кешене җәһәннәмнән азат итәр».

10. Факыйһ үзенең иснәде белән Ибне Мәсгудтән риваять итә: «Аллаһыны зикер итсә, Аллаһы Тәгалә хәләл иткән нәрсәне хәләл, харамын харам дип белсә, ул Рамазанда начар һәм кабахәт эшкә дучар булмаса, тиешле көнендә Рамазаннан чыкса, әнә шундый бәндәнең бөтен гөнаһлары ярлыканыр, һәр тәсбих һәм тәһлил бәрабәренә оҗмахта яшел зөбәрҗәт таштан бер өй төзелер, зөбәрҗәт ташның эчендә кызыл якут, якутның эчендә куыш эчле энҗедән чатыр булыр. Шул энҗе эчендә хур кызларыннан бер хатын булыр. Ул хатын кулында алтыннан, кызыл якут белән бизәлгән ике беләзек булыр. Аның яктылыгыннан җир яктырыр».

11. Әбү Мәсгуд радыяллаһу ганһе Пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять итә, ул болай дип әйтте: «Тәхкыйк, Рамазан ае якынлашты. Рамазан аеның нинди әҗерле икәнен белсәләр, минем өммәтем ул айның ел буе булуын теләрләр иде». Хузәга кабиләсеннән бер кеше: «Безгә Рамазандагы әҗер турында сөйлә әле», – дип әйтте. Пәйгамбәр галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Җәннәт ел буе Рамазан ае өчен бизәлер. Рамазанның беренче киче җиткәч, Гареш астыннан җил исәр, оҗмах агачларының

яфракларына бәрелүдән алар чыңлап китәр. Бу хәлгә хур кызлары карарлар һәм: «Бу айда безнең өчен бәндәләреңнән ирләр кыл, безнең күзләребез аларга карап, аларның күзләре безгә карап нурлансын…» – дип әйтерләр.

12. Пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять ителә, ул болай дип әйтте: «Раҗәб ае минем өммәтемнең ае. Ул раҗәбнең башка айларга караганда артыклыгы – минем өммәтемнең башка өммәтләргә караганда булган артыклыгы кебек. Шәгъбан ае – ул минем ай. Рамазанның башка айларга караганда булган артыклыгы – Аллаһы Тәгаләнең мәхлүкълары каршында булган артыклыгы кебек».

13. Факыйһ үзенең иснәде белән Хәсәннән риваять итә: «Дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәлам чыкканда, кешеләр бер-берсе белән низаглашалар иде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Сезгә Кадер кичәсе хакында хәбәр бирү өчен килдем һәм шул Кадер кичәсендәге әҗерләргә ышанмавыгыздан куркам. Шаять, Кадер кичәсенә ышануыгызда изгелек булыр. Соңгы ун көне эчендә тугызы калганда, ул Кадер кичәсен эзләгез. Җиде көн калганда, калган бишендә һәм өч көн калганда, соңгы кичәсендә эзләгез. Ул Кадер кичәсенең галәмәтләре: ул ачык һәм җиңел кич, эсселеге дә һәм салкыны да булмас. Ул кичнең иртәсендә кояш чыгар, кояшның күләгәсе булмас, ягъни томанланмас. Бер кеше ул кичтә әҗер-савапка ышанып уяу торса, Аллаһы Тәгалә аның шул кичтән әүвәл булган гөнаһларын ярлыкар».

14. Факыйһ әйтте: «Тәхкыйк, Пәйгамбәр галәйһиссәлам кич уяу торуда һәм көндез ураза тотуда ышануны һәм ризалыкны шарт кылды. Аллаһы Тәгалә вәгъдә иткән савапка күңел белән ышану – иман була. Аллаһы Тәгаләнең вәгъдә иткән савабына юнәлгән һәм Аллаһы Тәгаләгә кечелек кылган хәлдә булу – ризалык була. Әгәр бәндә Пәйгамбәр галәйһиссәлам бәян иткән савапларга һәм фазыйләтләргә ирешергә теләсә, Рамазан аеның хөрмәтен тану, телне ялганнан, гайбәттән

һәм артык сүздән, әгъзаларны хаталардан һәм аяк таюдан, күңелне көнләшүдән, мөселманнарга дошман булудан саклану тиешле. Әгәр моны эшләсә, Аллаһы Тәгалә ул бәндәдән кабул итәрме, юкмы дип куркырга кирәк».

15. Хәкимнәрнең кайберләреннән риваять ителә. Бер хәким: «Әй, минем Раббым! Дөньяда кайгы иясенә әҗер бирүне өстеңә алдың, Ахирәттә савап бирүне вәгъдә иттең. Әй Раббым! Әгәр син безгә бу уразаны кайтарсаң, безне кайгы бәрабәренә бирә торган әҗердән мәхрүм итмә, әй күркәм сыйфатлар белән танылган күркәм Зат!» – дип әйтә торган булган.

16. Әбү Зәрдән риваять ителә, ул болай дип әйтте: «Пәйгамбәр белән ураза тоттык. Ул Рамазанның егерме өченче кичәсе булгач, кич белән торып, төннең өчтән бер өлеше үткәнгә кадәр намаз укыды. Моннан соң егерме дүртенче кичәсе булгач безгә чыкмады. Егерме бишенче кичәсе булгач, янә безнең янга чыгып, кичнең ярты өлеше үткәнгә кадәр безнең белән намаз укыды. Без: «Бу кичәбез артыграк булсачы!» – дидек. Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Берәү чыгып, имам белән, ул имам кайтып киткәнгә кадәр, кич торса, аңа бөтен кич уяу торган савабы язылыр», – дип әйтте. Моннан соң егерме алтынчы кичәдә Пәйгамбәр галәйһиссәлам безнең белән намаз укымады. Егерме җиденче кичә булгач, торып бөтен гаиләсен җыйды һәм безнең белән намаз укыды, хәтта фәләх вакыты үтүдән курыктык». Без: «Нәрсә ул «фәләх?» – дип сорадык. Әбү Зәрр: «Сәхәр ашау», – диде.

17. Гайшә радыяллаһу ганһәдән риваять ителә. Рамазан киченең башында Пәйгамбәр галәйһиссәлам чыгып, мәчеттә намаз укыды. Аның белән бергә кешеләр дә намаз укыдылар. Таң аткач, кешеләр бу хәлне сөйләшә торган булдылар. Икенче кичтә кешеләр күбәйде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам намаз укыды, аның белән бергә башкалар да укыдылар. Өченче кичә булгач, халык күбәйде, хәтта мәчет әһеленнән гаҗиз калды,

мәчеткә сыймас булдылар. Пәйгамбәр галәйһиссәлам кешеләр янына чыкмады, бары тик иртәнге намазга гына чыкты. Иртә намазын укыгач, кешеләргә карап: «Пәйгамбәр бу кичәдәге эшегездән курыкмады. Ләкин мин сезнең хозурга кичке намазның фарыз ителүеннән курыктым. Әгәр фарыз ителгән булса, үтәүдән гаҗиз булыр идегез», – дип әйтте.

18. Гайшә радыяллаһу ганһә: «Пәйгамбәр галәйһиссәлам кешеләрне Рамазан кичләрендә уяу торуны фарыз итеп боермыйча, өнди генә иде; Расүлуллаһ вафат булгач, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең хәлифәлек заманында бу эш шулай ук дәвам итте. Гомәр бине Әл-Хаттаб хәлифәлегенең әүвәлге вакытында да бу эш шул рәвештә калды. Гомәр кешеләрне Өбәй бине Кәгъб радыяллаһу ганһәнең өенә җыйды», – дип әйтте.

19. Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Ул: «Гомәр бине Хаттаб бу тәравихны миннән ишеткән хәдистән алды», – дип әйтте. Әйттеләр: «Әй, мөэминнәрнең әмире, ул нинди хәдис?» Ул: «Расүлуллаһ галәйһиссәламнән ишеттем, ул: «Гареш тирәсендә Аллаһы Тәгаләнең яраткан урыны бар, ул урынны «Хәзыйратүл-кудс» диләр. Ул урын нурдан, андагы фәрештәләрнең һич саны юк. Мәгәр аларның санын Аллаһы Тәгалә генә белә. Аллаһы Тәгаләгә шулкадәр гыйбадәт кылалар ки, вакытларын һич гыйбадәтсез үткәрмиләр. Рамазан аеның кичәләре җиткәч, Раббыларыннан җиргә иңәргә рөхсәт сорарлар. Адәм балалары белән намаз укырлар, һәр кичәне җиргә төшәрләр. Аларны тоткан һәр кеше, яки алар тоткан һәрбер кеше шундый бәхетле булыр ки, ул бәхеттән соң мәңге кайгы күрмәс», – диде. Гомәр: «Бу сүзне сөйләгәч, әлеге гамәлне кылу безгә бигрәк тә тиешле», – дип әйтте. Хәзрәти Гомәр кешеләрне тәравих намазына җыйды. Һәм шул тәравих намазын шәргый итеп куйды», – дип әйтте.

20. Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Ул Рамазан аеның бер кичендә чыккач, мәчетләрдә кыйраәтне ишетеп һәм

андагы ялтыраган кандилләрне[1] күреп: «Гомәр безнең мәчетләребезне Коръән белән нурландырган кебек, Аллаһы Тәгалә Гомәрнең каберен яктыртса иде», – дип әйтте. Бу Госман бине Гаффән радыяллаһу ганһедән дә шулай ук риваять ителде.

*«Тәнбиһүл гафилин» китабыннан (2 том, Казан, 2004)*

1 Кандил – люстра

# Нәсыйхәт

# Сәхабәләрнең әхлагы һәр мөселманга үрнәк

Аллаһы Тәгалә Изге Коръәндә:

وَإِنَّكَ لَعَلَىٰ خُلُقٍ عَظِيمٍ ﴿٤﴾

**«Тәхкыйк, син күркәм холыктасың»,** – дип әйтә.

«Нун», 68:4

Шулай ук сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә: «Мин әхлакны камилләштерүне тәмамлау өчен җибәрелдем», – дип әйтә.

Барчабызга мәгълүм: Ислам динендә кешенең башка кешеләргә, гомумән барча мәхлүкъларга, тормышның төрле яссылыкларына карашы, мөнәсәбәте нинди булырга тиешлеге ачык билгеләнгән. Димәк, Ислам кешегә бу тормышта нәрсә кирәк булса, шуның барчасына өйрәтә. Бу кыйммәтле гыйлемнәрне без сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам янәшәсендә булган, аның белән бергә үскән һәм яшәгән кешеләрдән алабыз. Сәхабәләрнең тәрбиясе булып Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөйләгән сүзләр булган, ә хәзер без алардан үрнәк алабыз.

Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе башкалар арасында үзенең гаделлеге белән аерылып торган. Госман радыяллаһу ганһе бик оялчан һәм тыйнак булган. Гали радыяллаһу ганһене «гыйлем капкасы» дип атаганнар. Габбас радыяллаһу ганһене кешеләр зур галим буларак хөрмәт иткән. Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе шәригать мәсьәләләрендә тирән гыйлем һәм зирәклек күрсәткән. Халид бине Вәлид радыяллаһу ганһе – бөек гаскәр башлыгы. Бик күп хәдисләр тапшыручыларның берсе Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе булган. Сәлман Әл-Фәриси радыяллаһу ганһе бөек фикер иясе булган. Аларның барчасыннан да Аллаһы Тәгалә разый булсын.

Бөек Мостафа Исмәт Гарибуллаһ үзенең «Рисалә Кодсия» китабында: «Бу барлык шәхесләр (сәхабәләр) галәмнәрнең Раббысының хәзинәсе булып тора», – дип әйткән.

Дөрестән дә, Аллаһы Тәгалә бу кешеләрне олылады, алар Расүлуллаһ галәйһиссәламнән тәрбия алды. Шуңа күрә без аларның һәркайсысы турында да бары тик яхшы сөйләргә тиешбез.

Җәрир бине Габдуллаһ радыяллаһу ганһе – мәшһүр сәхабәләребезнең берсе. Бу мәкаләдә аның мисалында мөселманнар арасындагы мөнәсәбәтләр нинди булырга тиешлеген күрсәтергә телим.

Бервакыт Җәрир, ат алырга дип, базарга үзенең хезмәтчесен җибәргән. Хезмәтче базарда бер сатучыдан атның бәясен белешкән. Башта алар килешә алмасалар да, соңыннан атның бәясе 300 дирһәм дип билгеләгәннәр. Җәрирнең хезмәтчесе үзе белән мондый акчалар булмавын әйткән, һәм бергәләп Җәрирнең үзе янына барырга тәкъдим иткән. Сатучы белән хезмәтче Җәрир радыяллаһу ганһе янына киткәннәр.

Җәрир хезмәтчесеннән: «Атны нинди бәягә алдың?» – дип сораган. Хезмәтче 300 дирһәмгә икәнен әйткән. Башка бәяне ишетергә әзер булган Җәрир игътибар белән сатучының күзләренә караган һәм безнең өчен бер дә көтелмәгән сорау биргән: «Син атыңны 500 дирһәмгә сатарга ризамы?»

Сатучы дәшмәгән, җавап бирмәгән. Ә Җәрир радыяллаһу ганһе дәвам иткән: «Бу ат өчен 600 дирһәм җитәрлек булырмы?» – дип сораган. Сатучы янә дәшмәгән, ә янәшәдәге кешеләр моны гаҗәпләнеп күзәтеп торган. Җәрир бәяне арттырган: «700 дирһәм?»

Сатучы түзмәгән, гаҗәпләнеп: «Кем сез? Сатучымы әллә алучымы? Гомеремдә әйбернең үз бәясеннән артыграк бәһа тәкъдим итүчене күргәнем булмады. Әйтегезче, сез бу ат өчен ник шундый акчалар тәкъдим итәсез?» – дип сораган.

Ә Җәрир радыяллаһу ганһе болай дип җавап кайтарган: «Расүлуллаһка бәйгать (ант) китергәндә, мин һәр мөселман белән гадел һәм намуслы булачакмын, дип сүз бирдем. Ә синең атың 700 дирһәм тора. Аның өчен азрак түләсәм, Пәйгамбәр галәйһиссәламгә биргән антымны бозар идем».

Сәхабәләрнең тормыш юлы бик әһәмиятле, без аларны һичшиксез өйрәнергә тиеш, чөнки алар Мөхәммәд пәйгамбәребез өйрәтеп калдырган күркәм әхлак, тыйнаклык һәм гаделлек үрнәкләре. Хәтта сәүдә кебек мәсьәләләрдә дә алар үзләренең Аллаһы Тәгалә күзәтүе астында булуын онытмаган. Аларның калебләре пакь һәм ихласлык белән тулы булган, сәхабәләр Раббыбыз кушканнардан, Изге Коръәндә билгеләнгән чикләрдән бер адым да тайпылмаган.

Сөекле Пәйгамбәребез: «Минем сәхабәләрем – йолдызлар сыман: аларның кайсысына гына иярсәгез дә, хакыйкать юлын табарсыз», – дип әйткән. Аллаһы Раббыбыз безгә Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Сөннәте буенча яшәргә насыйп итсен иде һәм моны безләргә җиңеләйтсен иде. Әәмин.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

# Йосыф галәйһиссәлам – бөтен кешелек өчен югары әхлакның гүзәл үрнәге

## «Йосыф» сүрәсе – күңелләргә үтеп кергән гүзәл кыйссаларның берсе

Бер йөз унбер аятьтән торган «Йосыф» сүрәсе Коръәннең иң яхшы гыйбрәтле һәм гүзәл эчтәлекле кыйссаларыннан санала.

Ни өчен «Йосыф» сүрәсенә игътибар шул дәрәҗәдә югары бирелә соң? Чөнки ул Коръәндә иң җентекле хикәяләнгән кыйссаларның берсе булып тора. Кеше тормышындагы уңай һәм тискәре вакыйгалар бик оста тасвирлануы белән, җәмгыятьнең бөтен катлау ирләре һәм хатын-кызларына да кагыла. Шулай ук адәм баласы үз гомерендә кичерә торган рухи яшәешнең һәммә күренешләре гаҗәеп нечкәлекләре белән бирелә.

Монда олы яшьтәге пәйгамбәрнең төпчек улларына карата аталарча яратуы да бар. Шул нисбәттән өлкән улларында туган усал көнчелек һәм аларның Йосыфка кылган хыянәтләре дә тасвирлана.

Ата кешенең яраткан улын югалту хәсрәте, Йосыфның колдан түбән дәрәҗәдә бик арзан хакка базарда сатылуы, саф һәм чиста мәхәббәткә капма-каршы буларак эгоистик хисләр бәрелешүе, яла ягып, гаепсез кешене зинданга яптырып, соңыннан тәүбәгә килеп гафу сорау, гафу үтенү, төш юрау, дәүләт белән идарә итү, түбән һәм әхлакый тормыш алып бару. Шулай ук, ил җитәкчесенең гаҗәеп гаделлеге һәм халыкчанлыгы һәркемдә зур соклану тудыра. Ата һәм ул арасындагы мөнәсәбәт, алар арасындагы тугрылык һәркемдә кызыксыну уята һәм Аллаһыдан куркуның иң югары дәрәҗәсенә җиткерелеп, иң гүзәл үрнәк рәвешендә тасвирлануы – боларның һәммәсе «Йосыф» сүрәсендә үз урынын табып, иң тәэсирле хикәяләү үзенчәлекләре белән бирелгән. Менә шуның өчен дә ул күңелләргә үтеп кергән гүзәл кыйссаларның берсе.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

لَقَدْ كَانَ فِي قَصَصِهِمْ عِبْرَةٌ لِّأُولِي الْأَلْبَابِ ۗ مَا كَانَ حَدِيثًا يُفْتَرَىٰ وَلَٰكِن تَصْدِيقَ الَّذِي بَيْنَ يَدَيْهِ وَتَفْصِيلَ كُلِّ شَيْءٍ وَهُدًى وَرَحْمَةً لِّقَوْمٍ يُؤْمِنُونَ ﴿١١١﴾

**«Сөйләнгән ошбу Йосыф галәйһиссәлам кыйссасында, әлбәттә, гакыл ияләренә гыйбрәтләр бар. Коръән Аллаһы исеменнән сөйләнгән ялган сүз түгел, әлбәттә, Аллаһы Тәгаләнең Үзенең сүзе, Үзеннән элек иңдерелгән китапларны дөресләп иңдерелгән хак китаптыр вә һәрнәрсәнең хөкемен бәян итеп, иман китергән кешеләргә һидаять һәм рәхмәт булсын өчен иңдерелде».**

«Йосыф», 12:111

Коръәндәге сүрәләрнең гади хикәяләү генә булмыйча, ә һәр сүзеннән илһам чишмәсе бәреп торучы тәэсирле вәгазь булуын күрәбез.

Исеменнән үк күренгәнчә, биредә Йосыф галәйһиссәламнең тормышы хакында сүз бара. Кечкенәдән әнисез үсеп, агаларының яман холкы аркасында әтисен дә, туып үскән илен дә калдырырга дучар ителгән Йосыф галәйһиссәлам кол хәленнән бөек патша дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Ул үзенә Раббысы тарафыннан тапшырылган изге бурычын намус белән үтәп чыга һәм бөтен кешелек өчен югары әхлакның гүзәл үрнәгенә әверелә.

Бу сыйфатлама Йосыфның Аллаһы Илчесе, ягъни пәйгамбәр буларак кешеләргә Ислам динен таратуында да, яшәү барышында килеп туган һәртөрле вакыйгаларда үзен ничек тотуында, аеруча ата-анасына һәм туганнарына карата мөнәсәбәтләрендә дә бердәй чагылыш таба. Шул чаклы олуг кешелек кыйммәтләрен үз эченә алган кыйссага аерым бер сүрә багышлану бер дә гаҗәп түгел. «Йосыф» сүрәсе – Аллаһыдан

килгән тәкъдирнең галиҗәнәб көчен бөтен куәтенә тасвирлаган иң мавыктыргыч сүрә.

Төш күргән вакытта Йосыф галәйһиссәламгә 10 яшь булса, атасы, агалары Мисырга килгәндә ул инде 50 яшьлек патша дәрәҗәсенә күтәрелгән була. Менә шушы 40 ел эчендә Йосыф галәйһиссәлам коллыкны да, көнчелекне дә, зинданны да, хатын-кыз фетнәсен дә, дошманлык-дуслык, байлык-патшалыкны да, ялгызлыкны да кичерә.

## Олуг кыйммәтләрне үз эченә алган сүрә

Изге Коръәни Кәримдә нинди генә кыйсса укысак та, аның төп максаты – әдәп-әхлак, рухи байлыгыбызны җиткерү. Ягъни адәм баласына ничек итеп гамәл кылырга кирәклеге пәйгамбәрләр тормышы, алар белән булган вакыйгалар аша аңлатыла.

Йосыф бик күркәм, гадел, итагатьле бала булып үсә, шуңа күрә дә әтисе Ягъкуб галәйһиссәлам аны башка балаларга караганда күбрәк ярата.

Уйлап карасак, безнең тормышта да шул ук хәл бит. Гаиләдә 5 бала булса, бишесе дә бертигез яратылмый. Югыйсә, бармакларның кайсын тешләсәң дә авырта, дисәләр дә. Бер анадан: «Кайсы балаңны күбрәк яратасың?» – дип сораганнар. «Кечкенәсен – үскәнче, ерагын – кайтканчы, авырганын – терелгәнче», – дип җавап биргән ана. Гадәттә, гаиләдә зуррак балалар, бала табу йортыннан кечкенә бәби алып кайткач, үзләрен кая куярга белми йөри. «Мәхәббәт» кечкенә энесенә күчәр дип курка.

Әгәр ата-ананың баланы яратуы һәрберсенә тигез бүленмәсә, алар арасында үзара көнчелек, хөсетлек килеп чыгуын көт тә тор.

Җитәрлек дәрәҗәдә ата-ана назы күрмәгән бала тормышта үз урынын, үз юлын авыррак таба, андыйларның күңелендә, ни кызганыч, иң якын кешеләренә карата гомерлек үпкә, хәтта рәнҗү саклануы мөмкин.

Билгеле булганча, Ягъкуб пәйгамбәр Йосыфны бик ярата, чөнки Биниаминне тудырганда, әниләре Рәхилә вафат була, бу ике бала бөтенләй әнисез кала. Ун олы баласының аналары исән, ә ике кечкенәсенең әниләре юк.

Әмма балалар арасында мөгамәлә бертөрле булырга тиеш. Бер балага бүләк алдыңмы, икенчесенә дә ал, берсенә якты йөз күрсәттеңме, икенчесенә дә җылы карашыңны кызганма. Берсен киендердеңме, икенчесен дә киендер. Ата-ана, күпме баласы булуга карамастан, һәрберсенә тигез мөнәсәбәт күрсәтергә тиеш. Кыскасы, ислам тәгълиматы гаиләдәге балаларны тигез күреп яратырга куша, тигез күреп тәрбияләргә өйрәтә.

Көнләшү… Җәмгыятьтә кылынган җинаятьләрнең нигезендә, асылында көнчелек ята. Көнләшүнең гөнаһ икәнлеген без фәкать Коръәннән укып беләбез. Нинди генә җинаятьнең сәбәбен эзләп карасак та, ул көнчелек булыр.

Йосыфны үтермичә коега салыйк, узып барган кәрван табар, без тәүбә итәрбез, диләр агалары. 2 рәкәгать тәүбә намазы укыгач гөнаһлар ярлыкана, дип уйлый кайберәүләр.

Шәйтан аларның күңеленә нинди вәсвәсә сала? Коега салу – үтерүгә караганда да зуррак гөнаһ. Чөнки кеше анда газапланып, кычкырып ачлыктан интегеп үләчәк. Көнләшкән вакытта кеше үз холкына туры килмәгән гамәлләрне дә башкарырга мөмкин. Йосыфның туганнарына да шәйтан шулай вәсвәсә сала.

## Йосыфның түбән хисләрдән өстен калуы

Йосыф галәйһиссәлам Аллаһыдан куркучы мөэмин була. Вәзир йортында яшәгәндә зина фетнәсенә дучар ителә. Аңа бу вакытта 25, ә Зөләйхага 40 яшьләр тирәсе. Үзенең түбән хисләренә бирелеп, Йосыфны ул зур гөнаһка өнди. Егет Аллаһыга ялвара:

قَالَ رَبِّ السِّجْنُ أَحَبُّ إِلَيَّ مِمَّا يَدْعُونَنِي إِلَيْهِ ۖ وَإِلَّا تَصْرِفْ عَنِّي كَيْدَهُنَّ أَصْبُ إِلَيْهِنَّ وَأَكُن مِّنَ الْجَاهِلِينَ ﴿٣٣﴾

**«Йә, Раббым! Мине чакырган зинага караганда миңа зиндан яхшырак, әгәр ул хатыннарның хәйләләрен миннән Үзең бетермәсәң, ул вакытта мин аларга авышырмын вә ярамаган эшне эшләп җаһилләрдән булырмын».**

«Йосыф», 12:33

Бу урында һәммә кешеләр өчен мөһим булган ике төшенчәгә игътибар итик әле: бар ләззәт, бар сәгадәт. Күпләр бу төшенчәләрнең асыл мәгънәсен аңлап бетермәү сәбәпле, еш кына аларны бутый. Ләззәт ул – бик кыска вакытлы хис-тойгы. Әмма ләззәт, аеруча харам ләззәт, беркайчан бәхет-сәгадәт чыганагы була алмый. Киресенчә, алардан нәфесеңне тыеп кала алмау бәхет-сәгадәттән ерагайтып, газап һәм михнәт сәбәпчесенә әйләнә. «Бәхет нәрсә ул?» дигән сорауга бер акыл иясе: «Нинди генә сынаулар килгәндә дә үзеңнең кешелегеңне саклап кала алу», – дип җавап биргән. Димәк, бәхет-сәгадәт ул – гөнаһлардан ерак булу.

Зинадан качу өчен нинди дәлил күргән икән Йосыф галәйһиссәлам? Гали радыяллаһу ганһе риваятеннән аңлашылганча, ошбу хатын янындагы потны пәрдә белән каплап куйган. Әмма Йосыф, Аллаһының күзен бернәрсә белән дә каплап куеп булмый, ул адәм баласын һәрвакыт, һәркайда күреп торганлыгын белгән һәм шушы хакыйкатьнең харамнан ерагаю өчен иң зур дәлил булуын аңлап алган.

Зөләйханың ире зәгыйфьлек вә йомшаклык күрсәтеп, хатынына буйсына һәм бер гаепсез Йосыфны зинданга яптыра. Боларның гаилә тормышындагы ыгы-зыгы, гайбәт, алар өчен зур бәлагә әверелә, дәрәҗәләрен саклап калу максатыннан ошбу карарга киләләр дә инде.

Йосыф зинданда да кешелеген югалтмый. Башкалар белән дустанә мөнәсәбәттә булып аралаша. Зинданда вакытта Аллаһы Тәгалә аңа төш юрауны өйрәтә. Моннан тыш Йосыф зиндандагы халыкны дингә өнди. Аталары Ибраһим, Исхак, Ягъкуб диненә чакыра. Аллаһыга ширек китерергә ярамаганлыгын исбатлый.

Алга таба кыйссада Мисыр патшасының төше турында сөйләнелә. 7 арык сыерның 7 симез сыерны ашавы турында, 7 яшел башак белән 7 коры башак турындагы төшне юрарга Йосыф галәйһиссәламгә киләләр. Йосыф әлеге төшне түбәндәгечә юраган:

قَالَ تَزْرَعُونَ سَبْعَ سِنِينَ دَأَبًا فَمَا حَصَدتُّمْ فَذَرُوهُ فِي سُنبُلِهِ إِلَّا قَلِيلًا مِّمَّا تَأْكُلُونَ ﴿٤٧﴾ ثُمَّ يَأْتِي مِن بَعْدِ ذَٰلِكَ سَبْعٌ شِدَادٌ يَأْكُلْنَ مَا قَدَّمْتُمْ لَهُنَّ إِلَّا قَلِيلًا مِّمَّا تُحْصِنُونَ ﴿٤٨﴾ ثُمَّ يَأْتِي مِن بَعْدِ ذَٰلِكَ عَامٌ فِيهِ يُغَاثُ النَّاسُ وَفِيهِ يَعْصِرُونَ ﴿٤٩﴾

**«Йосыф әйтте: «Җиде ел тоташтан иген чәчегез, җиде елда уңыш яхшы булыр, алган уңышны сукмыйча башагы вә саламы белән кибәндә сакларсыз, мәгәр үзегез ашар хәтле генә сугып алырсыз. Моның соңында җиде ел ачлык еллары килер, уңышлы җиде елда җыйган игеннәрегез җиде ачлык елларында ашалып бетәр, мәгәр орлык өчен саклаган аз гына игеннәрегез калыр. Соңра ачлык елларыннан соң бер ел килер, ул елда яңгырлар явар, кешеләргә игеннәр вә җимешләр үсәр...».**

«Йосыф», 12:47-49

Аллаһының рәхмәте белән Йосыфның гаепсез икәне ачыклана. Патша аны үз янына эшкә ала һәм күпмедер вакыт узгач, ул Йосыфта ил белән идарә итү сәләтен күреп ала, үз вазифасыннан баш тартып, аны ла-

еклырак кешегә – Йосыфка тапшыра. Шулай итеп, Йосыф галәйһиссәлам Мисыр патшасы була.

Уйлап карасак, Аллаһының кодрәтенә вә хикмәтенә гаҗәеп мисал: коедагы Йосыф кол, тоткын була, ә еллар үткәч, зур дәүләтнең патшасы дәрәҗәсенә күтәрелә.

## Йосыфның миһербанлыгы

Ягъкубның кабиләсе дә ачлыктан интегә. Өйләрендәге соңгы зиннәтләрен төяп, Йосыфның ун агасы Мисырга ашлык алып кайтырга китә. Йосыф үзенең ярдәмчеләренә ашлык сатып алырга дип китергән зиннәтләрен кире капчыкларга тутырырга куша. Сәбәбен ничек аңларга? Бу байлыклар Йосыфның атасыныкы, ә ата кешедән ипи-ризык өчен акча алырга ярамый. Бу Йосыфның миһербанлыгына тагын бер дәлил.

Йосыф дәүләт белән гадел идарә итүче, халык турында кайгыртып яшәүче бөек җитәкче. Ул акыл иясе, алдан күреп эш итә, авыр ачлык елларында халыкны үлем һәлакәтеннән коткара.

Пәйгамбәрләр – Аллаһының иң яраткан колларыдыр. Шуның өчен дә сынауларның иң авыры, иң газаплысы алар җилкәсенә төшкән. Ә сынау килгәндә, адәм баласының кешелеген вә иманын саклап кала торган күркәм сыйфат – сабырлык. Сабыр итүнең әҗер-саваплары бәһасез! Хәерле юлда йөреп, Үзенә ихлас инанган бәндәләренә җибәрелгән тормыш сынаулары – ул Аллаһы Тәгаләнең колына олуг нигъмәт бирер алдыннан аның моңа лаеклымы, юкмы икәнен тикшереп карауга тиң. Кешегә Раббысы тарафыннан әзерләнгән нигъмәт никадәр зур бәһале вә кадерле булса, аңа ирешү юлында очраган сынаулар да шуңа бәрабәр рәвештә авыр вә катлаулы. Фани дөнья тозагына гүзәл әхлак белән каршы торып, бар сабырлыкны җыеп, тормыш дәрьясын ахырынача саф иман белән кичеп чыга алганнар әнә шул бөек, хәерле дәрәҗәләргә ирешәләр дә инде. Бу мәңгелек хакыйкать Коръәни Кәримнең «Йо-

сыф» сүрәсендә бөтен тулылыгы вә нечкәлеге белән, Аллаһы Тәгалә Үзе вәгъдә иткәнчә, иң гүзәл сурәттә аңлатыла. Коръән Кәримдәге «Йосыф» сүрәсе халкыбызның рухында, күңелендә яши. Ә Йосыф галәйһиссәлам исә бөтен кешелек өчен югары әхлакның гүзәл үрнәге булып тора.

*Зәйтүнә Гарипова,*

*Арча районы Яңа Кырлай мәчете мөгаллимәсе*

# Тәрбия

# Бала һәм милли аң

Бала үзенең милли телен, милли гореф-гадәтләрен, милли геройларын белергә тиеш. Милли тарихын, милли каһарманнарын белмәгән баланы камил дип әйтеп булмый. Безне 70 ел буе милләтсез, динсез кавем итеп тәрбияләргә тырышып карадылар, уңай нәтиҗә булмады. Кызганыч, бүген дә кайбер тар фикерле дин әһелләре: «Исламда милләт юк, милли үзенчәлекләргә, гореф-гадәтләргә урын юк», – дип акыл саталар. Аллаһы Раббыбыз Коръәндә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ ﴿١٣﴾

> **«Ий, кешеләр. Без сезләрне бер ир вә хатыннан халык кылдык, вә соңра сездән тармаклар, кабиләләр кылдык, бер-берегезне аерып тануыгыз өчен, сезнең Аллаһы хозурында хөрмәтлерәгегез – Аллаһыдан куркып, гөнаһлардан саклanучыгыздыр»,** – дип әйтте.

«Хуҗүрат / Бүлмәләр», 49:13

«Сезнең хәерлерәгегез – бер кавемгә әйләнүегез», – димәде бит, «Бер-берегезне таныган хәлдә, изге гамәлләрдә ярышучыларыгыз», – диде. Милли үзенчәлекләрегез, милли гореф-гадәтләрне сакламасак, бер-беребезне ничек танырбыз? Милләтләр кирәк булмаса, Аллаһы аларны яратмас, аятьләре белән әһәмиятен дә аңлатмас иде. Милли үзенчәлекләрне санга сукмау, гореф-гадәтләрне инкяр итү – Аллаһыга каршы килү була. Төрле ноталарның бер тәртипкә салынуы көй чыгарган кебек, төрле халыкларның Җир йөзендә бер-берсен хөрмәт итеп яшәүләре дә гармония тудыра. Әмма милли тәрбия, милли аң, милли

горурлык башка халыкларны кимсетү хисабына булырга тиеш түгел. Аллаһы Раббыбыз Коръәндә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا يَسْخَرْ قَوْمٌ مِّن قَوْمٍ عَسَىٰ أَن يَكُونُوا خَيْرًا مِّنْهُمْ ﴿١١﴾

**«Әй, мөэминнәр, бер кавем икенче кавемне кимсетмәсен, ул кимсетелгән кавемнең кимсетә торган кавемнән яхшырак булуы ихтимал»,** – дип әйтте.

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:11

Йә гарәп, йә төрек, йә урыска охшарга тырышып, үз милләтебезгә кимсетеп карасак, әлеге аятькә каршы килүчеләр булмабызмы? Шул ук вакытта башка бер милләтне кимсетеп карау да дөрес түгел. Аллаһы Раббыбыз безгә бу аятьтә: «Мөэминнәр», – дип эндәште, димәк, иманлы кеше үз милләтенә дә түбәнсетеп карамас, башка милләтне дә хөрмәт итәр.

Бөек урыс галиме, педагог һәм психолог К. Д. Ушинский да (1824–1870): «Милли тәрбия генә көткән нәтиҗәне бирә, тулы канлы шәхесләр формалаштыра», – дигән.

Безнең кебек милли азчылыкны, дини азчылыкны да тәшкил итүче халыкка, үзебезнең милли үзенчәлекләребезне саклау аеруча мөһим. Телебезне, гореф-гадәтләребезне оныту безне урыслашуга, шуның белән бергә динебездән ваз кичүгә дә китерә. Андыйларның меңнән бере бәлки динебезне югалтмас, әмма күпчелеге югалтачак. Үз заманында Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре дә: «Өч төрле әйбер диндә булмаса да, динне саклый, алар: милли тел, милли кием, милли гореф», – дип язды. Әби-бабаларыбыз урыслардан аерылып тору өчен, яулыкны да үзләренчә бәйләгәннәр, түбәтәйләрен дә салмаганнар, сакалны да үзләренчә йөрткәннәр. Татарның мәшһүр каһарманы Канкай

улы Бәхтияр, Пугачев янына килгәч, аңа түбәтәен салырга кушалар. Ул: «Татарның башта башы төшә, аннан соң гына түбәтәе», – дип җавап бирә. Никадәр горурлык һәм үз-үзеңне хөрмәт итү. Татар кешесе беркем каршында да – түбәтәен, чечен бүреген салмаган. Шуның өчен дә коммунистлар бу баш киемен законнан тыш дип игълан иттеләр һәм яланбаш яки кепка йөрүне модага керттеләр.

Бу шаукымга үзбәкләр генә бирешмәде, алар съезда да түбәтәй киеп утырырга үзләрендә көч таптылар, алар союздаш республика халкы иде, без автономия генә булдык. Бүген түбәтәй кияргә оялучы яшьләребез бу турыда белми, түбәтәйне искелек, гореф калдыгы дип кенә саный.

Үз милләтенең үзенчәлекләре: теле, киеме белән горурлана белмәгән бала – тулы канлы була алмый. Ул инде милләте аркасында гына да үзен кимчелекле, түбән сортлы кеше дип саный. Киресенчә, үзенең нәсел-нәсәбәсен, милләтенең тарихын белгән, аның белән горурлана алган бала беркайчан да үзен мескен итеп тотмас һәм киләчәккә юл ярганда бу сыйфат аңа, башкалар белән үзен тиң санап, алга барырга көч бирер.

## Гореф-гадәт йогынтысы

Гореф-гадәтләрнең, милли бәйрәмнәрнең каян килеп чыгуларын, уңай һәм тискәре якларын, тарихын бала күзалларга тиеш. Кеше көн саен тантана ясарга, бәйрәм итәргә мөмкин. Әмма бу бәйрәм нәрсәгә китерә, кешенең нинди сыйфатларын үстерә? Бала моны аңлап эшләргә тиеш. Әледән-әле төрле бәйрәмнәрдә катнашу, йөрү аркасында бала зарарлы гадәтләргә дә ияләшергә мөмкин. Күп балалар хәмерне беренче мәртәбә бәйрәмнәрдә авыз итәләр.

Бәйрәмнәрнең кайсы дини, кайсы милли, кайсы башка халыктан кергән, нинди максатны күздә тота, кешегә нәрсә бирә: дини яки милли аңын үстерәме, рухны баетамы? Бала анализ ясый белсен. Фикерләү юлы

белән бала үзе нәтиҗә ясасын: киләчәктә аның өчен кайсы бәйрәмнәр кирәк һәм әһәмиятле, кайсысы мөһим түгел, кайсысы зарарлы?

Динебездә бәйрәм итүләргә, күңел ачуга, спорт ярышларына урын бармы соң? Җавап уңай, әмма алар шәхес тәрбияләргә, иманны ныгытырга, рухны савыктырырга, сәламәтлекне яхшыртырга тиеш. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Сезнең күңелегезнең дә сезнең өстә хакы бар, күңелләрегезне иркенгә чыгарып алыгыз. Югыйсә, явыз холыклы булырсыз», – дип әйтте. Гомәр радыяллаһу ганһе дә үз вакытында, үз кул астындагы өлкәләрдә далага чыгып, төрле спорт ярышлары, күңел ачулар оештырырга куша торган булган.

Бу уңайдан милли горурлыгыбыз булган Сабан туйларының әһәмиятен киметергә тырышу, кайбер дин әһелләренең аны тәнкыйтьләп чыгуы һич тә дөрес түгел. Аның рухи асылын югалтып, гадәти эчү бәйрәменә әйләнеп баруы, әлбәттә, тәнкыйтькә лаек, ләкин без бу бәйрәмне инкяр иткәнче, аңа рухи төсмер бирик. Сабан туе безнең милли хисләребезне яңарта, туган-тумачалар, яшьтәшләр белән очраштыра, балаларыбызда җитезлеккә, көчле булуга мәхәббәт тәрбияли. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә көрәшкән, ат һәм дөя чабышларында катнашкан, балаларны ярыштырып уйнарга яраткан, беренче килгәннәргә бүләкләр бирә торган булган. Төз ату, йөзүне, авыр әйберләр күтәреп ярышуларны хуплаган. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең анабыз Гайшә радыяллаһу ганһә белән ярышуы да билгеле. Берсендә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам беренче килгән, берсендә – Гайшә радыяллаһу ганһә. Шуннан соң Расүлебез: «Бергә-бер булды», – дип әйткән. Дөяләр чабышында Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең дөясен гади бер кешенең дөясе узгач, мөселманнар бик кайгырышканнар. Әмма Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзенең ярыш нәтиҗәләре белән канәгать булуын, борчылырга урын юк икәнен белдергән һәм: «Аллаһы сөекле колларын дәрәҗәләрен күтәреп тә, төшереп тә сыный»,

– дип әйткән. Моның белән Пәйгамбәребез галәйһиссәлам ярышларда җиңү үз максат түгел, ә катнашуның әһәмиятле булуын искәрткән.

Бүген «сәламәт тормыш алып бару» мәсьәләсе күтәрелә, «Җитәкчеләр шәхси үрнәк күрсәтсеннәр», – дип тә сөйләнелә. Бу үрнәкне Пәйгамбәребез моннан 14 гасыр элек безгә эшләп, күрсәтеп калдырды. Димәк, спорт ярышларында катнашу да сөннәт икән. Әмма шәхесне түбәнсетә, рәнҗетә, имгәтә торган, бөтен максаты көндәшеңне юк итүгә, акча эшләүгә корылган вәхши спортка шәригатебез каршы. Бүген меңәрләгән кешеләр алкышлап торганда, рингта көрәшчеләрнең бер-берсен акча өчен, дан өчен үтерүләрен телевизор аша спорт дип күрсәтәләр, без моны харам дибез. Мондый фильмнар балада рухи сыйфатларны куәтләп, сәламәт яшәүгә теләк уятмый, киресенчә, баланың шәйтани хисләрен куәтли һәм хайвани инстинктларын көчәйтә.

Минемчә, спортның иң күркәме – чаңгы спорты. Кызганыч, ул әле бездә җитәрлек пропагандаланмый. Кеше картайгач көрәшә дә, хоккей уйный да, йөгерә дә, штанга күтәрә дә алмый, әмма чаңгыда йөри ала. Кыш көне 3–4 км чаңгыда йөреп кайтуны гадәткә кертсәк, сәламәтлегебез күпкә яхшырак булыр иде. Мәктәпләрдә спортның торышы, төрле спорт чараларында катнашкан балалар саны белән түгел, ә призлы урын алган балалар саны белән билгеләнә. Бу, үз чиратында, спортка массакүләм сәламәтләндерү чарасы итеп түгел, бәлки, көндәшләр арасында көрәш итеп, берьяклы гына карауга китерә, еш кына шатлык урынына нәфрәт, көндәшләрне күрә алмау хисе тәрбияли.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам безгә җиңелүнең дә табигый хәл икәнен күрсәтте.

Бүген еш кына дин әһелләрен музыканы аңламауда, дискотекага йөрмәүче мөселман егетләребезне тормыштан артта калуда гаеплиләр. Әлбәттә, Ислам музыканы инкяр итми, әмма нинди музыка, нинди ният белән уйнала, бу – бик әһәмиятле. Рухны ярлыландыра, шәһвәтне ко-

тырта торган һәртөрле музыканы харам дип әйтү – диннең кимчелеге түгел, ул – шуны да аңлаудан мәхрүм кешеләрнең кимчелеге. Медицина фәннәре докторы, профессоры А. М. Карповның «Самозащита от наркомании» дигән китабыннан өзек китерәм: «По интенсивности воздействия на мозг и психику хаотичных звуковых, световых, цветовых, ритмичных и других раздражителей это сравнимо с катастрофой. Такие песни людей возбуждают, но дезорганизуют их поведение.

Тонкие эмоции и мышление не получают сюжетного развития и «отключаются». Движения становятся стереотипными. От такой музыки люди становятся глупее, грубее, примитивнее. Именно на дискотеках молодые люди эмоционально перевозбуждаются, теряют контроль над своими побуждениями и поступками и приобщаются к наркотикам, алкоголю, табаку, знакомятся с любителями развлечений, попадают в «веселые» компании. Подобная музыкально-развлекательная продукция оказывает мощное деструктивное действие на духовное, психическое и физическое здоровье людей и способствует распространению алкоголизма, наркомании, а также и заболеваний передающихся половым путем».

Монысы инде: сез әйтергә яраткан «надан муллалар» сүзе түгел, үзегез үк мөкиббән киткән медицина вәкиле – медицина фәннәре докторының уй-фикерләре, фәнни-тикшеренү нәтиҗәләре. Безне – дин әһелләрен музыканы, сәнгатьне аңламауда гаепләүчеләр, игътибар белән кат-кат укыгыз һәм нәтиҗә ясагыз. Дин әһелләре «ненормальный»мы, әллә көн-төн мөкиббән китеп шул музыканы тыңлаучы «зыялыларыбыз» «ненормальный»мы?

Яхшыны-яманнан, хәләлне харамнан аера белмәү дә – дини тәрбия җитмәү билгесе. Әти-әни баласының дусларына да битараф булырга тиеш түгел. Җайлап кына, ачуын чыгармый гына бу мәсьәләдә дә дөрес юнәлеш бирү мөһим. Баланың дусты аны түбәнлеккә, начарлык-

ка өстери торган түгел, аңа яңа биеклекләр яуларга ярдәм итә торган, җәннәткә керерлек гамәлләр кылуга сәбәпче булса, әти-әни өчен зур ярдәм. Баланың шөгыле дә, дуслары да аңарда тәкъвалык сыйфатларын үстерергә тиеш.

*Җәлил хәзрәт Фазлыев*

*«Йөз дә бер вәгазь» китабыннан*

# Әдәби сәхифә

# Соңгы сынау

Кояш урман артыннан күтәрелеп, сүрән нурлары белән авыл ихаталарын сизелер-сизелмәс яктырта башлауга ук, өчимәнлеләр Нургали абый белән Кәүсәрия апа турындагы шомлы хәбәрне кабалана-кабалана берберсенә тапшыра башлады. Авылның хөрмәтле абыстае һәм мөхтәрәм аксакалы булган әби-бабайны кичә төнлә бер исерек машинасы белән бәрдереп киткән. Урамда кап-караңгы иде, шулай да, машина номерын күреп калучылар булгач, гаепле кешене бик тиз эләктергәннәр үзе, ләкин халык бик яраткан, олы ихтирамга ия булган ике өлкән кешенең хәле бик авыр икән, бик авыр... Күр син аны: Рамазан аенда, төнге тәравих намазыннан кайтканда, шундый бәлагә тарыганнар бит, ә!

Нургали абый белән Кәүсәрия апаны район хастаханәсенә бергә, ике кешелек аерым палатага яткырдылар. Илле елга якын бер гаилә булып гомер кичергән әби белән бабайны аермыйча, бер-берсенә иптәш вә терәк булырлар дип, шулай бергә урнаштырганнар иде. Улы Саха республикасының Мирный шәһәрендә, кызы исә бөтенләй чит илдә – Германиядә яшәгәнлектән, аларны башта борчымаска булдылар, әмма соңрак, бабайның хәле начарайгач, хәбәр итеп чакырттылар. Хәер, якын туганнары янда булмаса да, палатадан халык бер дә өзелеп тормады: күрше-күлән, мәчет картлары, башка авылдашлары килеп, күчтәнәч тә китерде, көчләреннән килгәнчә ярдәм дә итте. Сигезенче дистәне ваклап баручы карт белән карчыкка авыл халкының зур хөрмәт күрсәтүе алар ихласлы дин әһелләре булган өчен генә түгел, күркәм холыкларына, ачык, нурлы йөзләренә дә бәйле иде. Моннан тыш әле яшь чакларындагы танышу хатирәсе дә үзенә күрә бер сәбәп булды. Шушы тормыш хәле, менә инде берничә дистә ел дәвамында авыл тарихына мөнәсәбәтле кызыклы кыйсса буларак, буынна-буынга, телдән-телгә күчеп килде. Аны ишеткәч, кемдер елмайды, кемдер хискә бирелеп, күз яшьләрен тыя алмыйча ела-

ды, әмма күпләр бу хәлне олы бер гыйбрәт вә хикмәтле сабак итеп кабул итте...

...Яшь чагында Нургали агач ташый торган зур йөк машинасында эшләде. Ул вакытта, техника аз булу сәбәпле, машина йөртүчеләрне бик еш нормадан арттырып эшләттеләр, кайвакытта хәтта төнен дә юлга чыгарга туры килде. Менә шундый караңгы төннәрнең берсендә тәмам алҗыган егет рульдә барганда йоклап китә һәм аның юан бүрәнәләр төялгән машинасы тирән ерымга әйләнеп төшә. Ярый әле арттан МТС тракторы кайткан була. Тракторчы абзый, ауган йөк машинасын күреп, авылга чаба һәм ашыгыч ярдәм белән милиция хезмәткәрләрен чакыра. Фаҗига урынына килеп җиткән табиб исә... суламыйча яткан егетнең авыр җәрәхәтләрдән һәлак булуын белдерә. Каты яраланып, канга буялып беткән гәүдәдә, чыннан да, җан әсәре барлыгы сизелми. Инде нишләргә – медицина хезмәткәре шоферның үлемен рәсми рәвештә раслагач, «мәетне» район үзәгендәге моргка илтеп куялар. Шунда берничә сәгать ятканнан соң, егет, Аллаһының безгә мәгълүм булмаган тәкъдире белән, аңына килде. Бик каты туңганын һәм яраларның хәйран авырттырып сызлавын тойган егет беравык үзенең кайда икәнен аңыша алмыйча ятты. Ләкин яралары бәйләнмәгәнен, тимер ятагында ни матрасы, ни юрганы булмавын сизгәч, кайда эләккәнен чамалый башлады: «Йә Хода. Мине үлгән дип белеп, мәетләр саклагычына китереп куйганнар түгелме соң... Моргта бит мин». Әлеге шомлы, тетрәндергеч уй Нургалиның күңелен тәмам пошаманга салды. «Шушы зәһәр салкын, караңгы, куркыныч урында тагын күпме ятарга туры килер икән? Озакка китсә, чыннан да үлеп, җаның белән хушлашырга туры килмәгәе».

Күңел төпкелендә пыскып торган яшәү өметен чарасызлык күләгәсе кара шәүләсе белән каплый башлаган мәлдә, дөм караңгы бүлмәнең шомлылыгын тагын да арттырып, кемнеңдер сулкылдап елаган тавышы ишетелде. «Саташам бугай», – дип үзалдына уйлап куйды егет. Ләкин ян-

дагы елау тавышы тукталмагач, кымшанудан җәрәхәтләрнең каты авыртып алганын сизеп алса да, гаҗәпләнү хисе тәэсирендә, Нургали бераз күтәрелеп, башын тавыш ишетелгән якка борды.

– Әй... Кем бу? – дип караңгыга аваз салган егет үзенең хырылдап чыккан тавышыннан сискәнеп куйды. – Монда кемдер бармы?

– Бар... – диде бер хатын-кыз һәм борынын мышкылдатып: «Мин бу», – дип өстәде дә үкси-үкси елавын дәвам итте.

– Кем «мин»? – Әле генә чыгып китә язган котының әкрен генә урынына урнаша башлавын тойган Нургали шушы кешеләрчә бирелгән җаваптан бераз тынычлана төште. – Исемең ничек соң синең?

– Кәү...сәрия – диде тавыш иясе, исеменең беренче һәм икенче иҗекләре арасында янә мышык-мышык килеп.

– Ә мин Нургали – Янында исән кеше булуына анык төшенгәннән соң, егет сөенеченнән торырга талпынды, әмма башындагы яраның үзен кинәт «белдереп» алуыннан ыңгырашып куйды да, янә урынына ауды. Соңыннан исә, бераз тынычлангач, көчәнмәскә тырышып, әкрен генә тагын бер соравын бирде:

– Ә син, Кәүсәрия... безнең кайда ятканыбызны беләсеңме?

– Моргта – дип җаваплады «елак тавыш», шушы сүзнең мәгънәсенә әллә ни исе китмәгәндәй.

– Менә мин дә аны шулай уйлаганыем, – диде Нургали, һәм беравык дәшмичә ятканнан соң, сөйләшүне дәвам итте:

– Кәүсәрия, син монда ничек эләктең соң?

– Баттым – дип караңгы почмактан кыска һәм беркатлы җавап бирде тавыш. – Ә син?

– Ә мин... рульдә чакта йоклап китеп, машинам белән чокырга әйләнеп төштем.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Бер-берсенең җавабыннан хәйран калып, егет белән кыз күпмедер вакыт гаҗәпләнеп, дәшмичә ятты. Чыннан

да, ышанырлык хәлмени? Бер көнне «үлеп», бервакытта «терелгән» ике «мәет» бер урында шулай очрашсын әле? Шаккатырлык тәкъдир галәмәте булмый, тагын ни булсын? Йә Аллаһ.

Шулвакытта үзләрен кабер эчендә яткандай тойган яшьләрнең күңелләре бербөтен булып, олы, якты дөньяга чыгу максатына ирешүдә бер-берсенә сүзсез генә ярдәм итешергә вәгъдә бирде. Җәрәхәтләре каты сызлаудан, төнге салкын үзәкләргә үтеп туңдырудан гаять җәфаланып ятса да, Нургали җаны тернәкләнеп китүен һәм яшәү дәрманына ия булуын сизде. Кәүсәрия дә, читтәрәк яткан егетнең ни кыяфәтен күз алдына китерә алмаган, ни холык-фигыльләрен белмәгән килеш, аның шушы минутларда үзе өчен дөньядагы иң якын, иң кирәкле кеше булуын аңлады.

– Нургали.

– Әйе, Кәүсәрия.

– Бик суык монда. Туңдым мин, Нургали. Кулларымны да, аякларымны да тоймыйм.

Үзенең нинди хәлдә булуын абайлап бетермәгән егет, яраларның авыртуына көч-хәл белән түзеп, башта күтәрелеп утыра, аннары идәнгә төшеп, иреннәрен тешли-тешли, үрмәләп-шуышып дигәндәй, тавыш ишетелгән якка хәрәкәтләнә башлый, ләкин кыз яткан сәндерәгә кадәр килеп җиткәч, хәле бетеп ыңгырашып ала да, туктап кала. Каты туңудан һәм күрше «мәетнең» янына ук килеп туктавыннан тәмам куркуга төшкән кыз тагын да ныграк калтырана башлый. Әмма кытыршы кулның беләгенә кагылуын тойгач, әүвәл сискәнеп алса да, бераздан тынычланып киткәндәй була.

– Кәүсәрия, монда төшә аласыңмы? Төшсәң, бер-беребезгә сыенып җылынып идек, дим…

Бер-берсенә инде сыенырга өлгергән ике җанның калып-гәүдәләре дә берләшкәч, калебләр төбендә пыскып торган өмет чаткысы зураеп, ныграк, ышанычлырак итеп янып китте, хәтта… олы мәхәббәт ялкынына

әверелеп, бу бүлмәне генә түгел, бар дөньяны – хәзерге һәм алдагы тормышны сөенечле итеп, яктыртып җибәрде.

Соңыннан, иртәнге якта килгән санитарның бер-берсенә елышып утырган ике «мәетне» күргәч, ничек кычкырып җибәрүен дә, яралардан йөзе ертылып, шешенеп, зәңгәрләнеп бетү сәбәпле, әкиятләрдәге куркыныч диюгә охшаган егеткә берсүзсез кияүгә чыгарга ризалашкан Кәүсәриянең кешелекле гамәлен дә авыл халкы җай чыккан саен кызык бер хәл итеп искә алды. Чыннан да, Нургалиләр өенә килен булып төшкәндә, Кәүсәрия аның бу төбәктәге иң чибәр, иң уңган-булган егетләрнең берсе икәнен белмәде. Умыртка баганасы бераз зарарланган булгач, Нургалигә ярты ел чамасы урын өстендә ятарга туры килде. Шул вакытта нәкъ менә Кәүсәрия аңа үз-үзенә ышанырга ярдәм итте, кайчакларда ире төшенкелеккә бирелеп, күңеле сүрелсә, шаяртыбрак: «Теге төнне моргта минем янга килә алдың бит? Димәк, аякка басасың, Аллаһы боерса!» – дип юата иде үзен. Ә терелгәч, Нургали шөкер йөзеннән аякка гына түгел, намазга да басты. Хәләл җефете дә дин юлын үз итеп, намаз иясе дә булды, авыл абыстае ярдәме белән гарәп хәрефләрен үзләштереп, Коръән укырга да өйрәнде. Өлкән яшьтәге абыстай вафат булгач исә, аның вазифаларын Кәүсәрия башкара башлады.

Әй, бу тормыш арбасы диген! Бик озак тәгәрәттеләр аны бергәләп Нургали белән Кәүсәрия. «Терелеп» кабат аякка басканнан соң, егет зур йөк машинасына инде утырмый: башта фермада эшли, ә соңыннан, идарәдә эшләүче шофер лаеклы ялга киткәч, аның урынына урнаша – «Нива» машинасында колхоз рәисен дә йөртә, «конторның» башка йомышлары буенча да йөри. Авылда ул намаз укучы бердәнбер егет иде. Шуңадыр, өстәвенә, намуслы, сабыр, акыллы, тырыш булганга да халык аны бик хөрмәт итте. Гаилә коргач та, берничә ел алар әти-әнисе белән иске, кечкенә генә алты почмаклы йортта яшәделәр. Аннары, башка чыгарга ниятләп, авыл читендәге буш җир кишәрлегендә йорт салырга

керештеләр. Күпләр моның ише эшкә тотынуга, колхоздан ни дә булса «чәлдерү» җаен эзләсә, Нургали, идарәдә эшләп тә, төзелеш материалларын харамлашып юнәтүгә беркайчан да бармады. Бура агачларын да, конторга тиешле акчасын түләгәннән соң, урманга барып үзе әзерләде. Менә шул урманда янына инде бер килгән әҗәл белән аңа тагын очрашырга туры килде: алга таба авасы зур агач нигәдер ул басып торган якка ауды… Шунда, ярдәмче иптәшен коткарам дип әрле-бирле килгән арада, Нургали куе, чәнечкеле ботаклар астында калганын абайларга өлгерми. Әмма бу юлы да әҗәл дигәне егетне канаты белән генә сыпырып ала, ә җанын үзе белән алып китми: тәне шактый сыдырылып зарарланса да, егет өенә исән-имин кайта. Әйе, дөрестән дә, Аллаһы Тәгаләдән вакыт җитмәгән булган, чөнки гаиләдә әле ике бала – бер шаян малай белән мөлаем бер кызның туасы бар иде…

Яңа зур йорт салынгач та, авыл халкын гаҗәпләндергәне шул булды: яшьләр Нургалинең әти-әнисен иске йортта калдырмый: үзләре белән күчендереп, аларга зур, иркен, яп-якты бүлмә бирәләр. Кәүсәрия каенанасы белән авыл урамыннан сердәшче ахирәтләрдәй култыклашып узганда, көнләшүчеләр дә булгандыр, әмма авылдашларның күбесе аларга ихлас күңелдән сокланды.

Балта остасы булганга, авыл янындагы тау итәгеннән агып торган чишмәне төзекләндерү эшен дә Нургалигә йөклиләр. Агачтан искитмәле матур бизәкле корылманы ясый башлауга, аның әнисе авырып китә. Хатыны өйдә булуга карамастан, ул сәгать, сәгать ярым саен әнкәсенең хәлен белергә дип кайтып килә иде. Корылма төзелеп беткәндә, газиз әнкәсе вафат була. Авыл җыенында чишмәне Нургалинең әнисе истәлегенә «Миннекамал чишмәсе» дип исемләргә тәкъдим ителгәч, халык бу тәкъдимне бертавыштан хуплый. Шунда азсүзле, моңарчы хис-тойгыларга бирешүен бер дә күрсәтмәгән яшь ирнең, йөзен «көрәк» куллары белән каплап ела-

ганын күргәч, хатын-кызлар гына түгел, олпат ир-егетләр дә күз яшьләрен тыя алмый.

Бер ел да үтми – Нургалинең әтисе дә вафат була. Бик хөрмәтләп озата аны яшьләр. Ул вакытта халык Кәүсәриянең ихлас елаганына аптырый: үз әткәсемени.

Ә бер көнне алар тормышында күңелсез, әмма бик тә гыйбрәтле шундый хәл була. Эссе җәйнең урталары иде. Эштән әлсерәп кайткач, Нургали, гадәттәгечә, өенә кермәкче була, әмма өй ишеге эчтәге эләктергечкә бикләнгән булып чыга. Түрдәге бүлмәдән бала елаган тавыш ишетелә, ә Кәүсәрия чыкмый… Ишеккә дә, тәрәзәгә дә шакылдату нәтиҗә бирмәгәч, Нургали тәмам куркуга төшә, хатынына нидер булган дип, бик каты борчыла. Бала да елаудан һаман туктамый… Нидер эшләргә кирәк дип, ир-ат сарайдан кирәкле инструментын алып, тәрәзәне рамыние белән бергә салдыра да өй эченә керә. Караса, хатыны тирән йокыга талып, диванда ята, кечкенә каплаулы караватта исә яңа гына уянган бала елапмы елый. Барысы да тәртиптә булганга күңеленнән Аллаһыга шөкер сүзләре җиткереп, Нургали хатынын битеннән үбеп уята һәм күңеле тулып, аны башыннан сыйпый-сыйпый: «Кадерлеләрем минем, кадерлеләрем минем», – дип кабатлый да кабатлый. Алдагы төндә бала нигәдер көйсезләнеп йокламаганга, Кәүсәрия бөтенләй ятмады диярлек, ирен исә, иртән эшенә барасы бар дип, борчымаска булды. Төнлә йоклый алмагач, көндез ашарга пешереп бер кат өй эшләрен караганнан соң, яшь хатын баланы яткырып, черем итеп алырга уйлаган, ә менә нәрсә килеп чыккан… Ә бер ел алдан шундыйрак хәл күрше Харисларда булган иде. Ул вакытта Харис эштән кайтып, өенә керә алмыйча торган өчен сүгенә-сүгенә хатынын кыйнады. Ә Нургали… Шул кичне Кәүсәрия белән бала исән-имин булу сөенеченнән кибеткә барып, зур торт алып кайтты. Чынчынлап олы йөрәкле, игелекле, мәрхәмәтле бит ул Нургали.

Балаларын алар дини тәрбия биреп үстерделәр. Кечкенәдән сүрә-догалар ятлаттырып, 7-8 яшьләрендә намаз уку тәртибен өйрәттеләр (мәктәптә укыганда икесе дә биш вакыт намазны калдырмый иде). Уллары Фаяз югары уку йортына кереп, шәһәрдә укый башлагач, әтисе ниндидер үзгәреш булуын сизеп алды: моңарчы аралашучан, ачык йөзле егет нигәдер үз эченә бикләнеп, төшенкелеккә бирелде. Бер кайтуында күңеле төшүнең сәбәбен сорагач, егет башта серен ачмады, соңыннан исә укыган җирендә проблемалар барлыгын әйтте. Шунда Нургали аны-моны сораштырып тормыйча, бер генә сорау бирде: «Биш вакыт намазың тәртиптәме?». Фаяз карашын читкә юнәлдереп, атасының күзенә карарга кыймыйча торгач, хәлнең асылына төшенгән әтисе улы гомерлеккә исендә калдырган кыска, әмма бер мәгънәле нәсыйхәт әйтте: «Намазыңны калдырсаң, Аллаһы Тәгалә дә сине калдырыр. Намазыңны ташламасаң, Аллаһы Тәгалә сине беркайчан да ярдәменнән ташламас». Шул җитә калды: малай элекке тәртипкә кайтып, барысы да рәтләнде. Институтны тәмамлаганнан соң, бер курсташының әтисе: «Иң акыллы, иң тәртипле иптәшең белән кайтыгыз», – дип чакыргач, Фаяз Якутиядәге Мирный шәһәренә китеп, алмазлар эшкәртщ торган оешмага эшкә урнаша. Эше күңеленә дә ятышлы, бик керемле дә булып чыга. Шунда матди хәлен яхшыртып, «аякка баскач», әле укыган вакытта аралаша башлаган күрше авыл кызы Наиләгә өйләнә Фаяз. Шуннан соң яшьләр Якутиягә китеп баралар.

Университетның дүртенче курсында укып йөргәндә, кызлары Тәслимә бер егет белән аралашуын, алай гына да түгел – егетнең гаилә корырга җитди нияте барлыгын әйтте. Каршы килмәделәр, «алып кайт, танышып, сөйләшеп карыйк», диделәр. Кайттылар. Ләкин Нургали төс-кыяфәте ярыйсы күркәм булган егеттә масаю һәм мин-минлек сыйфатлары барлыгына игътибар итә. Каян башына килгәндер, чәй табыны алдында ул егетне аптырашта калдырып: «Син «Кунут» догасын беләсеңме?»

– дип сорап куя. Тегесе «юк» дигәч: «У-у, «Кунут»ны белмәгәч, син витр-вәҗиб намазын укымыйсың, димәк. Шулай булгач, көндәлек намазларың да юк инде синең. Ә намаз укымаган кешегә без кызны бирә алмыйбыз», – дип төп мәсьәләгә нокта куя. Кыз ахыргы курста укыганда, университет җитәкчелеге бер төркем студентларны, шул исәптән Тәслимәне дә, Германиягә практикага җибәрә. Менә шунда башка факультетта укучы Сәлим исемле егет белән таныша да инде ул. Икесе дә дини гаиләдән, икесе дә намаз әһелләре булу аларны тагын да якынайта, берләштерә. Немец телен бик яхшы белгәнгә, икесенә дә эш тәкъдим итәләр. Никахны алар кыз ягында – Өчимәнледә укытты. Тәслимәне чит илгә яшәргә дип озатканда, Кәүсәрия күз яшьләрен тыя алмыйча елады да елады. Нургалие генә: «Мондый кияү белән Германиягә түгел, Кытайга китсә дә күңелем тыныч минем. Анысы да Аллаһы җире, анда да сәҗдә кылып була», – дигәч, күнде һәм: «Язган ризыгың шундадыр инде, кызым», – дип тынычлангандай булды. Шулай да, озаткан көнне үзенең бәгырь парәсе, нәзек чәчкәдәй үстергән газиз баласы белән аерылу тойгысыннан кич буе үзенә урын таба алмыйча, юксынып, өзгәләнеп йөрде. Аннары төне буе йоклый алмыйча, тормыш елларын барлап, уйлап ятты.

«Үлеп терелгәнче» Кәүсәрия медицина көллиятен тәмамлап, үзе туып үскән Каенлык авылына эшкә кайткан була. Менә шунда, иптәш кызлары белән су коенырга дип барган җирендә, кинәт көзән җыеру сәбәпле «бата» да инде ул. Инде мәгълүм булганча, шушы тәкъдир сынавы аны Өчимәнлегә китерә. Соңыннан кайбер тел бистәләренең: «Карале син, безнең Нургали-имәнгә нинди күркәм Кәүсәрия-каен туры килгән!» – дип кинаяле, әмма бик төгәл чагыштырулары бер дә юкка булмаган шул. Ә тора-бара, Кәүсәрия фельдшер-акушерлык пунктында эшли башлагач, аның күңеле дә каеннардай ак, ә теле һәркемне тынычландырырлык татлы сүзләргә бай булуы ачыкланды. Шуңа да авыл халкы аны үз итеп, «безнең шәфкать туташыбыз» дип яратып атый. Соңрак

та бу хөрмәт сүрелми һәм күпмедер вакыт дәвамында ул «шәфкать апасы» булып тора, ә инде лаеклы ялга чыгып, халык соравы буенча дини йолаларны төпләп үти башлагач, авылдашлары, үзләре дә сизмәстән, аны «безнең шәфкать абыстае» дип йөртә башлый. «Шәфкать туташы» һәм «шәфкать апасы» чагында ул тәннәрне дәвалаучы булса, соңгы елларда үзенең вәгазь-нәсыйхәтләре, хикмәтле сүзе, һәрьяклап уйланган төпле киңәшләре белән авылдашларының җаннарын сихәтләндерде.

Менә шулай итеп, шактый еллар үтте, Нургали белән Кәүсәрия үзләре яшәгән салада гына түгел, күрше-тирә авылларда да намуслы, ихлас иманлы мәчет карты һәм хикмәтле, күркәм холыклы абыстай буларак дан-хөрмәт казанды.

...Хатирәләр җебенә тормыш вакыйгаларын тезә-тезә, Кәүсәрия әби бабае Нургали белән бергә үткән юлны күз алдыннан уздырып ятты. Күпне күрергә, кичерергә туры килде шушы тормыш юлында, ләкин ни генә булса да, һәрбер хәлне алар Аллаһының хикмәтле сынавы буларак кабул итте. Менә шушы бәлагә таруларының да ниндидер әлегә мәгълүм булмаган хикмәте бар. Тик нинди?

Хастаханә палатасында караңгырак та, салкынчарак та иде. Шуңа микән, әби ерак яшьлектәге теге шомлы, әмма аны бик бәхетле иткән төнне исенә төшерде. «Салкын иде, бик салкын иде шул төн. Тәннәребез калтырады, ләкин бер-беребезне ишетүгә җаннарыбыз җылынды... Чөнки шул җаннарда олы мәхәббәт ялкыны кабынды. Шул вакытта Аллаһы Тәгалә мин бөтенләй белмәгән, гомеремдә бер тапкыр да күрмәгән кешегә күңелемне беркетеп куйды. Гомерлеккә беркетте. И, Нургали... Йөрәгем белән тойдым синең изгелегеңне, чиста күңелле, яхшы кеше булуыңны. Ирләр арасында шундыйлар сирәк була, бик сирәк. Хатын-кызның бәхете – ирдән диюләре хак сүзләр. Тормыш юлдашыңны ышанычлы, игътибарлы, кайгыртучан булуы, аның күңел җылысын тоеп яшәү, чыннан да, зур бәхет бит ул. Безне кавыштырган хәтәр-хәвефле шул төндә күңелләребезне

җылытып та, яктыртып та җибәргән мәхәббәт хисе Аллаһының рәхмәте белән гомер-бакыйлык булды, кимемәде, сүрелмәде. Нургалиемнең күңел җылысын әле дә тоям бит әле мин…»

Хастаханә бүлмәсендәге тынлыкны бүлеп, янәшәдә караватшыгырдаганы ишетелде. Бераздан шул тавышка ыңгырашкан аваз кушылгач, әби: «Бабаем уянды, ни дә булса кирәктер», – дип борчылып куйды. Шул мәлдә әңгер-меңгерле почмактан әрнүле зәгыйфь тавыш яңгырады:

– Кәүсәрия!

– Әү, Нургали.

– Бик суык монда. Туңдым мин, Кәүсәрия. Өстәвенә, гәүдәм әллә нишли… сызлый, кысыла.

Машина бәрдерүдән каты имгәнмәсә дә, әбинең аягы сынган була, шуңа күрә ул башта әкрен генә күтәрелеп утыра, аннары зур саклык белән идәнгә төшеп юрганын эләктерә дә, карты яткан каршы якка үрмәләп-шуышып дигәндәй, хәрәкәтләнә башлый. Бабай яткан караватка кадәр килеп җиткәч исә, юрганны аның өстенә яба, һәм кулын учларына алып:

– Монда мин, монда, җаныкаем. Бераз йоклап алдыңмы?

– Аллаһыга шөкер, кадерлем, йокладым. Әллә нинди төшләр күреп яттым. Хәерлегә булсын.

– Ниләр күрдең, җаныкаем?

– И, сөйләсәң сүз. Яныма ап-актан киенгән бик матур бер кеше килеп минем белән сөйләште. Мин аны белмим шикелле. Ә ул: «Без синең белән инде ике тапкыр очрашкан идек, ди. Беренчесендә, ди, Аллаһы Тәгалә сиңа гомер генә түгел иман юлы һәм бик яхшы пакь күңелле тормыш юлдашы да бүләк итте. Икенчесеннән соң арагызны ныгытып, гаиләгезне ишәйтте. Үзенә тагын да якынайтты. Әйбәт яшәдегез бу дөньяда, диде… Ә хәзер инде ди сиңа кайтырга вакыт җитте.

Соңгы сүзләрне ишетүгә Кәүсәрия әбинең йөрәге дөп-дөп итеп кага башлады. Әмма үзен кулга алып, ул бабайның кулларына бите белән сарылды да, тыныч кына әйтте:

– Төштә аклык – матурлык күрүне хәерлегә юрыйлар. Ә кайтырга дигәне. Без монда әллә дүртенче, әллә бишенче көн түгелме соң? Чыннан да, озакламый моннан чыгарып, кайтарып җибәрерләрдер безне, шәт.

– Кәүсәрия. Мин сиңа бик рәхмәтле. Син мине бәхетле иттең. Ә ул дөрес әйтте: бик әйбәт тордык без синең белән. Гаебем булса – кичереп, риза-бәхил бул.

Хәлне аңлап күңеле тулса да, әби бар сабырлыгын туплап, еламаска тырышты.

– Нургали, иртәгә балалар кайтып җитә, дип хәбәр иттеләр. И, сагынганнардыр инде. Иртәгә, Нургали!

Бабай беравык дәшмичә ятты. Соңыннан ниндидер бик мөһим нәрсәне исенә төшереп, борчылып, кабаланып иткәндәй, карчыгының кулларын йомшак кына кысып алды да, авыр сулап:

– Кәүсәрия. Мин Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле. Ул мине бәхетле итте. Гомер буе Аның ярдәмен, мәрхәмәтлеген тоеп яшәдем. Синең белән булдыра алганча тырыштык, ләкин шөкер итеп бетерә алдык микән. Балаларга әйт: барысына шөкер итеп яшәсеннәр, безне догадан калдырмасыннар.

Сабыр итеп күз яшьләрен тыеп торса да, әби түзми һәм бабайның күкрәгенә сыенып, тавыш-тынсыз елый башлый. Ярты гасыр элек берберсенә ныклап беркетелгән җаннарның озакламый аерылачагын абайлап, ул бу дөньядагы иң якын, иң кадерле кешесе белән хушлашу мизгеле якынайганын аңлый. Моңа ышанасы килмичә, сыңар канаты каерылгандай авырлык тойса да, ул күңеленнән тәкъдир насыйбы белән ризалашты. Шуңа да картына:

– Бер дә борчылма, әтисе. Әлхәмдүлилләһи шөкер – биш вакыт намаз ияләре бит алар, догадан калдырмаслар. – диде.

– Кәү...сәрия. Тагын шунысын да әйт: кәлимәне... телләреннән төшермәсеннәр.

– Кайсы кәлимәне? – дип сорый әби, каушавыннан саташкандай.

– Ләә иләәһә илләллаһ, Мүхәммәдүр рәсүлуллаһ.

Әби ризалыгын белдерергә дип талпынган арада бүлмә бер мизгелгә яктырып киткәндәй булды... ...һәм ни гаҗәп: күңел халәте тәэсирендә Кәүсәрия абыстай матур чәчкәләр белән тулган зур, иркен болын күрде. Карап туймаслык шул җете, нәфис чәчкәләрнең кәлимәне көйләп торуларыннан болын өсте чыңлап торган тавышка күмелде. Ә чәчкәләр арасында – шатлыклы елмаеп, яшь Нургали басып тора. Бераздан болын әйләнәсендәге киң һәм нык кәүсәле баһадир имәннәр белән яшел яулык япкан ак күлмәкле оялчан каеннар куе яфракларын кыштырдатып, Нургали әйткән кәлимәне кат-кат кабатлый башладылар сыман. Ә бер имән өстендә урта яшьләрдәге Нургали агач ботакларына тотынып, шул кәлимәне елмая-елмая тәкрарлый. Менә ихлас мөэминнәрнең тугры, ышанычлы юлдашы булган шушы кәлимә агач яфракларыннан зәңгәр күктәге ак болытларга күчеп, бар җиһанны тантаналы яңгыратты. Бәхетле болытлар, бөек кәлимәне кабатлый-кабатлый, ерак офыкларга таба юл тотты. Ә алар арасында, йә Раббәл гааләмиин! – күк гөмбәзен яңгыраткан болытларга кушылып, моңлы мәкаме белән кәлимәне көйли-көйли, ап-пак тукымага төренгән инде өлкән яшьтәге Нургали әкрен генә көнбатышка таба юнәлә. Ә Кәүсәрия... Ул тын да алмыйча өскә карап, талгын гына ерагайган картын моңсулык һәм шатлык илә соклану хисләрен берләштереп чагылдырган нәүмизле дә, өметле дә күз карашы белән озатып, күккә карап тора...

Абыстай өнгә килеп башын күтәргәндә, тынып калган карты инде суламый иде. Колагы белән күкрәгенә янә кысылып, бабайның йөрәк ти-

бешен ишетергә өметләнгән карчык бераздан мәрхүмнән аерыла һәм шушы хәлгә әле ышанып җитмәгәндәй, күпмедер вакыт селкенмичә, хәрәкәтсез утыра. Болытлар арасыннан кинәт килеп чыккан ай киң тәрәзә аркылы бүлмәне матәм нурлары белән яктыртып алгач кына, Кәүсәрия әби чынбарлыкка кайтып, үзенең гомерлек юлдашы белән уртак булган юлы шушы мизгелдә аерылганын аңлый. Бу вакытта якты ай нурлары хастаханә бүлмәсен генә түгел, Кәүсәриянең олы хәсрәт халәте биләп алган күңелен дә яктыртты сыман, шуңа күрә әүвәл ни эшләргә, ни уйларга белмичә утырган карчык, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп, кулларын догага күтәрә:

– Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин! Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинәә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн. Йә Раббым, йә Аллаһы! Бакыйлыкка күчкән тормыш иптәшем Габделхак улы Нургалинең рухын шат кыл. Аның кылган гыйбадәтен кабул итеп, гөнаһларын, бәндәчелек белән кылган хата-кимчелекләрен ярлыка, мәңгелек Ахирәт тормышында Үзеңнең рәхмәтендә булуын насыйп әйлә. Йә Раббым! Үземне дә, балаларым белән оныкларымны да тәүфыйк-һидаять юлында булучылардан кыл! Бу фани дөньядан мәңгелеккә күчкәндә, хәләл җефетем үрнәгендә «Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүр-расүлуллаһ» кәлимәсен әйтеп, Үз хозурыңа мөэмин-мөселман булып, иманлы хәлдә күчүебезне насыйп ит... Йә Раббым! Нургали картым кебек, мин дә Сиңа бик рәхмәтле! Шундый кеше белән кавыштырганың өчен, миңа шундый тормыш юлдашы, шундый балалар, шундый бәхетле гомер биргәнең өчен шөкер хисләремне җиткерәм Сиңа, йә Рабби! Йә Илаһым!.. Нургалием белән бүген аерылдык, әмма ышанасым килә: күңелләребез әле очрашачак. Бу дөньяда без бәхетле булдык, Ахирәттә дә лаеклы бәндәләрең өчен хәзерләнгән Җәннәт бакчаларында бергә булырбыз дип өметләнәм. Шунда Синең дидарыңны күрү бәхетенә ирешүчеләр арасына эләксәк, бу дөньядагы җиде дистә ярымлык гомергә сузылган

сәгадәт Син бар кылган бәхетнең бер бик кечкенә генә өлеше булганын төшенер идек. Мәңгелектәге бәхет-сәгадәт белән чагыштырганда, безнең бу дөньядагы гомерлек бәхет ул – барлык дәрья-диңгезләр суының бер тамчысы гына кебек. Ләкин дәрья-диңгезләр суы тамчылардан җыелган сыман, Ахирәттәге сәгадәт дәрьясы да җир йөзендәге бәхет тамчыларыннан җыела. Шундый һәрбер тамчының асылы – иман, ягъни Синең барлыгыңа-берлегеңә ышану, йә Раббым! Шушы иман-ышанычтан аерма, мине, зәгыйфь бәндәңне онытма, ялгызымны калдырма, ярдәмеңнән ташлама...

Тәрәз пыяласына шап-шоп итеп бәрелә-сугыла, шыбырдап яңгыр ява башлады. Кемнеңдер, яңгырлы көнне якын кешесен соңгы юлга озатканда, «табигать тә елый» дигәнен исенә төшереп, Кәүсәрия абыстай күңеленнән бу фикергә ризасызлык белдерде. «Нишләп елау булсын, ди! Киресенчә – яңгыр бит ул Аллаһының бик зур рәхмәте, бәрәкәтле нигъмәте! Адәм баласына җир йөзендә яшәргә мөмкинлек бирелүе дә – зур нигъмәт. Әмма яңгыр башланып, кайчандыр туктарга тиеш булган кебек, кеше гомере дә кайчан да булса тәмамлана. Иң мөһиме – һәркем Аллаһыны танып, гыйбадәт әһеле булып, бу дөньядан лаеклы китәргә тиеш...

Кәүсәрия әби шулай үзалдына уйланып утырган арада, кинәт хастаханә бүлмәсен шомлы караңгылык баса. Моңарчы караңгылыктан бер дә курыкмаган карчыкның күңелен ниндидер хәвефле тойгы биләп ала. Күпмедер вакыт шул халәттә утырганнан соң, әллә йокымсырап киткәнгә, әллә аңын җуйганга, абыстай сәер, хәтта гаҗәеп шундый бер хәлне күзәтә: бүлмәне болытлар арасыннан килеп чыккан ай яктыртып ала һәм аның хафалы яктысында кап-кара киемнән булган килбәтсез, куркыныч бер зат пәйда булып, әби янына килеп баса. Шуны күрүгә абыстай «Әгузү билләәһи минәш-шәйтанир-раҗим» дип әйтә, шуннан соң теге

шыксыз артка чигенә, әмма бөтенләй чыгып китми. Әби «бисмилләсен» әйтәм дигәндә генә, кара зат аны бүлдереп, дәшә:

– Нәрсә, харап булдыгызмы? Харап булдыгыз! Халык дөрес сөйли: ул төнне мәчеткә бармаган булсагыз, исән-сау калыр идегез. Ха-ха... Ә Хариска бит ул кичне мин аракы эчерттем. Мин! Ә Аллаһы сезне сакламады.

Кәүсәрия абыстай кара затның кем булуын чамалап, бисмилләсен әйтеп, болай диде:

– Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин! Аллаһы Раббыбызның биргәненә шөкер! Безнең белән ни булса да – без бик риза!

– Ю-ук, алай түгел ул, – дип ысылдады кара шәүлә. – Сез бит изге Рамазан аенда, намаздан кайтканда бәлагә тарыдыгыз. Шул сәбәпле, картың дөнья куйды. Менә сиңа изге ай! Ә бит әле тагын яшәп була иде дөньяда!

– Вәсвәсәләмә, мәлгунь! Картымның изге Рамазан аенда җан бирүе – бик зур дәрәҗә ул! Аннары – кешенең ничек, ни сәбәпле түгел, нинди рухи халәттә китүе мөһим. Тәравихтан кайтканда, безне машина бәрдерүе дә – Аллаһы Тәгалә билгеләгән тәкъдир, һәм моңа дәгъва, ризасызлык белдерергә безнең хакыбыз юк! – дип җавап бирде әби бераз кабаланып.

– Ха-ха! Матур, тыныч картлык кичереп, әле тагын яшәр идегез, дим! Сезнең аерылуыгызга табигать тә елый бүген!

– Аллаһы Раббыбыз биргәненә шөкер! Әле егет чагында бакыйлыкка күчәргә тиеш булган Нургалигә Аллаһы Тәгалә зур бүләк ясады бит: гомер биреп, туры юлга бастырды, мөэмин-мөселманнардан кылды. Ә шунда динсез, гыйбадәтсез китеп барган булса? И-и, Аллаһы Раббыма ничек ризасызлык белдереп, ничек оялмыйча елап, бу яңгырны да табигатьнең күз яшьләренә тиңлим?! Юк, без Нургали белән бәхетле һәм бүген вакытлыча гына аерылдык.

– Алай димә. Сезнең әле башкарасы эшләрегез, сөйләшәсе сүзләрегез калды...

Абыстай бермәл уйланып алды: «Чыннан да, кадерле хәләл җефетем белән ярты гасыр чамасы бергә яшәдек, ә бер-беребезгә нәрсәдер әйтмичә калдык сыман...» Ләкин әби шушы вәсвәсәгә дә бирешми һәм ышанычлы, ныклы тавыш белән җавап бирә:

– Юк! Барысы да Аллаһы әмере буенча нәкъ үз вакыты белән башлана һәм тиешле булган вакытта тәгәлләнә. Барысы да Аллаһы теләгәнчә.

Шуннан соң абыстай «әгузү-бисмиллә»сен әйтеп, «Аятел-Көрси»не укый башлый, аны ишетүгә кара киемле зат юкка чыга. Шулвакытта бүлмә тылсымлы нурлардан яктырып киткәндәй була һәм ни гаҗәп: Кәүсәрия әби алдында шушы төндә инде бер күзәтелгән күркәм манзара ачыла: ул матур чәчкәләр белән тулган зур, иркен болында басып тора, аның әйләнәсендә куе агачларның яфраклары изге зикер сүзләрен кабатлагандай игелекле, талгын җилдә әкрен генә кыштырдый, ә ак болытлы, зәңгәр күктә... йә Раббил гааләмиин! – анда аның сөеклесе... аның кадерле бабае киң итеп елмаеп, аңа кул болгый! Сөбеханәллаһ, мә шә Аллаһ! Әйе, Нургали бит бу! Әле китмәгән! Шунда күктә көтеп тора! Иң мөһиме – мине күрә. Әнә бит – миңа кул болгый! Әй, юк. Болгамый. Ул бит кулы белән ишарәләп, үзе янына менәргә чакыра. Әйе-әйе... мен монда минем янга, күккә, дип дәшә бит ул! Менәсе иде, менәсе. Хәзер, җаныкаем, менәм, кадерлем! Менәм!

Шул вакытта, ниндидер билгесез көчләр тәэсирендә Кәүсәрия әби җирдән аерылып өскә таба күтәрелә башлый. Агач кәүсәләренең очларына җиткәч туктый һәм аска караганнан соң, йөрәге кинәт чәнчеп алудан «аһ» итеп әйтеп куя һәм... астагы күренеш юкка чыгып, бар дөнья ап-акка әйләнә, өстән исә Нургалинең тавышы ишетелә:

– Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүр расүлуллаһ.

Кәлимәне ишетүгә, абыстай шундук аны кабатлый һәм матур тавыш белән шул сүзләрне әйтә-әйтә югарыга күтәрелә башлый.

– Килеп җиттеңме, җанашым!

– Килеп җиттем, бәгърем!

– Мин бик тә шат, кадерлем!

– Шушыдыр ул тәкъдирем!

– Сөбеханәллаһ!

– Әлхәмдүлилләһ!

– Аллаһу әкбәр!

– Вә лилләһил хәмд!

Һәм бу ике изге җан Аллаһының иксез-чиксез Галәмен бөек кәлимә авазы белән бергәләп яңгыратып, Яратучының иман-гыйбадәт әһелләре өчен хәзерләнгән сокландыргыч, хәйран калырлык хозур-ләззәт микатенә таба юнәлделәр…

*Ришат хәзрәт Курамшин,*

*Кукмара мәдрәсәсе мөдире*